PRESSA

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН 2020 СЕНТЯБРЬ № 9

# СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

АРАГА
*әни керә*
*ике ут арасында*

*уха*
*оста балыкчы*
СЕРЛӘРЕ

*Әллә ир-ат,*
*әллә хатын-кыз*
ТАБИГАТЬ
*ялгышы гынамы*

*Гөлназ*
СӘФӘРОВА: *«Бүгенгемнән дә яхшырак булырга телим!»*




Хәтер – мәңгелек...

# Хәтер – мәңгелек...

Бөек Җиңүгә миллионлаган гап-гади кешеләрнең каһарманлыгы бәрабәренә ирешә алдык. Алар арасында безнең татар егетләре, татар кызлары да байтак. Минем бабам, синеке, аныкы... Сугыш афәте кагылмаган, сугыш ишек шакымаган капка, гаилә калды микән? Җиңү таңы безгә шуңа да кадерле... Инде бу хакта бүгенге яшьләребезгә дә аңлатасы, төшендерәсе, күңелләрендә горурлык хисләре уятасы килә. Бу проект – шул хакта. Мондый ядкарьләр, бәлки, сезнең гаиләләрдә дә сакланадыр. Юк икән, аларны шушы сайттан табып алырга мөмкин: https://pamyat-naroda.ru. Бабаларыгызга орден-медальләр ни өчен бирелде икән? Балалар, оныклар белән бергә утырып эзләп карагыз әле. Әлеге тарихи документларны үз күзләре белән күргәч, Җиңү сүзенә алар инде берничек тә битараф калалмас...

Табышларыгызны безнең белән дә уртаклашыгыз. Хатларыгызны көтәбез.




Бабам Камалов Гаяз Камалетдин улы повестканы 1941 елның июнь аенда ала. Аны Мари урманнары уртасындагы Суслонгер хәрби лагерена старшина итеп җибәрәләр. Бу үлем лагерендагы гаделсезлеккә түзә алмыйча, фронтка китә. Бүләкләү документларыннан күренгәнчә, бабай Көнбатыш фронтның 16 армиясе 108 нче укчы дивизиянең 539 нчы укчы полкының 4 нче укчы рота старшинасы булып Смоленск өлкәсендә сугышка керә. Шунда ук ВКП(б) сафларына баса. 1942 елның 12 апрелендә Смоленск (хәзерге Калуга) өлкәсенең Фомино авылы янында Зайцева Гора биеклеге өчен хәлиткеч бәрелештә каты яралана – пуля сул үкчәсен үтәли тишә.

Госпитальдә дәваланып аякка баскач, сугыш юлын дәвам итә. Бик гаярь сугышчы була ул. 1943 елның 8–10 март көннәрендә Калуга өлкәсенең Жиздра станциясе янында Крестьян Тавы авылын дошманнан азат иткәндә рота командиры яралангач, ике мәртәбә ротаны һөҗүмгә күтәрә. Снаряд кыйпылчыгы тиеп, уң кул сөяге чәрдәкләнсә дә, яу кырын ташламый. Бабам командалыгында 40 фашист солдаты юк ителә. Үзе исә «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә.

Яралары төзәлгәч, 1943 елның августыннан бабай сугышчан юлын 2 нче Белоруссия фронтының 855 нче аерым телеграф-эксплуатация ротасында отделение командиры булып дәвам итә. Монда да зур батырлыклар кыла: һөҗүм вакытында өзелгән телеграф чыбыкларын берничә мәртәбә снарядлар яңгыры астында шәхсән үзе ялгап, фронт штабын Кызыл Армиянең Баш штабы белән бәйләүче элемтәне булдыра. Шушы батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.

Бабаем өчен Бөек Ватан сугышы 1945 елның сентябрь аенда гына тәмамлана. Өйдә – Буа районының Түбән Наратбаш авылында аны газизе Нурлыбәнат, биш баласы көтә. Ә әниебез Гөлчирә 1947 елда дөньяга килә.

Миләүшә ГАЙНАТУЛЛИНА.
Казан.



04345


Наградной лист

1. Фамилия Имя и Отчество Камалов Гаяс Камалович
2. Звание Старшина 3. Должность часть Командир отделения 855 Отдельной Эксплоатационной телеграфной роты

Представляется к награде Орденом „Красная звезда“

4. Год рождения 1904 5. Национальность татарин 6. Партийность ВКП(б) 7. Участие в гражданской войне, последующих боевых действиях по защите СССР и отечественной войне (где когда) Отечественная война 1941 г.

Имеет ли ранения и ...



Приказ

Секретно экз №

По 539 стрелковому полку 108 стрелковой дивизии
16 Армии Западного фронта
23 Марта 1943 года №02 Действующая армия
От имени Президиума Верховного совета Союза ССР Награждаю:

Медалью „За отвагу“

1. Санитара красноармейца Балакирева Евгения Ивановича за то, что он в боях 8-10.3.1943 г. за д. Верхняя Акимовка под сильным обстрелом вынес с поля боя 16 человек тяжело раненых с их оружием, один ручной пулемет и 7 раненых без оружия. 1923 года рождения, б/парт., Русский, призван в РККА Торопецким РВК Калининской обл. Домашний адрес

2. Командира пулеметного расчета 1 пульроты старшего сержанта Грачева Василия Константиновича за то, что он в ... за д. Верхняя Акимовка под сильным обстрелом арт... выдвинул свой пулемет в перед наступающих подразделений ... уничтожил до 20 автоматчиков и 2 расчета станковых пулеметов противника, которые мешали продвижению наших подразделений ...

# Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2019





Фото: Анна Арахамия

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

**Баш мөхәррир**
Л. Н. Маликова

**Редколлегия:**
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

**Редакциянең гомуми телефоны** 222-09-77

**Җитәкче урынбасары** 222-09-78
Рәмзия Кашапова
**Баш мөхәррир урынбасары** 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
**Җаваплы сәркатип**
Лариса Маликова
**Әдәби мөхәррир**
Эльмира Закирова
**Сайт мөхәррирләре:**
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

**Тышлыкта:**
Гөлназ Сәфәрова
Фото: Аида Сафина

**Верстка:**
Резеда Галиуллина
**Бүлек мөхәррирләре:**
Чулпан Галиәхмәтова
Раилә Хәялиева
**Корректор**
Фирдәвес Исмәгыйлева
**Фотокорреспондент**
Анна Арахамия
**Гамәли хезмәткәрләр:**
Нәфисә Әскәрова
Олег Сердюк

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 28.08.2020 ел.
Басмадан чыкты: 4.09.2020 ел.
Заказ А-2223
Тираж 7300

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»




ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+





Фото: Анна Арахамия

Роберт ӘХМӘТҖАНОВ

* * *

*Эзләп тапты күзем бу якны да,*
*һич тә онытмады.*
*Хушлаша җәй, ак яулыклар болгап*
*агыла болытлары...*

*Хушлаша җир, яфракларын җилпеп*
*шаулаша юкәләр.*
*Күзгә җиргә яфрак түшәп, бар да*
*түләп китәләр.*

*Сибелә яфрак эзләренә, сары*
*көзнең табышлары.*
*Кагыла җирнең җан җиренә, кагыла*
*торна тавышлары!..*

*Сине уйлап, мин дә чиртәм сазның*
*көзге кылларына.*
*Авырттырма, җаныма тимә, көздәй,*
*чыкма юлларыма!*

*Көзге мәхәббәтем сиңа түгел – аны*
*көзге урман тыңлар,*
*Сиңа түгел, бәгърем!*
*Сулыгып-сулыгып, моңы*
*еракта бер тынар...*


## Безнең тышлыкта

«Уңышка ирешкән кеше белән яңадан танышырга кирәк, диләр. Кешесенә караптыр. Мин бер дә үзгәрмәдем дип әйтә алам. Үз-үземә ышанычым барлыкка килде – шул гына.»



12 «Мин – Гөлназ Сәфәрова...»
Гөлнур Сафиуллина

## Заман һәм без



6 Табигать тә ялгышамы?
Чулпан Галиәхмәтова

16 Витамин модасы
Раилә Хәялиева



20 Безнең апа – Чемпион!
Эльмира Закирова

# ЭЧТӘЛЕК

## Татар дөньясы




24
«Бер яхшылык эшләп калырга...»
Мәдинә Авзалова



28
Көмеш тезген, алтын йөгәннәр...
Лилия Гәрәева

## Мәдәни тормыш



34
Кол
Ләлә Сабирова

42 Беренчеләр
Әхтәм Зарипов

## Яшәеш



46
Алсуның чишмә башы – Уяндыкта!
Венера Мәҗитова



50
Ир бирмәк – җан бирмәк
Гөлнур Сафиуллина

Җыр булып калдың 54
Роза Мулланурова

## Хуҗабикә




60
Балыкчы шулпасы

»

# ТАБИГАТЬ ТӘ ЯЛГЫШАМЫ?


Фото: www.pixabay.com

**Безнең җәмгыятьтә буыннан-буынга килгән кыйммәтләр бар: хатын-кызның төп миссиясе бала табып аны тәрбияләү, ир-атныкы – рухи һәм физик яктан көчле булып, гаиләсен җил-яңгырдан саклап яшәү, киләчәк өчен хезмәт итү. Хатын-кыз булып тугансың икән инде, димәк, нәселне дәвам итәр, синдә яралган җанны үстерер өчен Аллаһы Тәгалә ана булу вазыйфалары йөкләгән, тугач сабыеңны ашатыр, рухи бәйләнешне арттырыр өчен күкрәкләр бүләк иткән үзеңә. Хатын-кыз икәнеңне йөрәгеңнең һәр тибешендә аңлап яшисең. Ир-атлар да бу хакта онытмый торгандыр. Әмма... үз тәнен, Аллаһы Тәгалә биргән җенесен кабул итә алмыйча газап утында янып яшәгәннәр дә бар. Күңел тынычлыгын табар өчен хәтта операция өстәленә ятарга мәҗбүрләр. Аларны трансгендерлы кешеләр диләр. Күпләр аларга «бозыклар» дигән тамга сала. Әмма ул кешеләрнең дә күңелләре, җаннары бар, бәхетле булырга тели, башкалар кебек яшәргә хокуклы. Эчләрендә нинди буран уйнаганын үзләре генә беләдер. Ходай биргән бердәнбер гомереңне үз асылыңны эзләп үткәр әле! Юк, теләп алган йөкләре түгел ул. Табигать ялгышымы бу, әллә җәмгыять хатасымы?..**



Чулпан
ГАЛИӘХМӘТОВА

### *Бәхетсез лотерея*

Мониторның теге ягында – озын чәчле, зур күзле, борыны, ияге хатын-кызларныкы кебек нәфис Оля. Тавышы югары тембрлы. Миңа туры карарга уңайсызлана. Әледән-әле чәчен төзәтә. «Бик үк куркыныч күренмимдер дип ышанам». Бу – Оляның миңа әйткән беренче сүзләре.

– Үземне белә башлаганнан бирле, хәзер мин – әти кебек, үскәч әни кебек булам дип уйлый идем. Сабыйлык беркатлылыгым белән шуңа ышанып яшәдем. 7-9 яшьләрдә әнинең киемнәрен киеп караган өчен мине кыйныйлар иде, әмма психик халәтемә артык игътибар итмәделәр. Урта сыйныфларда укы-

ганда гадәти түгеллегемне аңладым... Үсмерләр бик рәхимсез. Артык йошмак булганлыктан, мыскыл иттеләр, әледән-әле кыйналдым. Ул чактагы кимсетелүләремне искә аласым килми. Югары сыйныфларда җирәнгеч, бозык кеше икәнемә тәмам инанган идем инде. Юк, нормаль үсмер егет булырга теләмәдем түгел, теләдем. Хоккей уйнадым, бассейнга йөрдем. Тик болар барысы да үземне көчләп эшләнгән адымнар иде. Пубертат чорына кергәч, кеше үзгәрә башлый. Мускулларыма, иягемдәге төкләргә карап, мин түгел бу дип уйлый идем. Интернетта утыра башлагач, трансгендер кешеләр турында укып белдем. Стипендия акчасына парик, косметика алып, качып кына хатын-кыз кебек киенеп карый башладым. Яңа образда ничек күренүем кызыксындырды. Моның җүләрлек икәнен хәзер аңлыйм. Тагын бер җүләр шөгылем бар иде: көндәлек яздым. Әти-әниләр белән яшәгәндә көндәлек алып бару – ут белән уйнауга тиң ул. Беркөнне университеттан кайтып фатир ишеген ачып керүгә, әти белән әни икесе ике яктан шул парикларым, көндәлекләрем белән мине кыйнарга тотындылар. «Син ВИЧтан, наркотиклардан үләчәксең, фахишәгә әйләнәчәксең», – дип «якты киләчәк» юрадылар. Шушы хәл тагын кабатланса, безнең фамилияне йөртмәячәксең дип кисәттеләр. Әти-әниеңнән андый сүзләр ишетү бик авыр. Син бит аларга ышанасың! Үз-үземне үтерергә теләгәннән соң психоневрологик диспансерда ятып чыктым. Шул чорда параллель төркемдә укыган бер студентны җирләргә бардык. Зират, аның мәете, кабер бик нык тәэсир итте. Үлемнең начар булуын аңладым һәм үз тормышым өчен көрәшергә сүз бирдем. Әти-әнинең куып чыгаруына әзерләндем. Эш таптым. Университетны тәмамлаганчы алар белән яшәдем, аннан соң Мәскәүгә магистратурада укырга киттем. Бозыклык эзләп китәсең дип, гаиләм берничек тә ярдәм итмәде. Нинди бозыклык хакында уйлау! Миңа иң элек яңа тормышымда исән калырга кирәк иде.

## Ишекне ачып керүгә, әти белән әни көндәлекләрем белән мине кыйнарга тотынды.

Ул вакытта табиб белән киңәшләшмичә гормоннар ясый башлаган идем. Ә бу бик зур хатам булган икән. Гомер өчен куркыныч... Мәскәүдә дә тормыш авыр булды. Мин ул вакытта кызларга охшый башлаган идем инде. Тулай торакта яши алмыйм. Мәскәү өлкәсеннән фатир арендаладым. Эшкә урнаштым. Ул акча фатир өчен түләүгә китеп барды. Трансгендерлыкны билгеләү буенча табиблар комиссиясен үтәр өчен акча җыйдым. Ул вакытта 50 мең сум иде. Үттем. Бу хакта каян белгәннәрдер: «Безгә мондый карачкы кирәкми», – дип эштән кудылар. Депрессиягә бирелдем. Шулай да яшәргә көч таптым. Документларымны бик зур авырлык белән алыштырдым. Ул вакытта бик күп кимсетүле сүзләр ишеттем. Махсус адвокат яллагач кына очына чыга алдым.

*«Компьютерда мин үземне кечкенә, кара төртке итеп кенә күрәм. Сезгә хатын-кыз булып күренәмдер дип ышанам». Оля кабат үзенең тышкы кыяфәте өчен борчыла. Ул әле һаман да туры карарга кыенсына.*

– Борчылма, син бик чибәр, Оля. – Ул оялып кына рәхмәтен әйтә. – Ахырда әти-әниең кабул итә алдымы?

– Тулысынча кабул итеп бетерделәр дигән хис юк әле. Бәлки, ата-аналар хакында алай уйларга ярамыйдыр да, әмма Россиянең иң яхшы уку йортларының берсен тәмамлап, яхшы эшкә урнашып, әйбәт акчалар ала башлагач кына, миңа карата мөгамәләре яхшырды кебек. Зур компаниядә программист булып эшли башладым. Дусларым бар, Альп тауларына чаңгы шуарга йөрим. Күрәсең, фаразлары чынга ашмавын аңладылар. Алар еракта яши. Әни белән көн саен телефоннан сөйләшәм. Һаман да миңа элеккеге исемем белән эндәшә. Трубканы куям да гадәти тормышыма кайтам. Әнигә дә авырдыр. Теге вакытларда дингә бик каты бирелде. Минем бит бабаларым мулла булган. Әбием сезнең журналны алдыра иде... Пандемия вакытында әти, шалтыратып, эше буенча киңәшләште. Бу да яңалык. Мөнәсәбәтләр әкренләп кенә җайга салына кебек. Сирәк кенә кунакка кайтам. Теге вакыйгалардан соң сигез ел үтүгә карамастан, фатир ишегеннән тыныч кына уза алмыйм... Ә шәхси тормышымда... Дөресен генә әйткәндә, анда берни юк. Мин куркам... Гашыйк булганым бар. Әмма үземә әйтә идем: ул хакта уйлама, аңа карама... Шулай итеп хисләремне тыйдым. Ир-атларны үземә якын китермим. Ул романтика эзләп танышыр да, барысын да белгәч кыйнап ташлар дип куркам. Шуңа күрә яулап ала алмаслык принцесса мин. *(Оялып кына елмая.)*

– Инде үзеңне бәхетле кеше дип саныйсыңмы?

– Бәхет минем өчен абстракт төшенчә. Эшем, дусларым бар. Аларның яртысы минем үткән тормышым хакында белми. Бәлки, аларга карата болай эшләү гадел дә түгелдер. Документларым кыяфәтемә тиңдәш. Күлмәк, итәк киеп йөрим. Җенес органнарыма пластик операция ясатырга телим. Әлбәттә, моның бик кыйммәт икәнен беләм. Акча җыям. Операциядән соң шәхси тормышымны да көйләрмен дип хыяллана идем, әмма «Гаилә кодексы»ндагы яңа төзәтмәләр минем кебек язмышлы кешеләргә гаилә коруга урын калдырмас кебек. Яңа канун гамәлгә кергән очракта, безгә документларны – туу турындагы таныклыкны алыштырырга кирәк булачак. Димәк, беркайчан да гаиләм, балаларым булмаячак... Дәүләт мине хатын-кыз итеп таныды да, хәзер икенче сортлы кеше исәбенә кертмәкче. Югыйсә болай булуыма мин гаепле түгел. Бәхетсез лотерея тартып чыгарганмын... Әгәр минем кебекләрне кечкенә чактан ук мыс-

кыл итмәсәләр, без гадәти кешеләрдән әллә ни аерылмас та идек. Балачактан башка төрле мөнәсәбәт булса, мондый тарихлар булмас иде. Гомосексуалистлар төркеменә кертеп караулары да куркыта. Мин илне ташлап китәргә мәҗбүрмен. Googl компаниясенә эшкә чакырганнар иде, ул чакта ризалык бирмәдем. Хәзер үзем аларга эш сорап хат яздым. Ә мин әле яши генә башлаган идем. Әле яңа курыкмыйча дуслашырга өйрәндем. Быел беренче тапкыр дус кызларымны җыеп туган көнемне үткәрдем...

### *Үземне озак эзләдем*

Германга 23 яшь. Кара майкадан. Беләкләрендә мускуллар уйнап тора. Иягендә сирәк кенә сакалы бар. Ул аны һаман сыпыра. Борын тирәсендә, ираннәрендә – пирсинг.

– Билгеле, бу хәлнең минем белән булуын теләмәс идем, әмма... 12 яшемдә үземә ошамый идем инде. Башкаларга охшамаганлыгым турындагы уй башымнан китмәде. Мин мәктәптә укыган вакытта анимелар (яшүсмерләр һәм олылар өчен япон мультфильмнары) популяр иде. Үземне шундагы ир-ат персонаж кушаматы белән атап йөри башладым. Яшьтәшләрем дә яңа кушаматымны кабул итте. Үзем хакында ир-ат заты буларак сөйләшә башладым. Бу хакта әти-әниләр белгәч, сораулар туды. «Уен гына, игътибар итмәгез», – дип тынычландырдым, чөнки нигә болай эшләгәнемне үзем дә аңламый идем әле. 16 яшемдә трансгендерлар хакында укып белдем. Менә бит мин кем икән дип уйладым! Дөрес, әле берничә ел кем булуым хакында шикләнеп йөрдем. Беренче тапкыр егет кешегә гашыйк булдым. Кызларны да ошата идем. Бу еллар – иң авыр вакытларым: сайлау алдында калдым. Үзем хакында хатын-кыз затыннан итеп сөйләп карадым, булдыра алмадым. Сексопатологка йөри башладым. Аңардан билгеле бер карар көттем. Әмма ул да «юк, син бит кыз кеше» дип әйтмәде. Гомерем буе психологлар белән шөгыльләндем. Кечкенә чакта гиперактив бала булганмын, үсә төшкәч, язу



Медицина фәннәре докторы, профессор, сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш балалар баш психологы Ләйлә ШӘЙДУКОВА: *«Трансгендерлык тумыштан ук килә икән, аны берничек тә төзәтеп булмый...»*

белән проблемалар килеп чыкты, үсмер чакта депрессияләр... Психологлар белән әллә нинди темаларга сөйләшә идем, әмма трансгендерлык буенча гына түгел. Миндәге үзгәрешләрнең уеннан узуын күргәч, әни берничә табибка алып барып карады, әмма алар патология күрмәде. Бу уемнан кайтару өчен әни бик күп тапкырлар минем белән утырып сөйләште. 20 яшемдә, үзем эшләп акча таба башлагач, Санкт-Петербургка барып түләүле комиссия үттем. Түләүсез комиссия дә үтәргә була, әмма сиңа шизофрения диагнозы куеп, психик авырулар диспансерына ябып куймаслар дип беркем гарантия бирми. Җитмәсә, бер айлап әлеге диспансерда ятып тикшерелергә кирәк. Комиссия узгач, табиб белән киңәшләшеп, гормоннар кадый башладым. Операция ясаттым. Минем күкрәкләрем болай да үсмәгән иде, шулай да кистердем. *(Майкасын ачып җөйләрен күрсәтә.)* Алты ел бер спортзалга йөрим. Документларымны алыштырып бетерүнең икенче көнендә туптуры ир-атлар чишенү бүлмәсенә юнәлдем. Әйе, мин беркайчан да эчке киемнәремне салмыйм. Душ та керә алмыйм. Бер тапкыр юынып карадым. Каршыма бергә тренажерда шөгыльләнгән ир-ат очрады, ярый артыма әйләнеп өлгердем.

– Хәзер әти-әниеңнәр белән мөнәсәбәтең ничек?

– Әни әле дә булса мине кызы итеп сөйләшә. Чынбарлыкны кабул итәргә тырышмый да кебек. Телефонында да яңа исемем янында иске исемем дә язылган. Әлбәттә, аңа авыр. Әни белән әтинең «кешеләргә нәрсә әйтербез» дигән уй башларыннан чыкмый. Әмма бу – аларның проблемасы. Югыйсә бөтен танышлар, туганнар белә. Мондый йөзем, буем белән яшерергә азапланмыйм да. Шулай да эштә күрше цехтагы ир-атлар белеп мыскыл итә башлагач, китәргә туры килде. Кондитер-технолог мин. Хәзер заказ буенча өйдән тортлар пешереп сатам. Әти белән бу темага берничә тапкыр сөйләштек, әмма аның ахыры һәрвакыт җәнҗал белән тәгәлләнде. Ул мине аңламый. Ә бит сине яратабыз, диләр...

– Ә нигә пирсинг ясаттың?

– Кыяфәтемнән игътибарны читкә юнәлтер өчен. *(«Кулым да гел татуировкалардан тора», – дип беләген күрсәтә.)* Тышкы кыяфәтем өчен бик борчылам. Көзгегә карамыйм. Мускулларыма гына тыныч карый алам. Гомумән, чит кешеләр янында үземне шәрә итеп хис итәм.

– Хыялыңны тормышка ашыргансың, инде син бәхетлеме?

– Дөресен генә әйткәндә, юк. Бәхетсез булырга сәбәпләр дә юк кебек, әмма шулай да... Антидепрессантлар да эчтем, психолог белән дә эшлим. Шәхси тормышымны көйли алмыйм. Якын кешем юк. Балам булмаячак, чөнки аңа бәхет, матур киләчәк бирә алырмын дип уйламыйм...

### *Трансгендерлык: авырумы, нормаль халәтме?*

«Быелга кадәр трансгендерлык психик тайпылыш дип санала иде, әмма Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы аны бу исемлектән алып

## Җенесен үзгәртеп тә бәхет таба алмаганнар бар.
# Бәхет – күңел халәте, күрәсең...

атты. Андый кешеләр үзен җенесенә туры китереп хис итми, җенес конфликты аркасында бик авыр кичерешләргә дучар була», – дип аңлатты профессор, медицина фәннәре докторы, Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш балалар баш психиатры Ләйлә Шәйдукова. Профессор әйтүенчә, трансгендер кешеләр саны күбәя.

– Трансгендерлык килеп чыгуның берничә сәбәбе бар, – ди ул. – Аның төп варианты генетикага бәйле. Кеше генетикасында хилафлык килеп чыга икән, аны берничек тә төзәтеп булмый, чөнки ул тумыштан килгән үзенчәлек. Гормоннарның дөрес эшләнмәве дә сәбәпче була ала. Бүгенге көндә рәсми рәвештә фәнни яктан расланган инде: ир-атларда тестостерон гормоны кими, ә хатын-кыз гормоны – эстроген арта. Шуңа күрә дә хәзер күп ир-атларның гәүдәсе хатын-кызларныкына охшаш. Алар куркыныч янаган төркемгә керә. Тәрбия дә бик мөһим роль уйный. Кечкенәдән малайларны – булачак ир-ат, ә кыз баланы булачак хатын-кыз итеп тәрбияләү шарт. Ата-аналар балаларында гендерлык бүленеше буенча сәерлекләр күрә икән, кичекмәстән белгечләргә: психиатр, сексопатологка мөрәҗәгать итсен иде. Дөрес, генетикага бәйле булса, берничек тә тәэсир итеп булмый. Баланы ничек бар, шулай кабул итәргә кала. Әмма шунысы да бар: хәзер дөньяда гына түгел, Россиядә дә җенесен үзгәртеп тә канәгатьләнмәгән, элеккечә үк үзенә урын тапмый яшәгән трансгендерлар шактый. Димәк, эш җенес үзгәртүдә түгел, ә кешенең холкында. Монда башка психик тайпылышлар да булырга мөмкин. Шуңа күрә ниндидер җитди адымнар ясаганчы, тәҗрибәле белгечләр күзәтүе астында булырга кирәк. Минем практикада андый очрак булды. Үзен 30 ел хатын-кыз дип йөрткән ир-ат бик көчле психик травма кичергәннән соң, кабат җенесен алыштырды. Хәтта нечкәреп беткән тавышы да бер төн эчендә үзгәрде. Ул 30 елдан соң үз асылына кайтты.


Минемчә, белгеч хаклы: менә ни өчен трансгендерлыкны ачыклый торган дәүләт комиссияләрендә махсус хастаханәдә ятып чыгу шарты да бар. Ә түләүле комиссияләр бары тик акча эшләүгә кайтып калырга да мөмкин. Бу язманы әзерләгәндә дәүләт учреждениеләрендә эшләүче табиблар әңгәмәдән баш тартты, гәрчә әлеге теманы үзләре үк актуаль дип әйтсә дә. Әйе, җәмгыятьтәге барлык проблемаларны ачып салып сөйләшергә куркабыз шул әле без. Ә бит мәгълүматлы булмау зур проблемаларның башы булырга мөмкин, бигрәк тә төрле яктан гендер мөстәкыйльлеге турында җилләр исკәндә. Федераль матбугатта психиатрлар трансгендерлыкның тумыштан килүе турында да, уйдырма булу очрагы хакында да яза. Беренчесе белән бар да аңлашыла. Ләйлә Шәйдукова әйтүенчә, андыйларны кабул итәргә кирәк. Безнең героебыз Оляның да бәхетле булырга хокукы бар. Моның өчен җәмгыятьтә берниндди киртәләр дә булырга тиеш түгел дип әйтсәк, уйдырма трансгендерлыкка чикләр ачылачак. Үсмерләр кәеф- ләре киткән саен җенес үзгәртә башламасмы?! Мондый хәлләр булмасын өчен, мөгаен, беренче чиратта гаиләдәге тәрбия мөһимдер. Бер танышымның сөйләве искә төшә. «Кызым үсмерлек чорында кисәк кенә: «Нигә мин малай кеше булып тумадым микән, кыз булу рәхәт түгел», – дия башлады. Социаль челтәрләрдә дә үзен ир затыннан итеп язышканын белдем. Аның сәерлеге тышкы кыяфәтендә дә сизелде: малайларча киенә, чәчен кыска итеп кистерә. Бу хәлләргә чаң суктым. Юк, баланы тотып әрләмәдем. Гаиләбезне анализладым. Читтән карагач, кызымны аңлый да башладым. Мин бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр ат кебек эшлим, дилбегәне үз кулыма тотканмын да барысын да үзем хәл итеп яшим икән. Кызым белән аралашырга да вакытым калмаган. Мин аңа хатын-кыз сыйфатларын бирә дә, аңлата да алмаганмын. Ә ирем, әлбәттә, җиңел тормышка риза булган. Ул эшенә барып кайта, гел телевизор каршында утыра, иртәгәсе өчен борчылмый, һәрвакыт үзен карый, яшь, чибәр... Ә минем кайбер көннәрдә көзгегә карарга да вакытым юк. Иң элек үземне кулга алдым. Җитәкче вазыйфасыннан баш тартып, җиңелрәк эшкә күчтем. Җаваплылыкны да әкренләп иремә күчерә башладым. Гади итеп кенә әйткәндә, киредән хатын-кызга әйләндем. Кызым алдында хатын-кыз булып яшәүнең бары тик уңай якларын күрсәтергә теләдем. Хатын-кыз матурлык өчен, ә ир-ат ул матурлыкны саклау өчен дигән төшенчәләрне аңлатырга тырыштым. Хәзер гаиләбездә әти – терәк, әни – гаилә учагын саклаучы. Классик гаилә шулай булырга тиеш инде ул. Кызым да әкренләп карашларын үзгәртте. Дөрес, бер көн эчендә генә булмады бу үзгәрешләр. Әмма беләм – кызым хәзер чын туташ. Әгәр шул вакытта барысын да үз агымына калдырган булсам, дөньяда тагын бер трансгендерлы кеше арткан булыр иде. Гаилә, бары тик гаиләдәге мөнәсәбәтләр кеше шәхесе формалашуда роль уйный».

Җәмгыять тә билгеле бер эталоннары белән бу хәлләрне кискенләштерәдер. Матурлык образы нинди: кызлар зәңгәр күзле, күбәләк иренле, озын, нәфис гәүдәле, ә егетләр физик яктан көчле, киң җилкәле баһадирлар. Балачакта бертөрлерәк булганнар үсмерлек чорына кергәч бүленә башлый. Әмма бөтен кеше дә бу эталонга туры килми бит. Бу исә мыскыл ителүләргә, буллингка юл ача. Үзенә ябылган үсмер кайдан да булса терәк эзли башлый. Вакытында ярдәм кулы сузмаганнарны Интернетның фильтрсыз дөньясы кочаклап кына алачак. Димәк, табигатьне генә гаепләп булмый...

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020


Ярты миллионлы тираж белән бөтен СССРга таралучы журнал тышында сурәтләре басылып чыкканнан соң тормышларында нинди үзгәрешләр булды икән аларның? Бу проект шул хакта да… Татарстан тарихында аларның – ул чорда «Азат хатын», бүген инде «Сөембикә» булып басылучы журналыбыз геройларының да салган эзләре бар. Еллар сарысы сеңгән фотолардан елмаючы ул сөйкемле хатын-кызлар – республикабыз кичкән юлларның тере шаһитлары.

# ҖИР КЕШЕСЕ

















































Фото: Анна Арахамия

**Фәнүсә КАДЫЙРОВА:**
**«Селекционер ул – бүген башлаган эшенең дистә елдан соң уңышлы буласына өмет белән яшәүче. Өмет һәм түземлелек – менә аның юлдашлары. Бәлки, шуңадыр да селекционерларның күбесе озын гомерле. Өметләнеп яшәү гомерне озынайта, күрәсең».**

Фәнүсә Кадыйрова – Әлки кызы. Үзе шәһәрдә яшәсә дә, хезмәт юлы авыл хуҗалыгы белән бәйле аның. Белеме белән агроном, һөнәре буенча селекционер ул.

Фәнүсә Заһитовнаның әлеге катлаулы, сабырлык һәм вакыт сорый торган эшчәнлек белән кызыксынуы юкка түгел. Дәү әтисенең бертуганы Вакыйф Шәкүров – РСФСРның һәм ТАССРның атказанган агрономы, гомере буе борчак селекциясе белән шөгыльләнгән кеше. Ул чыгарган «Казанский 38» сортлы борчак заманында хәтта экспортка озатыла. Мәктәпне яңа тәмамлаган Фәнүсә дә хезмәт юлын абыйсы үрнәгендә Татарстан Республикасының тәҗрибә станциясендә лаборант буларак башлап җибәрә. Үзе эшли, үзе Казан дәүләт авыл хуҗалыгы институтында (хәзерге Казан дәүләт аграр университет) укый. Кыз киләчәген бары туган ягында гына күрергә теләсә дә, язмыш аңа башка юл әзерли. 1967 елда Казанга тәҗрибәле селекционер Наталия Петелина килә. Ул җитәкләгән төркемгә карабодайның яңа сортларын чыгару бурычы йөкләнә. Татарстанда карабодай селекциясенең яңа этабы башлана. Наталия Николаевнаны үзенең остазы саный Фәнүсә ханым. Селекция эше аңа чынлап та бик мавыктыргыч һәм кызыклы өлкә буларак ачыла. 1986 елда карабодайның «Казанская крупноплодная» сорты өчен авторлар төркеменә СССР Министрлар Советы дәүләт премиясе тапшырылу, 1994 елда исә Россия Федерациясенең фән һәм техника өлкәсендәге дәүләт бүләгенә лаек булу – шул тырышлыкларының нәтиҗәсе.

80–90 нчы елларда Татарстан карабодай игү буенча Алтай һәм Башкортстаннан гына калышып, өченче урында бара. «Карабодай икътисадый яктан үзен аклый торган культура, – ди Фәнүсә ханым. – Азык-төлек кыйммәтеннән тыш, аны игү умартачылар өчен дә файдалы. Туфракны төрле чир кузгатучы микроорганизмнардан һәм чүп үләннәреннән дә дәвалый ул. Әмма корылыкка чыдамсыз, туфрактагы авыр металларны туплый торган үзлеге дә бар. Безнең максат корылыкка чыдам, азык сыйфаты ягыннан өстен һәм авыр металлардан чиста булган яңа сортлар чыгару иде. Мәсәлән, «Саулык» дигән сортыбыз диетик сыйфатлары белән аерылып тора».

Яңа сорт булдыру дип әйтү ансат, моның өчен 12–13 ел вакыт һәм гаять зур тырышлык кирәк. Селекционерның хезмәте кабинетта утырып эшли торган түгел. Апрельдән октябрьгәчә – җәйге челләдә дә, коеп яуган яңгыр астында басуда булырга туры килә аңа. «Берәр көн янына бармый калсаң, үз материалыңны танымыйсың. Безнең эш – көн дә күзәтеп, исәпләп, үлчәп, язып бара торган», – ди Фәнүсә ханым. «Димәк, кыш көне эшегез кимрәк», – дигәч, көлеп үк җибәрә: «Кыш көне эшебез тагын да күбрәк. Кышын җәй буе тупланган материалга анализ ясала».

Татарстан Авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институтында (ул эшли башлаган станция хәзер шулай атала) 40 ел эшли Фәнүсә ханым. Бүген ул – Татарстанның атказанган агрономы, ике дәүләт премиясе лауреаты, авыл хуҗалыгы фәннәре докторы, 150 фәнни мәкалә авторы, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы, Казан дәүләт аграр университетының гомуми җир эшкәртү, үсемлекләрне саклау һәм селекция кафедрасы профессоры, карабодайның 16 яңа сортын чыгаручы. «Чатыр Тау», «Батыр», «Яшьлек»... Ул сортларның исемнәре генә дә ни тора!

Лилия ГӘРӘЕВА

Ул – ут кебек! Сәхнәдә дә, эфирда да, тормышта да! Тамашачы аның аптырап, югалып калган чагын хәтерләмидер. Юктыр... Гөлназ бит ул! Чая, җитез, тапкыр!
Мин! Шул исемдәге тапшыруында (ул аның авторы да, алып баручысы да, режиссеры да) үзенең геройларына бу сүзне Гөлназ берничә тапкыр кабатлата. «Мин»дә катнашкан хатын-кызның күңелендә үз-үзенә ышаныч уянырлык, теләсә нинди авырлыкларны җиңәрлек көч тоярлык итеп... Без исә «Барс-медиа» компаниясе проектлары җитәкчесе, алып баручы Гөлназ СӘФӘРОВАның үзеннән: «Мин!» – дип әйттерәбез. Нинди ул без белгән һәм белмәгән Гөлназ?



Фото: шәхси архивтан

# «МИН – ГӨЛНАЗ СӘФӘРОВА...»

Секунд эчендә эфирда фикерен әйтергә һәркем булдыра алмый. Бик авыр бу! Мин өйрәндем.

### Һөнәр сайлау турында

Мин табиб булырга хыялландым! Хирург! Җәйләрне гел әби янында үткәрә идем. Ул – ветеринар, аның белән икәү фермадан фермага йөрибез, малларга вакциналар ясыйбыз. Әбинең һәр адымын күңелемә сеңдереп барам. Мәсәлән, тәкәне ничек печәргә икәнен хәзер дә яхшы беләм. Нинди кайчы кирәгән, нинди мазь... Ул мазьнең исенә кадәр хәтерлим. Сыер бозаулатырга да икәү йөрибез: ул эшли, мин карап торам. Бу процесслар кешеләрдә тагын да кызыграк булачак кебек тоела. Хирург булам дип хәл иткәч, мәктәптә химия белән биологияне тырышыбрак укый башладым. Ә журналистикага кереп китү... Җиденче сыйныфта татар теле дәресендә мәкалә язып карадык. Укытучым Резеда Илдусовна язмамны мактады, «бишле» куйды. Мактаганны исә бик яратам! Юк, юк, үземә объектив карыйм – факт өчен булса гына... Икенче мәкаләмне яздым. Монысын әтигә дә күрсәттем. Ә ул университетта, журналистика факультетында да укыта. «Беренче курс студентларыннан әйбәтрәк язгансың», – диде әти... Беренче курслардан яхшырак?! Миндә канатлар үсте! Әти юк-барга мактый торган кеше түгел! «Сабантуй»га, «Татарстан яшьләре»нә яза башладым. Гел проблемалар күтәрәм! Студент чакта башкалар практикадан өч-дүрт материал белән кайтса, минеке калын папка була иде. Редакциягә ябышып ятам: хатлар редакциялим, интервьюларга йөрим... Нигә киттемме? Дөресен әйтәм: бу эш миңа рухи канәгатьлек кенә китерә, кызганыч, акча китерми иде... Кайчак яшьләр: «Радио-телевидениедә эшлисебез килә, нидән башларга икән?» – диләр. «Газетага язудан!» – дим. Яза, фикерле белә торган кеше генә радиода сөйли ала. Анда авызны ачуга кем икәнең күренә. 30 секундта! Эфирда буш сүз сөйләмәү – талант ул.

### Тел турында

Радиога килгәнче татарча яхшы беләм дип уйлый идем. Өйдә гел туган телдә генә аралаштык. Университетка кергәч, районнан килгән бер егет белән очраша башладым. Ул миңа смсларны да гел татарча гына яза иде. «Сәләт»кә барып эләктем – анда да татарча гына сөйләшәбез. Әмма мохит бар бит әле – шәһәрдә үскәч, дуслар белән барыбер күбрәк русча аралашырга туры килде. Тапшыру алып барганда шалтыратып: «Татарча җүнләп сөйләшә белмисең, утырма анда», – диючеләр булды... Ә мин үҗәт! «Күрерсез, үземнең өлкәдә иң яхшысы булачакмын!» – дидем эчемнән. Бүген инде теләсә кемне үзем татарчага өйрәтә алам. Мин – татар теле ни өчен кирәклегенең ачык мисалы. Алып баручылар арасында лидерлар рәтендә торам. Хөкүмәт дәрәҗәсендәге зур чараларны, бүләкләү тантаналарын алып баруны ышанып тапшыралар. Чөнки ике телдә – татарча да, русча да камил сөйләшәм. Аксак урыным – инглиз теле...

### Сәламәтлек турында

Сәламәтлегемә бик игътибарлымын. Каршыма берәр яшел әйбер куйсагыз һәм «файдалы» дисәгез, мин аны ашыйм. Ямьсез күренсә дә, тәмсез булса да... Файдалы әйбер дип үлеп китәм... Атнага өч тапкыр сулыш алу



■ Хатын-кызларның һәркайсы чибәр, аны ача белергә генә кирәк. Мин аларга ничек матур була алганнарын күрсәтәм, калганы – үз кулларында.

гимнастикасы ясыйм. Аны бөтен кешегә дә тәкъдим итәм. Минем әнкәй – мәрхүмә кайнанам... (*Телефоны шалтырый.*) Гафу, әнигә генә җавап бирим. Трубканы алмасам, беләсезме, нәрсә була?! (*Сөйләшә.*) Иртәгә улымның туган көне, аны чакырырга онытмадыңмы, моңа әйттеңме дип сорый. Әни мине гел контрольдә тота – онытa торган гадәтемне белә. Тапшыру төшергәндә администратор алам, «Гөлназ, онытмадыңмы?» – дип торучы... Әнкәйне сөйли идем. Вакуум гимнастикасы белән шөгыльләнә иде. Биш ел элек! Ул бит әле яңа гына модага кереп бара. Бу гимнастика белән мавыгучыларның каннарында кислород 100 процентка якын була икән. Ә бу – иммунитет дигән сүз. Әнкәй салкын тиюнең ни икәнен белмәде! Ничек сәламәт булырга дип әллә кайдан нидер эзләгәнче, тирә-юнеңә, якыннарыңа гына карарга кирәк: алар сирәк авырый икән, моның өчен нәрсә эшлиләр? Генетика – бер нәрсә, әмма үзеңне чыныктыру да мөһим. (*Телефоны шалтырый.*) Бигрәк үҗәт кеше булды бу... Әйе, тыңлыйм... Ә сезгә соңрак шалтыратсам буламы? Ярый... Гафу, мин телефонга береккән инде. Сүндереп кенә куйыйм әле...

### Режим белән яшәү турында

Мин – режим кешесе, ансыз яши алмыйм. Ул минем канга сеңгән. Безнең гаиләдә дә шундый тәртип. Кичә миңә әби шалтыратты: «Яңа пәрдәләр кирәк... Казанга

## Үз бәямне, үз мөмкинлекләремне ничек куллanyрга кирәген беләм. Әмма бу масаю түгел!

үзем киләм. Сишәмбе-чәршәмбе синең белән кибетләрдә йөрербез. Җомга көнне мине врачка яздыр. Ә шимбә кайтып китәм», – ди. Әни дә шулай, гаиләдә берәр бәйрәм булса: «Әйдә, план корабыз», – ди. Максатыңа ирешә алу – вакытыңны тиешенчә бүлә белүдән тора. Дәүләт структурасына эшкә алганда, иң беренче чиратта, тест биреп, юкка гына шуны тикшермиләр. Үзеңне дисциплинада тотуның бер юлы да бу.

### «Мин» тапшыруы турында

Тапшыру аша 150 хатын-кыз узды инде. Алар белән аралашудан бер нәрсәне аңладым: һәркемнең тормышы китап язарлык. Дөньяны акка һәм карага гына бүләргә ярамый. Бу кеше нигә аерылган, нигә баласын ташлаган дигәнче, ул узган юлны узып карарга кирәк. Аның итеген киеп! «Һәркемнең үз бәхете», – ди әни. Әйе, үз юлы, үз бәхете...

### Мәхәббәт турында

Мин беркайчан яратмаган кеше белән тора алмас идем. Беркайчан өйләнгән ир-ат белән йөри алмас идем. Беркайчан сөяркә була алмас идем. Мине алай тәрбияләмәделәр... Хатын-кызның көче – гаиләдә дип саныйм. Әмма шул ук вакытта романтик та түгелмен. Күрдем дә башымны җуйдым дип әйтә алмыйм. Гаиләдә төп яратучы кеше ир-ат булырга тиеш, минемчә. Хатын-кыз күбрәк яратса, аңа авыррак: ул бала тәрбияләүне дә үз өстенә ала, тормышны да тарта, иренә дә хезмәт итә...

Ленар миңа шунда ук: «Син минем хатыным булачаксың», – диде. Көлдем генә... Ә никах – насыйп ризык кебек икән ул... Никахсыз торырга миңа рөхсәт итмәячәкләр иде. Әйтеп карадым каравын... Куркып кына... «Алайса ике ел бала тапмаячакмын. Мин аның үземнеке икәненә ышанырга тиеш. Килеп чыкмый икән, аерылышам – кеше ни әйтер димәгез. Бала белән ялгыз каласым килми», – дидем әти белән әнигә. Ленар белән дә шулай килештек. 21 яшь иде миңа бу вакытта.

Ярый, никах укылды, туйлар узды. Без икебез дә көчле кешеләр – власть бүлешә башладык. Хәтта... сугышуга барып җиттек. Юк, юк, Ленар миңа кул күтәрмәде. Хәтерлим, кухняда утыра идек – икебез дә үз позициясен яклый. Ленар шунда кулындагы стаканын миңа таба атып җибәрде. Аз гына читкә тайпылып калдым. Стакан чәлпәрәмә килде... Бар да бетте, дип өйдән чыгып киттем. Әмма яшь парларга әйтәсем килә: мондый тарткалашу, «рольләр бүлешү» беренче ике елда бөтен кешедә дә була. Аннан курыкмаска һәм качмаска кирәк. Ни генә дисәк тә, гаиләдә төп кеше – ир-ат булырга тиеш. Беркайчан да ир-атның горурлыгына тияргә ярамый.

### Киңәшчеләр турында

Алар минем дүртәү. Беренчесе – әби! «82 яшьлек әбиеңә проблемаларыңны сөйләмәсәң инде...» – диләр. Тик ул бит аларны чишә! «Син мине ишетмисеңме әллә?» – дим мин аңа кайчагында. «Ишетмәм дә, миңа ничә яшь икәнен оныттыңмы әллә?» – ди ул. Оныттам шул... Аны үземнең яшьтәшем кебек кабул итәм. Әбидәге тормыш тәҗрибәсе, андагы интуиция! Ул китсә, минем белән нәрсә булыр, белмим... (*Елый.*) Әбидән соң төп киңәшчеләрем – әни, әти, ирем Ленар, Алма апай, сеңлем Айсылу... Хәзер инде улым Айдан да киңәшчеләр рәтенә кереп бара. Әти! Ә әти ул аерым тема, аның фикере минем өчен бик мөһим. Кечкенә чакта мин аны Президент булыр дип уйлый идем. Бөтен кеше өчен әтисе шулай үрнәктер инде... Әтием Минназыйм Сепперов – минем өчен дәрәҗә! Хәер, ул бөтен татар милләте өчен дәрәҗә.

Ирем Ленар белән бер-беребезне өйрәтергә яратабыз инде без. Әйе, мин дә аны өйрәтәм, эшендә берни аңламасам да... Дус кызларым арасында: «Ирең бөтен нәрсәне дә сөйләмә, минеке аерылганда шуларның барысын үземә каршы кулланды», – диючеләр булды. Ә мин ул барысын да белеп торырга тиеш дип саныйм. Ленар беркайчан да миңа начарлык эшләмәячәк дип уйлыйм. Ничек инде бу адымга барсын – ул бит минем кешем!

### Көнләшү турында

Миндә юк ул – бу яктан әнигә охшаганмын. Үземнең барысыннан да яхшырак икәнемне беләм. Ленарга да шулай дим... Хыянәтне кичерә алыр идемме дип уйлыйм кайчак. Физик яктан хыянәтне, мөгаен, кичерә алыр идем... Ир-атларны аңлап, аңлатып булмый бит аларны. Аннан хатын-кызлар да бик әрсез хәзер. Ә минә гашыйк була калса... Ул очракта мин көрәшә алмас идем...

### Өй турында

Әби сүзен гел әйтәм: гаиләгә кеше китертергә ярамый. Шуңа күрә аралашкан кешеләрем байтак булса да, бөтен нәрсәне сөйли алган якын дус кызларым юк. Танышлар арасында дус кызлары ирләрен алып киткән очраклар байтак булды. Башта бергә чәй эчеп йөрделәр, аннары... «Дус кызлар булмый», – ди әби. Ленар да шул фикердә.

### Оялу турында

Миндә «испанский стыд» бар – кеше өчен оялу. Кайчак радиодан берәрсен тыңлыйм да, җир тишегенә керердәй булып утырам... Ә үземнең оялуларны мәктәптә укыганда ук әни бетерде. Кайда нинди конкурс бар – ул мине шунда катнаштырды, аркамнан этә иде дә: «Бар, оялма!» – дип, сәхнәгә чыгарып җибәрә иде. Нинди генә түгәрәккә йөртмәде ул мине! Психологлар нәкъ шулай киңәш итә – баланы мөмкин кадәр күбрәк нәрсә белән булса да шөгыльләндерергә, җәлләмәскә: горизонтлар шулай киңәя. Әнинең аркадан этеп торуы аркасында кеше булдым да... Ә оялу... Уңышсызлыклардан курыкмыйм, шуңа кызармыйм да. Тик моны әрсезлек белән бутарга кирәкми – әрсез алабай түгелмен. Миндә туктальп калу, чикләр бар – ул әти-әни тәрбиясе белән кергән.



« Тулысынча укыгыз

### *Киенү турында*

Миңа килешмәгән киемнәр дә бар. Инстаграмда язылучыларыма вәгъдә бирдем: «Шуларны сезгә бер киеп күрсәтәм әле», – дидем. Җайлы киемнәр яратам. Матур күренәм дип кенә, салкында юка киемнән түзеп басып тормаячакмын. Туңгач, авырганымны беләм лә. Нәрсәдер капланып утырганымны фотога төшереп алсалар соң, иң мөһиме – миңа рәхәт, җылы... Гомумән, матур итеп киенеп кенә кеше матур булмый – ул киемне күрсәтә белергә дә кирәк әле. Стиль – ул эчтән килә.

### *Танылу турында*

Инстаграмдагы битемә 141 мең кеше язылган (*телефонын кабыза*). Карагыз әле, яңа гына 142 мең булдылар! Шундый артистлар бар: «Яныма килделәр дә, фотога төшерә башладылар, ярый әле күзлегем бар иде», – диләр. Масаючыларны яратмыйм! Берсенә әйттем, түзмәдем: «Карале, сине бит шул халык күтәрә», – дим. Әйе, бармак белән дә төртеп күрсәтәләр кайчак. Бик күңелле түгел инде, әмма аларны гаепли алмыйм. Миңа да кызык булыр иде. Әйтик, Казанга Мадонна килсә, аның кайсы кибеткә кереп, нинди бюстгальтер алганын, аягына нәрсә кигәнен мин дә күзәтеп йөрер идем.

Үз тамашачыңны, үз аудиторияңне хөрмәт итәргә кирәк. Мин үземнекеләргә беркайчан начар сүз әйттермим. Бер реклама бирүче: «Сезнең анда колхозчылар бит әле», – дип сүз башлады. Шундук бүлдердем: «Сезнең белән хезмәттәшлек итмәячәкмен. Аларны шулай атыйсыз икән, димәк, мин дә сезнең өчен колхозчы», – дидем.

### *Профессиональлек турында*

Миңа үз эшенең чын белгечләре булган кешеләр ошый. Андыйларга берсүзсез ышанам. Нәрсә кушсалар – шуны киям. «Татар җыры»нда: «Блондинка булырга кирәк», – дигәч, чәчемне дә буятканым булды... Тик, кызганыч, күпчелек өлкәләрдә бүген профессиональ булмаган кешеләр утыра, күп нәрсәне алар хәл итә. Нидер эшләгән кыяфәт чыгаручылар. Аларны мин әллә кайдан күрәм – шунда ук чыгырымнан чыгам. Әмма мине күбрәк сөяркәләр армиясе борчый. Бер зур көчкә әйләнделәр: үзләре очрашкан ир-атлар белән идарә итәләр. Алар җырлый белми, тик без көне-төне шуларны тыңларга мәҗбүр, чөнки ротация, акча салынган. Алар – инстаграм йолдызлары, үзләре эшләп тапмаган машина, йорт, фатир, кием-салым белән мактана. Интеллект юк, акыл, зирәклек юк... Бу хәл теләсә кайсы өлкәне, оешманы, компанияне тупикка алып бара. Моны күпләр белә, тик дәшми. «Сөембикә» аша шул ир-атларга мөрәҗәгать итәсем килә: сез бит шундый акыллы ирләр, биш тиенлек хатын-кызларга башыгызны әйләндерергә ирек бирмәгез инде.

### *Пандемия турында*

Дөнья хәзер башкача булыр дигәч, елмаеп кына куйган идем. Ә ул бит безне, чыннан да, үзгәртте. Моңа кадәр миндә дә гел чабу да чабу булды. Көнгә икешәр чара алып бардым... Хәзер күңел кушканны гына эшлим. Ярый моны шушы яшемдә үк аңладым. Әйе, иң мөһиме – күңел тынычлыгы... Бер дус кызымның яңа гына әтисе үлде. Ә алар ике ай аралашмаганнар иде. Сентябрьдә, туган көнендә араларны җайлармын дип уйлаган иде. Елый да елый хәзер... Шуның өчен якыннарны яратып калырга кирәк. Бу өч көнлек дөньяда берәүгә дә пакычлыклар эшләргә ярамый – барыбер кире үзеңә әйләнеп кайта. Ерак әбием сүзе монысы. Чын мишәр хатыны иде ул. Холкым белән мин аңа да охшаган...

### *Бала турында*

Әниләр ике төрле була. Бер ишләре баланы таба да, аның ничек үскәненә исе китми: вакытында ашаганмыюкмы, киеме чистамы-түгелме, температурасы бармыюкмы... Үсә бит ул! Мин икенче төркемгә карыйм: «Үтүкләгән трусы кидеңме?», «Тешеңне чистарттыңмы? Яхшы итепме?», «Чәчең таралганмы?, «Носкиеңны алыштырдыңмы? Тегесен юарга салдыңмы?»... Мин – педант! Идәнем һәрвакыт юылган булырга тиеш: чүп күрсәм – дөнья бетә... Шуңа күрә бер бала гына табам, икенчесенә көчем җитмәс дип уйладым. Әйе, мин эгоисттыр...

### *Планнар турында*

7–15 яшьлек балалар өчен телевизион мәктәп ачасым килә. Туплаган белемнәремне кемгәдер тапшырасы иде... Чын мәктәп булыр ул! Эшләп торучы журналистлар, профессиональ операторлар мастер-класслар уздырыр, үзем дәресләр үткәрермен. Аны тәмамлаучылар барысы да телевизион алып баручылар булырга тиеш дигән сүз юк. Яза, сөйләшә, аралаша белү – һәр өлкәдә кирәк әйбер: ул балаларга кечкенәдән салынырга тиеш. «Сөйләшә белгән кеше теләсә кем белән уртак тел таба», – ди әни. Мәктәп ачарга теләвем турында һичшиксез языгыз – сез язып чыккач, аны бит эшләргә кирәк булачак. Артка юл калмасын.

Гөлнур САФИУЛЛИНА





# ВИТАМИН МОДАСЫ

Яшь, чибәр, энергияле, көчле булырга теләүчеләр саны арта бара. Табибларның эштән бушап торганы булмаса да, бүген модада – сәламәт яшәү рәвеше. Күпләр моңа ирешүнең иң җиңел юлы – витаминнар куллану дип саный.



Раилә
ХӘЯЛИЕВА

### *A, B, C, D...*

Баш-аягым белән витаминнар дөньясына кереп чумдым. Халәтем шундый иде... Ә интернет киңлекләрендә тиз арада сәламәтләнергә булышучы, стресс, депрессияләрдән тартып чыгаручы нинди генә витамин комплекслары, БАДлар хакында язмыйлар! Кая караган мин моңарчы?! Проблемаларны шулай чит илдән кайтарылган микроэлементлар кулланып җиңел генә хәл итеп булганда, бер ай алдан язылып, аннан су буе чиратта утырып нишләп табибларга йөрелгәндер?! Аш бүлмәсендәге шкафның киштәсендә витамин савытлары күзгә күренеп арта башлаган иде, танышымнан хәбәр килеп төште: «Витаминнар эчәр алдыннан кайсы табиб белән киңәшергә кирәк икән ул?» Киңәшергә? Белмим... Витамин дару түгел лә... Мин күпләр кебек үк барысын да башкаларның тәҗрибәсенә таянып хәл иттем...

Ул кичне уйлана, фикерле торгач, үзем дә сизмәстән A, B, C, D дөньясы белән артык мавыгып китүемне аңладым. Әле ярый артык дозаларда кулланып, сәламәтлеккә зыян салырга өлгермәгәнен...

# Безнең организм витаминнардан башка яши алмый!

### *Витаминнар хикмәте*

«Вита» сүзенең латинчадан «тормыш» дип тәрҗемә ителүе юкка гына түгелдер. Безнең организм витаминнардан башка яши алмый. Кайбер витаминнарны организм үзе синтезлый, ә кайберләре ризык белән керә. Тарихтан билгеле, күп еллар элек C, $B_1$, $B_3$, D, фосфор, кальций җитмәгәнлектән килеп чыккан цинга, пеллагра, рахит авыруларыннан кырылган халык. Акрынлап витаминнарның мөһимлеген аңлый, өйрәнә һәм җитештерә дә башлаганнар. Ә хәзер табиблар кирәкме-юкмы икәнлеген ачыкламыйча, тикшеренмичә учлап витамин ашаучылар белән көрәшә.

Витамин эчү модасы XX гасырның җитмешенче елларында башлана. Биохимия атасы, Нобель премиясе иясе Лайнус Полинг «С витамины һәм салкын тию» дигән китап чыгара. Ул анда тәүлеккә 3000 мг C витамины кулланырга кирәклеге турында яза. (Тәүлеклек норма 30 тапкырга кимрәк.) Бу галим витаминның дәвалау көченә шундый ышана, ул аны хәтта СПИД, яман шеш белән авыручыларга да тәкъдим итә. Ә үзе көнгә 18000 мг C витамины куллана һәм 93 яшенә кадәр яши. Яман шеш авыруыннан вафат була. Соңрак башка галимнәр салкын тигәндә дә, яман шеш авыруларына каршы да C витаминын артык кулланудан әллә ни файда булмаганын исбатлый.

Америкада әле һаман да витаминнарны гипердозада эчәргә яраталар. Күбрәк булган саен, әйбәтрәк, имеш. Әйе, көчле витаминнарның файдасы юк түгелдер. Әмма моның сәламәт күренеш түгел икәнлеген дә белеп тору кирәк. Язмамның башында витаминнарны табиб белән киңәшеп кенә кулланырга кирәк дигән фикер узган иде. Игътибар итәсездер, бүген социаль челтәрләрдә үзләрен диетолог, нутрициолог дип атап, актив рәвештә туклану, витаминнар эчү буенча төрле курслар, марафоннар оештыручылар күбәйде. Коллаген тәкъдим итүчеләрнең генә дә исәп-хисабы юк! Барысы да аның файдасы турында гына сөйли. Сәламәтлеккә зыян салырга мөмкин булган яклары турында язарга әллә иренәләр, әллә... Сәламәтлекне кайгырту кебек бик җаваплы эшкә алынасыз икән, табибның да сыналганына, тәҗрибәлесенә тукталырга тырышырга кирәк.

Бу уңайдан журналыбыз сайтында эксперт буларак киңәшләр бирүче табиб-диетолог, нутрициолог Элина БОРҺАНОВА фикере:

– Медицина белемен раслаучы дипломы булмаган нутрициологларның кешегә нинди препаратлар билгеләргә хакы юк. Нутрициолог ул – дөрес итеп тукланырга өйрәтүче белгеч. Табиб-нутрициологлар гына кешенең физиологиясен белеп, организмдагы үзенчәлекләргә карап, кирәкле витаминнарны билгели ала. Витаминнарны кулланыр алдыннан һәрвакыт кан анализы аша үзеңә кайсысы җитешмәгәнне ачыкларга киңәш итәр идем. Беренче эш итеп, ферритин, аксымның үзләштерелүен, кандагы шикәрне, калкансыман биз эшчәнлеген, $B_{12}$, цинк, селен, бакыр, кальцийны тикшертеп карарга була. Безнең сәламәтлек нинди ризыклар кабул итүебезгә дә бәйле. Шуңа күрә беренче чиратта туклануны җайга салырга, зыян китерүче продуктлардан арынырга кирәк. Организмга һәрвакыт витаминнар кирәк булуы бәхәссез. Миннән кайвакыт витамин кулланып кына авырулардан дәваланып буламы, дип сорыйлар. Барысы да авыруның нинди булуына, организм үзенчәлекләренә карап хәл ителә. Күптән түгел генә гипотиреоз диагнозы куелган бер кыз мөрәҗәгать итте. Анализлар биргәннән соң, организмына селен һәм йод җитмәгәнен ачыкладык. Кирәкле витаминнарны билгеләдек, ашауны җайладык, һәм берникадәр вакыттан соң барысы да үз урынына кайтты, гормоннар кулланып торырга туры килмәде. Берәүнең бите бетчәләгән иде. Күпме генә тырышсам да, котыла алмыйм, дип килде ул. Бу очракта организмга цинк витамины җитешмәгәнлеге ачыкланды. Цинк кабул итә башлагач, бит тиресе чистарып, матураеп китте. Әмма, минемчә, бөтен эш витаминнарда гына түгел. Куанычлы нәтиҗәгә ирешер өчен һәрвакыт комплекслы эш алып барырга кирәк. Табиб билгеләгән витаминнарны да эчегез, физик күнегүләр турында да онытмагыз.

### *Яшьлектә калучылар*

Алсу исемле бер танышымның һәр иртәсе хлорофил яки лимонлы су эчүдән башлана. Аннан – сулыш гимнастикасы, 20 минут – медитация. Иртәнге ашы – йомырка тәбәсе белән ярты авокадо яки кокос сөте һәм суперфудлар кушылган җиләкле смузи. Һәм, әлбәттә, бер порция витаминнар! Алар төгәл бүленеп куелган: баш мие эшчәнлеге өчен микроэлементлар, спирулин, бакопа, магний, куркума, бетулин... Алсу кебекләрне биохакерлар дип атыйлар. Максатлары – табигать законнарын урап узу, картаймаска тырышу. Мондый принцип белән яшәүчеләргә төрле витаминнарга, дөрес туклану өчен кулланыла торган ризыкларга, тренировкаларга бик күп акча тотарга туры килә. Әмма алар арасында да берникадәр вакыттан соң гадәти тормышка әйләнеп кайтучылар еш очрый икән. Табигать үзен алдарга ирек бирми ул...

Безнең организм үзенә кирәкле витаминнарны табигый юл белән – ризыктан алырга җайлашкан, әлбәттә. Бүгенге шартларда химия кушып үстерелгән яшелчә, җиләк-җимеш ашаудан нинди файда булсын, дип бәхәскә дә керер кайберәүләр. Җиләк-җимешләрдә витамин составының шактый кимүе турында сөйли белгечләр. Авыл хуҗалыгы өчен сыйфат түгел, күләм мөһим шул. Кырлар ашлама белән туклана, без – шул кырларда үскән икмәк белән... Базарларда күзне кызыктырып ялтырап яткан яшелчәләрне безнең өстәлләргә бозмыйча алып кайтып җиткерү өчен җитештерүчеләргә аларны өлгермәгән килеш өзеп алырга, махсус препаратлар ярдәмендә «үстереп» бетерергә туры килә... Бар өмет дәү әниләребез бакчасында үскән җиләк-җимеш, яшелчәдә буламы инде?!

Фото: Анна Арахамия

PRESSA



# Белемсез килеш витаминнар киңәш итүчеләрдән сак булыгыз!

## *Витаминлы балачак*

Ватсабымда чит илдән витаминнар заказ бирүче кызлар теркәлгән төркем бар. Андагы әниләрнең активлыгын белсәгез! Кайдан шулкадәр мәгълүматны туплап, укып, истә калдырып бетерәләр диген. Чып-чын консилиум анда! Табибларның балаларга һәрвакыт игътибары җитеп бетмәү сәбәплеме икән, бу заманда һәр әнигә күп укырга, белешергә, бераз гына педиатр да булырга туры килә, нишләтәсең! Менә шул төркемдә әниләр еш кына балаларына D һәм омега, төрле мультивитаминнарга заказ бирә. Моны табиб кушканга карап түгел, «без кулландык, файдасы бар» дигән чит киңәшләрне тыңлап сайлауларына игътибар итәм. Үземнән беләм, балалар табибына баргач, витаминнар темасына сөйләшү бик кыска була, гадәттә.

– D витамины эчәсезме?

– Эчәбез!

Күпме микъдарда, ничек кирәк, кызыксынып торыш юк, барысы да – дару кабына язылганча. Нелли Сеидова ике дистә елга якын балалар табибы булып эшли. Һәр көне балалар һәм әниләр белән аралашып уза. Балаларга кагылышлы витаминнар турында аның белән дә сөйләшәбез. «Дөрес сайланып кабул иткән витаминнар матдәләр алмашы процессында катнаша, иммунитетны ныгыта. Бездә кояшлы көннәр аз, шуңа күрә табиб билгеләмәсә дә, профилактика өчен Д витаминын һәр балага эчерергә киңәш итәм. Әлбәттә, иң дөресе – кирәкле витаминнарны анализ биреп, табибтан билгеләтү. Кайвакыт бала еш авырый башлый, тырнаклары кителә, хәлсезләнә. Анализлар бала сәламәтлегендә башка тайпылышлар күрсәтмәсә, аларга витаминнар комплексы бирергә кирәк. Бала да, әни кеше үзе дә ризыктан гына кирәкле дәрәҗәдә файдалы элементлар алып бетерә алмый. Язгы, көзге һәм кышкы чорда балага витаминнар бирү комачауламый», – дигән фикердә ул.

## *Онлайн витаминнар*

Нигә витаминнарны чит илдән заказ биреп кайтартырга тырышабыз? Барлык витамин бергә җыелган комплекслар сайтта арзанрак та чыга, сайлавы да җайлы, кирәк икән өйгә кадәр китереп тә бирәләр. Бездә очрамаганнары да бар. Ә ник аларда витаминнар белән сәүдә итү шулай алга киткән?

Халкын сыйфатлы ризык белән туендыра алмау сәбәпле, Америка планетада беренче булып витамин җитештерә башлый. Россиядә исә витаминнар һәм БАДларның дозасын билгеләү буенча көчле контроль куелган. Югары дозадагы витаминнар дару сыйфатында сертификацияләнгән булырга һәм табиб рецепты белән генә бирелергә тиеш. Ә аларда илдә дару, витаминнар кабул итү буенча җаваплылык сатып алучылар өстендә. Бәлки Америкада ел саен 60 меңләп кешенең артык витамин кулланып, ашыгыч ярдәм хезмәтенә мөрәҗәгать итүе яки кайбер витаминнар аркасында яман шеш авыруларының арту факты да шуның белән бәйледер?! Без дә алар юлыннан китмәсәк иде.

Витаминнарны кулга төшерү җайлы булса да, аларның барысын бергә эчәргә ярамаганлыгын да белеп торырга кирәк, ди белгечләр. Мисал өчен, A һәм D витамины бер-берсен нейтральләштерә, $B_2$ һәм C витаминнары да бер-берсе белән туры килми, E витаминын D белән эчмиләр. Тимер кулланганда каһвә һәм кара чәй эчмәскә тырышалар. Авырлы вакытта организмда A витамины артып китсә – балада анемия авыруы килеп чыгу куркынычы бар. C витаминын артык кулланганнан соң, гиповитаминоз килеп чыгарга мөмкин... Сизәсезме, витамин эчүнең аерым бер фән икәнен?

...Минем киштәдә дә матур савытлы витаминнар кими башлады. Анализлар биргәннән соң, шактыеның бөтенләй кирәк булмаганлыгы ачыкланды. Башка юлдан киттем – «дөрес тәлинкә» кагыйдәсе буенча тукланам хәзер. Тәлинкәнең яртысын яшел тәмләткечләр, яшелчәләр, бер чиреген озак эшкәртелә торган углеводлар, икенче чиреген аксымга бай ризыклар (балык, ак ит, кузаклылар) белән тутырасың да тыныч күңел белән өстәл артына утырасың. Иң дөрес туклану – ризыкны төрләндереп ашау, ди диетологлар. Парда пешкән яшелчәләр, яшел тәмләткеч үләннәр... Помидор, кыярда – клетчатка, сырда – калий, кальций, ипидә – $B_1$ витамин группасы, иттә – тимер, балыкта омега, D витаминнары елмаеп тора әнә. Барысы да үзебезнең сый!



**Ленар КАШАПОВ, табиб-кардиолог, терапевт, «Сөембикә» журналы сайты эксперты:**

Чыннан да, витаминнар безнең организм өчен иң кирәкле элементлар. Бүгенге көндә аларның ниндие генә юк: хатын-кызларга, бала көтүче әниләргә, ир-атларга, олы яшьтәге кешеләргә... Эш шунда, тәкъдим ителгән витаминнарның барысы да безгә ярдәм итәме, витамин запасын тутырамы? Иң беренче чиратта, витаминнарның ничек ясалганына игътибар итәргә кирәк. Мисал өчен, организм синтетик витаминнарның 10% гына куллана дип әйтергә була. Табигый чималдан ясалганнарының файдасы күбрәк. Әгәр без дөрес туклансабыз, өстәлебездә һәрвакыт җиләк-җимеш (яңа өлгергәннәре), яшелчә, ит, диңгез ризыклары икән, поливитаминнар комплексының кирәге дә юк, дияр идем. Авыл кешесе табигатькә якын яши, аларга витамин эчәргә кирәкми дигән фикер белән килешмим. Кайбер авыруларны читләтеп үтәр өчен табиб билгеләгән очракта, һәркемгә файдалы ул. Иң мөһиме: табиб белән киңәшергә онытмагыз!

# ИРЕКЛЕ КОНЦЕРТ






Татар эстрадасы яшәргән! Әйе, әйе, пандемиядән соң җырчылар матурланып, көләчләнеп, күркәмләнеп киткән. Озакка сузылган аерылышудан соң, ниһаять, очрашканнарына да сөенә алар. Тамашачылары гына экранның теге ягында, әмма алар быел аеруча күп. «Барс Медиа Груп» беренчеләрдән булып җырчыларны җыйды – «Казан Экспо»ның Илһам Шакиров исемендәге концертлар залында «TMTV» татар музыкаль премиясенең V еллык тапшыру тантанасын үткәрде. Яңа формат – online концерт булды ул. Беренчедән, коронавирус таралу куркынычын булдырмады, икенчедән, республика халкы өчен катлаулы икътисадый вазгыять урнашуын исәпкә алып, билетлар сатудан баш тартты да масштаблы заманча эстрада музыкасы, уты һәм декорацияләр бәйрәмен бушка уздырды. Дөньяның теләсә кайсы почмагында яшәп, пижамадан гына диванга кырын ятып яраткан кешеләр белән бергәләп ял итү өчен менә дигән сәбәп булды кечкенә юбилей концертлары. Тамаша «TMTV» телеканалы эфирында һәм Youtube каналда трансляцияләнде. Аны 2 миллион тамашачы караган. Әлеге концерт шуның белән уникаль дә. «Тамашачы концертны кайда, кем белән карау мөмкинлеген үзе хәл итә, бу аңа ошый. Сүзсез генә ләззәтләнү, кушылып җырлау яисә хәтта кушылып бию... Концерт залында һәрвакыт чын-чынлап иркенәеп булмый, чөнки үз-үзеңне тоту кагыйдәләре бар. Ә монда тулы ирек. TMTV премиясен online форматка күчергәндә без нәкъ менә шуны уйлап эш иттек», – диде җаваплылыгы чикләнгән «Барс-Рекордс» җәмгыятенең үсеш һәм инновацияләр буенча директоры Динә Гәрәева.









Елның иң яхшы һәм иң популяр 36 җырчысына традицион статуэткалар тапшырдылар. Алар тавыш бирү юлы белән сайланды. Яшь башкаручылар күп. Зәринә Асылкаева, Эльвира Фазлыева арсен Камакаев, Айлин... Алар белән бергә Әнвәр Нургаелиев, Иркә, Гүзәл Уразова, Ришат Төхвәтуллин, Филүс Каһиров, Айдар Галимов, Зәйнәб Фәрхетдинова кебек татар эстрадасы йолдызлары да, Хәмдүнә Тимергалиева кебек олпат җырчылар да бар иде тантанада. «Пандемия дип тормыйбыз, җырлыйбыз, Аллага шөкер. Безнең халык гомер буе җырлаган. Зур бәйрәм бу! Болында чәчәкләр бик күп бит, һәрбер чәчәк үзенчә матур. Безнең артистларыбыз да шундый. Аларны бер болынга җыйган өчен «Бар Медиага» рәхмәт», – ди Хәмдүнә апа. Җыр бәйрәме бар икән, димәк, яшибез!

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА



PRESSA






**Сәлимә апа... Яраткан укытучыбыз, якын дус кызыбыз кебек күргән сердәшебез, укучыларының кумирына әйләнеп киткән апабыз... Мәктәп елларын искә төшергәндә мин генә түгел, күпләр иң беренче аның исемен әйтәдер. Алай гынамы! Сәлимә апа дигән бик шәп укытучыбыз барын инде университетта бергә укыган дуслар да, бергә эшләгән хезмәттәшләр дә белә. Аның турында математика укытучыбыз дип әйтү генә аз булыр иде. Спортсмен да ул: чаңгыда узышу буенча район һәм шәһәр чемпионы, йөзү буенча өч ел рәттән районда җиңеп, Казанда республикакүләм «Өлкән буын» ярышларында Актаныш данын яклаган, туризм буенча Бөтенроссия ярышларында катнашып, спорт мастерлыгына кандидат нормативларын тапшырган... Йөгерү, теннис, велосипед, мылтыктан ату, шахмат та аныкы... Фото, техника, сәяхәтләр тагын... Гармунчы да, җырчы да... Сәхнәдә ул уйнаган рольләр исә үзе бер тема...**











Эльмира ЗАКИРОВА

# БЕЗНЕҢ АПА – ЧЕМПИОН!

Чаллыдагы милиция мәктәбе, елгачылар лицее, яшь диңгезчеләр үзәге, кадет мәктәбе... Ә форма ничек килешә аңа! Погонлы педагог дип тә йөртәләр әле үзен...

Гомер юлын Актаныш, Алабуга, Байсар, Чаллы, тагын Байсар чорларына бүлеп карый башласаң, Сәлимә Борһан кызы Якупова турында матур фильм төшереп булыр иде! Ул кайда да чемпион пьедесталында!

### *Хәтерлим мин әле бүгенгедәй...*

Мәктәбебезгә яңа укытучы килгән! Исеме Сәлимә икән. Алгебра, геометрияләрдән керәчәк, безнең 10 нчы «А» ның класс җитәкчесе дә булачак ди. Күрше Богады авылыныкы, Алабугадан быел гына институт тәмамлап кайткан, үзе спортсмен икән дигән хәбәрләр дә килеп ирешә. Бераз тәкәббер, баш бирмәс классыбыз сынап-сагаеп күзәтә башлады. Исеме дә, үзе дә яңа, ят тоелды. Беренче мәртәбә аны каскадан, стройотряд костюмыннан мотоциклда күреп телсез калдык!

Ә беренче сентябрьдә инде килешле итәк-костюмнан классыбызга керде. Озын буйлы, талчыбыктай зифа гәүдәле... Чәчен гаврош итеп кистергән... Кырыс, таләпчән күренә...

**Сәлимә апа сөйләгәннәрдән:**

Байсар мәктәбенә очраклы гына килдем. Ижау кызы Вәсилә белән бер курста укыдык, икебез дә чаңгы буенча институтның җыелма командасында идек. Икәүләп бер үк авыл мәктәбенә укытырга кайтабыз дип планнар кордык... Актаныштa РОНОда чират торабыз. Коридор тулы халык! Чират урамга кадәр сузылган. Мин практика үткән Киров мәктәбенең директоры Хәнәфи Гәрәевич узып бара. Күреп алды да җитәкләп диярлек алып кереп китте РОНО мөдире Әхсән Шакирович кабинетына. Ә анда Байсар мәктәбе директоры Басыйров абый да утыра булып чыкты. Мәктәпкә физика-математика укытучысы кирәк икән. «Үскәнем, чыгып тор әле», диделәр дә, үзара килешкәннәрдер инде, мине Байсар мәктәбенә билгеләделәр. Вәсилә Богадыда калды. Гомердә күргәнем юк иде Байсарны – 15 августта матайга атланып танышырга киттем. Ул авыл кызлары Рәзинә, Наиләләр белән Алабугада бергә укыдык. Монысы Мәктәп урамы, монысы Урта җыен урамы дип, әллә нинди урам-тыкрыкларда йөрттеләр. Менә монысы Мәүҗидә апа өе, син шунда фатирда торачаксың, дип тә әйттеләр әле. Һәм шулай булып та чыкты.

Исем дигәннән... Мин 1950 елның 1 сентябрендә Иске Богады авылында туганмын. Ул елны сентябрь башында ук кар яуган. Авырлы хатынын, балаларын калдырып әллә кайдагы чит өлкәгә урып-җыюга баруга каршы төшкәне өчен әткәйне Минзәлә төрмәсенә утыртып куйганнар. Әнкәй берүзе бәрәңге алырга чыккан. Олы апам Дәнфирә беренче класска укырга кергән мин туган көнне. 3 яшьлек Дәния апам ишекне ача да: «Балаң елый – кер!» – дип, туктаусыз чыга да кычкыра икән. Чөнки исеме юк бәбинең. Ә әнкәй, өй мәшәкатьләренә күмелеп, авыл советына исем куйдырырга бара алмый. Бер көнне әткәйнең энесе Мирас абзыкай кергән, балага исем куйдыгызмы, дип сорый икән. «Юк, апаем, юк, һич җитешә алмаем. Барып куйдырып кайтчәле», – дигән әнкәй. Мирас абзыкайның хатыны Шаһидә җиңгәчәй: «Сәлимә куйсак ничек булыр, әнисе Сәкинәгә дә якын исем», – дип, минем язмышны хәл иткән. Мин бик шат бу исемгә! Сау-сәламәт дигән мәгънәне аңлата ул! Аллага шөкер, сәламәтлегемнән зарланмыйм, һәр көнемне файдалы итеп үткәрәм.

Бер кызыклы вакыйганы әле хәзер дә көлеп искә төшерәм. Беренче яртыеллыкны йомгаклар вакыт җиткән, ә минем өлгереш буенча һаман отчетлар тапшырылмаган. Ярар, дәрестә төзермен әле, дим. Унынчыларга дәреснең планын аңлаттым да, Шәрипов Азатны такта янына чакырдым. Ул теорема сөйләгән арада отчет әзерләргә керештем. Бер колак белән укучымны тыңлыйм, сораулар бирәм. «Дүрт»ле куйдым, икенчесен чакырдым. Үзем отчет язам. Инде ярты дәрес узып бара шулай. Өй эшләрен тикшереп, парта араларыннан үттем. Дәфтәрләре ачып куелган. Тын гына утыралар... Икенче рәткә күчтем. Арткы партада берсенең дәфтәре юк бит. «Дәфтәрең кайда?» дип күтәрелеп карасам... мәктәп директоры Басыйров абый! Дәресемә кереп утырганын абайламый да калганмын. Каушауны белгертмәдем инде. Кыңгырау шалтырауга, җиңел сулап куйдым. Ә укытучылар бүлмәсенә кергәч, директор мине мактады: чып-чын дәрестә утырдым, диде! Шуннан бирле иң элек классны күздән кичерә торган булып киттем. Берәрсе кереп утырмасын тагын.

### *Сез иң гүзәл кеше икәнсез!*

Башта куркып, шикләнеп кабул иткән апабыз әллә ниләр уйлап таба, безнең белән волейбол да

## И, аны Актаныш белән Байсар гына түгел, бөтен Чаллы белә! Сокланалар, яраталар...

уйный, кич кинога культпоходлар да оештыра, фотога да төшерә, чаңгы шуарга да алып чыгып китә... (Чаңгы ярышларында 8 км дистанциядә Алабуга шәһәре чемпионы булган Якупова бит ул!) «Их, Сәлимә апа кебек матайда очып кына йөрсәң иде ул!» – дип кызыгып, малайлар да соклануын яшерми. Дәрестә үзен бик коры тотса да, класстан тыш чараларда гел үз тиңе итеп карый безгә. Яшь тә бит әле! Бездән дүрт-биш яшькә генә зуррак. Шаян, юморлы, күп белә. Башка классларга йолдызлар, галактика турында бик кызык әйберләр сөйләгәнен ишеткәч (ул аларны астрономиядән укытты), көнләшеп үлә яздык. Сәлимә апа институтта укыганда дүрт ел буе астрономия түгәрәгенә йөргән, фәнни конференцияләрдә чыгышлар ясаган икән бит! Без, кызлар өчен ул якын дуска ук әйләнде берзаман! Кичләрен авыл өстендә тын гына балкыган Киек каз юлы яктысында киләчәк турында хыялланып йөрибез. Врач, укытучы, журналист булабыз дип, укытучыбызга серләребезне чишәбез. Ул үзе дә романтик. Актаныш мәктәбендә укыганда ярышларда гел беренче урынны алып кайткан кыз спорт юнәлешеннән китәргә, физкультура институтына барырга хыялланган. Берара геолог булам дип йөргән. Валерий Чкаловка сокланып, Вениамин Каверинның «Два капитана»сыннан илһамланып, очучы булу турында да уйланган. «Әнә апаң укыган җиргә – Алабугага барырсың, диде дә әнкәй, шунда киттем. Дәния апам кебек укытучы юлын сайладым. Үкенмим», – диде ул.

Сәлимә апа яшәгән фатирдан ике атлап бер генә сикерәсең – Сөн инде аяк очында. Шуңадыр, майның җылы көннәрендә ул иртән мәктәпкә килгәнче үк Сөндә йөзеп тә чыга әле! «Безнең апа менә шундый ул!» дип, башка класслар алдында борынны чөябез. Үзебез дә сизмәстән, Сәлимә апаны ярата башлаган идек инде. «Сез иң гүзәл кеше икәнсез» дигән җыр бигрәк туры килеп тора аңа! Якын итүләребезне, аңа охшарга тырышуларыбызны үзе сизә микән? Классташыбыз Гөлшат бер маҗара уйлап тапты. «Әйдәгез, кич белән Сәлимә апаның баскычына чәчәкләр куеп калдырабыз», – ди. Караңгы төшкәч, киттек Түбән оч буйлап. Капка төбе саен – чәчәккә күмелгән янбакчалар. Камил каравыл тора, Гөлшат сиреньнәр мутый, Әлфия белән мин лаләләр өзәбез... Юк, искәрмә рәвешендә булса да, урлашу түгел бу. Ниятебез изге бит. Кеше-кара күргәнче, сулы банкадагы чәчәкләрне сак кына куеп калдырабыз да өйләргә йөгерәбез. Ә укытучы апабызның уты һаман яна әле...

**Сәлимә апа сөйләгәннәрдән:**

Тормышта миңа гел яхшы кешеләр генә очрады. Беренче укытучым Мәгъфия апа Шәехҗанова гармунда уйнап, биетеп-җырлатып, походларга алып чыгып китеп, күп нәрсәгә өйрәтте. Башлангыч класста укыганда җәяүләп ике көнлек походка бардык. Яңа Жияш, Каратал, Яңа Богады, Солтангол, Иске Әлем, Аешларны үттек, Сөн тамагына җиттек. Дөнья белән танышуым шулай башланды. Яши-яши илләр күрдем, дөнья гиздем. Мәскәү, Питерлар, Төньяк Кавказ, Идел буе шәһәрләре... Мисыр, Болгария, Венгрия, Югославияләр... Кызыл диңгездә, Кара диңгездә, Каспий, Азов, Балтыйк диңгезләрендә, Әдрән диңгездә йөзгәнем бар. Нинди генә укытучылар укытмады мине! Шуларның үрнәге мине дә укытучы булырга әзерләгәндер. Математика укытучыларым Рәйсә апа Насыйрова, Мәсгудә апа Латыйпова, рус теле укытучым Хәния апа Гыймазова, класс җитәкчем Нурдидә апа Музаһитова... Институтта астрономиядән фәнни җитәкчем, укытучым Александра Григорьевна Юлкина, чаңгы буенча тренерым Дмитрий Иванович Марфин, мәктәп директорым Миргалим Гыйлемович Басыйров һәм башка бик күпләр...

Әткәем Борһан белән әнкәем Сәкинәгә рәхмәтле мин. Әткәй гомер буе механизатор булды, авылның беренче тракторчысы иде. Белмәгән эше юк: электрик та, балта остасы да, мич чыгаручы да, киез итек басучы да, сәгать төзәтүче дә ул... Әнкәй безнең бик чая, матур җырлый иде, спектакльләрдә Галиябануны уйнаган... Әнкәй – әтисенә, мин әнкәйгә охшаган. Әткәйнең әтисе Якуб Җаббар улы хаҗга җәяүләп барган кеше, әнисе Таифә – Иске Богады мулласы Мөхәммәт хәзрәт кызы. Ә әнкәйнең әтисе Хәсәншәех Халиков – указлы мулла, Иске Солтангол авылында мәдрәсә тоткан, балалар укыткан. Совет власте чорында репрессияләнгән. Авыл җыенында халык өч тапкыр алып калган аны. «Ничек хәл итәсез, Хәсәншәех мулланы сөргенгә җибәрәбезме?» – дип сорый икән староста. «Юк-юк, калдырабыз, аның өе тәтәй дә, хатыны чибәр, бүтән бер байлыгы да юк», – дип каршы төшкәннәр. Авыл халкы каршы булгач, 1930 елда төнлә урлап киткәннәр аны. Һәм ул Мурманскида вафат булган. Аны бик укымышлы, белемле иде дип сөйлиләр. «Әткәй алтын хәрефләр белән язылган китапларын сыпырып утырыр иде гел. Үзем үлгәч, кайларда исраф булып ятарсыз микән, дип и жәлләр иде», – дип, әнкәй гел искә ала торган иде. Әбкәй үлгәч, ул китапларны капчыкка тутырып, аның каберенә салганнар. Әбкәем Нурдидә абыстай – Бикбау авылыннан Әхнәф мулланың төпчек кызы Хәсәншәех хәзрәткә дүртенче хатын булып килгән. Әнкәй ягыннан мулла нәселеннән без. Әбкәй мине бигрәк ярата иде.

Изге теләкләрен теләп үстерде. Бабкай белән әбкәйнең сигез бала булган, шуларның икесе – әнкәй белән Хөмәйрә апа гына исән-сау үскән. Сталин чорында сөргеннәргә сөрелгән туганнарның язмышы бик гыйбрәтле. «Зөләйха күзләрен ача» киносын караганда гел үзебезнекеләрне уйлап утырдым. Халиковлар нәселенең каберләре бөтен Рәсәй буйлап сибелгән. Кайсы Хабаровск краенда, кайсы Мурманскида, кайсы Казакъстанда... Хәсәншаех хәзрәтне алып киткәч, әбкәйне сигез баласы белән өеннән куып чыгарганнар, землянка казып торганнар. Аларның өч өйләре булган. Берсен – авыл советы, берсен – мәктәп, берсен клуб иткәннәр. Әллә кайда еракларда туган оныклар исә татарча белми үскән инде. Әбкәй үзе исән чакта аларны Салих, Ганиф, Галимә дип йөртте, ә алар чынлыкта Сережа, Геннадий, Галина булып чыкты...

Бабамнар авылда мәдрәсә ачкан кешеләр. Гаиләбезнең укытучылык династиясе шуларга барып тоташа. Бездә 11 педагог. Апам Дәния, сеңлем Әнисә, Әнисәнең, энебез Азатның балалары... Педагогик стажыбыз 200 елга якын.

Үземнең укытучы икәнемне мәктәптә генә түгел, урамда да, өйдә дә, ялда да, кунакта да гел истә тотам. Үчле булмадым, көнләшмәдем. «Ачу тотма, ул бит сине эчтән кимерә... Үткәреп җибәр, гафу итә бел», – дип өйрәттеләр мине. Әйткән сүземне үтәргә тырышам. Иң яратмаганым – сүзендә тормаган кеше.

### *Хыяллар – ак җилкән...*

Тәки безнең авыл килене булды ул! Марат абый Моглиев белән өйләнешүләренә дә быел инде 40 ел. Кызлары Чулпан Алабуга пединститутының чит телләр факультетын тәмамлап, Мәскәүдә, Аэрофлотта стюардесса булып эшли. Уллары Алмаз – архитектор. КИСИ тәмамлаган. Чаллыда байтак мәчетләр, йортлар, кибетләр аның проекты буенча салынган. Инде хәзер Алмаз гаиләсе белән Мөслимдә яши. Мөслимнең Ык буендагы атаклы ял паркын күргәнегез бармы? Алмаз проекты буенча эшләнгән! Хатыны Миләүшә белән биш бала үстерәләр. Ибраһим, Габдрахман, Мөхәммәт, Сәйдә, Давыт... Болары – яраткан оныклар!

Гомер китабының Чаллы битләре тагын да баерак, кызыклырак. Марат абый КАИны бетергәч, КАМАЗның фәнни-техник үзәгендә инженер булып эшли. Сәлимә апа укыту-производство комбинатына завуч булып урнаша. Электротехника, информатика дәресләрен алып бара. Ул елларда фотоаппарат асып, бөтен Чаллы оешмалары белән танышып йөрүләрен көлә-көлә искә төшерә. Аннары инде хыялларын ак җилкән итеп, чын җилкәннәр сыналган җиргә – диңгез моряклары, капитаннар булырга әзерләнгән малайларны укытырга килә: Елгачылар лицееның укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары була. Бераздан – Яшь диңгезчеләр үзәгенең методика бүлеген җитәкли, 82 нче кадет мәктәбендә физика һәм астрономия укыта. Аның 30 дан артык укучысы хәрби вузларга укырга керә: Рязань десант, Санкт-Петербург хәрби-диңгез институтларын, башка хәрби уку йортларын тәмамлап, РФ Оборона министрлыгының истәлек билгеләренә лаек булган, Батырлык ордены белән бүләкләнгән укучылары бар.

**Сәлимә апа сөйләгәннәрдән:**

Курсантлар хәрби диңгез формасыннан йөри иде, алар флот традицияләрендә тәрбияләнделәр. Нинди генә махсус фәннәр укытылмады монда! Диңгез музеебыз үзе генә дә ни тора! «Шлюпка старшинасы» белгечлеге алган егетләр белән бергә җилкәнле, ишкәкле шлюпкаларда Кама, Идел буйлап ерак походларга йөрдек. Безнең лицейны тәмамлаучылар Мәскәү, Түбән Новгород диңгез академияләрендә, Санкт-Петербург хәрби-диңгез институтында укуларын дәвам итте. Каспий, Балтыйк, Кара диңгез флотларында хезмәт иттеләр. Ә Андрей Мерзляков дигән укучым Каспий диңгезе флотилиясендә хәрби корабль капитаны! Дмитрий Константинов һәм Илдар Вәлиуллин Россия диңгез ВУЗларының Мактау китабына кертелделәр. Алар лицейда укыганда физика һәм астрономия буенча призлы урыннар яулыйлар иде. Рәдиф Гатауллин һәм Алексей Скубенко Батырлык орденына лаек булдылар. Лицейда 12 ел эшләдем. «Бар иде шундый лицей...» дип истәлекләр язасым килә әле...

* * *

Сәлимә апалар Байсарда яши хәзер. Ул һаман актив. Тынгысыз, шат күңелле – авылның җаны кебек! Әле «Җәүһәр» фольклор ансамбле белән авылларда концерт-спектакльләр куеп йөриләр, әле кыңгыраулы атларда, гармуннар белән Сабантуйга бүләкләр җыялар, әле егетләрне армиягә озаталар. Сәлимә апа йөзү буенча өч ел рәттән инде район чемпионы. Ул – чаңгыда, ул – велосипедта, ул Сөндә йөзә. Чәчәкләр үстерә. Шахмат, фото, мәктәп, физика дәресләре, клубта репетицияләр... Без – Сәлимә апаның унынчылары – көн саен диярлек ватсапта аралашып яраткан укытучыбызның хәлләрен дә белеп торабыз. Фотоларын да күрәбез.

«Сәлимә апаны таныдыгызмы? Нинди чибәр егет дисәм... «Беренче театр»да Фатихны ул уйнаган бит!»

«Безнең апа – супер!!!»

«Сәлимә апа – репетитор! Укучыларны институтка әзерли!»

«Сәлимә апаларга кереп чыктым. Шундый тәмле бәлеш пешергән!»

Ә мин барыбыз исеменнән дә менә шушы сүзләрне язып куйдым:

«Сәлимә апа! Туган көнең – күркәм юбилееexcellent белән котлыйбыз! Һәрчак шулай яшь, ягымлы, тынгысыз булып кал! Җаныңа хуш килердәй күңелле мәшәкатьләргә күмелеп яшә! Яратабыз! Сагынабыз! Күрешүләр көтәбез!»

# «БЕР ЯХШЫЛЫК ЭШЛӘП КАЛЫРГА...»

Мәдинә АВЗАЛОВА

**Үз-үзеңә ышану ул – талант, дигән бер акыл иясе. Шулайдыр. Бары үзенә ышанган кеше генә максатына ирешә. Юлындагы киртәләрне дә, катлаулы-текә борылышларны да сизми ул. Хезмәт юлын гап-гади бер слесарь булып башлаган егетнең тиз арада, үзе әйтмешли, күз ачып йомганчы, өч институт тәмамлап, цех начальнигы, партоешма секретаре, районның халык контроле комитеты рәисе, аннары район советы депутаты булуын ничек аңлатырга башкача?! Бүген ул – Гарәфетдин Миннегазиз улы ХИСАМЕТДИНОВ – республиканың танылган шәхесе, үз эшенең, үзе яшәгән җирнең патриоты. Хөкүмәт бүләкләренә, ВДНХның бронза медаленә лаек. Үз төбәгендә мәдәни мирасны торгызу өчен барын да эшләргә әзер ул.**









**ТАМЫРЛАР** Мин тумышым белән Кукмарадан. Биш балалы гаиләдә үстем. Әтием Миннегазиз Хисаметдинов Герман сугышыннан II группа инвалид булып кайткан. Ул, мин беләбелгәннән, гомер буе тимер юлда эшләде. Әнием Хәбирә бик уңган кеше иде. Кулыннан килмәгән эш юк та кебек иде аның: ул оста пешекче дә, ул оста тегүче дә, мич чыгаручы да... Ул «Ана даны» медаленә лаек хөрмәтле ана да...



**УКУ** Бер караганда, тормыш юлым башкаларныкыннан әллә ни аерылып тормый да шикелле. 1 нче татар мәктәбендә сигезенче сыйныфны тәмамладым. Әйбәт укыдым, теләп, бик яратып укыдым. Алга таба да белем алырга ниятем бар иде, тик әти: «Сине укытырга мөмкинлегем юк», – дип, мине – 14 яше дә тулмаган малайны Ижаудагы һөнәр училищесына илтеп куйды. Русча начар белә идем, дәресләрдә яртысын аңлыйм, яртысын аңламыйм... Телне өйрәнгәнче, начар укыдым. Ә инде ярты еллап вакыт узганнан соң төркемдә иң яхшы укучылар рәтендә йөри башладым. Ике елдан соң училищены гел «бишле» билгеләренә генә тәмамладым. Һәм, эшне озакка сузмыйча, Казанга җибәрүләрен сорап, училище директоры янына кердем. «Минем укыйсым килә», – дидем.

Һөнәр үзләштерүен үзләштердем – слесарь-җыючы булдым. Ә менә урта белем турында аттестатны Казанга килгәч, имтиханнарны экстерн тапшырып алырга туры килде. «Һөнәрең болай да әйбәт, юкка мәшәкатьләнәсең», – диючеләр дә булды. Тик мин үземә нәрсә кирәген яхшы белә идем инде.



**УҢЫШЛАР** Ул чагында даны еракларга таралган «Урак һәм Чүкеч» заводында гади слесарь булып эшли башладым. Аннары авиация институтына укырга кердем. Институтка керүе авыр булмады. Нишләптер миңа барысы да җиңел бирелә торган иде... Институтны тәмамлагач, башта мастер, аннан соң цех начальнигы итеп куйдылар. Ә тагын бераздан... шул заводның партоешма секретаре булдым. Аннан – районның халык контроле комитеты рәисе... Ничектер, барысы да күз ачып йомганчы! Өстәвенә, унөч ел Казан шәһәренең Киров районы Советы депутаты булып та тордым, ун ел буена Адмиралтействодагы депутатлар берлеген җитәкләдем. Үз гомеремдә өч институт тәмамладым. Финанс-икътисад институтында да белем алдым. Шуңадырмы, «Заречье» банкында, «Сбербанк»та рәис урынбасары вазыйфаларын үтәү авыр булмады. Соңгы унбиш елда үзем оештырган «Татипотека-Үзәк»не җитәкләдем.

Ләкин иң зур эшем дип үзем гомер иткән җирне шәһәрнең гүзәл бер почмагына әверелдерү, тарихи истәлекләрне яңарту, килгән кунакларны җәлеп итәрлек урыннар булдыруны саныйм. Бер сүз белән әйткәндә – яшәгән җиремнең мәдәни-тарихи мирасын торгызу белән шөгыльләнәм.

Чишмә башы унынчы гасырларга барып тоташкан Бишбалта бистәсенең Казан шәһәре өчен зур кыйммәткә ия тарихи урын булуын бөтен илгә белгертәсем килә. Кайчандыр республиканы дөньяга танытып, шаулатып-гөрләтеп торган корылмаларның күбесе хәзер бөтенләй юк, кайсылары җимерек хәлдә. Әйткәнемчә, районның чишмә башы булган Бишбалта бистәсе халкы заманында берсеннән-берсе җитди вакыйгаларның шаһиты булган: Казан ханлыгы барлыкка килүе, 1552 елда Зөя утравы ягыннан йөзеп килгән Иван Грозный гаскәренең Казанны басып алуы, дары заводында булган ике зур шартлау, 1918 елда Колчак һәм ак чехларның Казанга зур зыян салуы... Россиянең бөек реформаторы Петр I дә, биредә яшәүчеләрнең агач эшенә осталыгын күреп, Бишбалтада Адмиралтейство төзү турында Указ чыгарган. Шул чагында барлыкка килә дә инде Татарстанда машина төзелешенә нигез салучы «Урак һәм Чүкеч» заводы, җитен комбинаты, күн артеле һәм башкалар, һәм башкалар...

Кайчандыр республиканың таянычы-терәге булган, сугыш чорында шартлаткычлар, снарядлар, сапер кирәк-ләренә кадәр җитештергән, атом бомбасын уйлап тапкан бөек галим И. В. Курчатов эшләгән «Урак һәм чүкеч» заводы да, шулай ук җитен комбинаты, күн эшкәрту артеле дә... юк инде бүген. Миңа ул корылмалар урынында чүп үлән үскән бушлык булуын күрү бер дә җиңел түгел. Заводта эшли башлаган вакытларны гомер онытасым юк. Ул минем өчен үзенә күрә бер чынығу мәктәбе, канатларны тагын да киңрәк җәеп очу өчен сынау мәйданчыгы булды. Заводта эшләгәндә йомычка җыю конвейеры ясауда катнашып, ВДНХның бронза медаленә лаек булдым. Аннары реконструкция башланды. Бу мәшәкатьләр янә минем җилкәгә төште. Партоешма секретаре булып эшләгән чорлар иде ул. Яңа цехлар, ЧПУ-станоклар барлыкка килде. Беренче мәртәбә халыкка күп катлы биек йортлар, тулай торак, балалар бакчалары сала башладык. «Биредә кече Пицунда булыр», – дип хыялландык. Без җитештергән товарлар, шул исәптән канат юллар да Вьетнам, Куба, Болгария, Югославия илләренә озатыла башлады. Заводның 130 еллыгына музей ачтык. Реконструкциянең уңышлы тәмамлануын билгеләп, 1984 елда Советлар Союзы күләмендә «норматив-чиста» продукция җитештерү буенча семинар үткәрелде. Мин дә шунда катнаштым.

Һәм... бер көнне гөрләп торган завод эшләүдән туктады. Ул урында «Адмирал» базары эшли башлаган иде дә... соңыннан анда янгын чыгып, бинасы көлгә әйләнде.



**ДИН** Халык контроле комитеты рәисе булып эшли генә башлаган чагым. Яныма бер төркем картлар килде. «Син татарча белә торган кеше. Безнең кеше... Безгә мәчетне кире кайтарырга булыш», – дип, гозерләрен җиткерделәр. Вәгъдә биреп калдым. Вәгъдә бирсәм, үтәми кала торган гадәтем юк. Чыннан да, ул бинада элек мәчет булган. Башта җитен комбинаты директоры белән сөйләштем. Бина ул вакытка аның карамагында иде. Аннан соң партия район комитеты беренче секретаре белән... Сөйләшүләр алып бара торгач, кайтарырга кирәк, дигән уртак фикергә килделәр. Рәҗәп мәчетенең ишекләре шулай итеп кабат ачылды. Рамазан, Колшәриф мәчетләрен салганда да хәлемнән килгәнчә матди ярдәм күрсәттем. Саный китсәң, күп инде андый эшләр.

Фото: Анна Арахамия



**ХӘЙРИЯ** Кайчандыр шушы бистәдә татар хатын-кызлары гимназиясе эшләгән. Берара ул Вертолет заводының училищесы булып алды. Бинаны кире кайтару, анда татар гимназиясе булдыру өчен күп көч түгәргә туры килде. Бүген анда Фәнит Харисов җитәкләгән 15 нче татар гимназиясе урнашкан. Монда тарихчы-галим Дамир Исхаков, укытучылар, укучылар көче белән тарихи музей ачылды. Төбәк тарихына кагылышлы бик күп материаллар тупланды. Алар бүген ул кечкенә музейга гына сыеп та бетми. Хыялым – аерым музей төзү. Янәшәдә генә иске йортны сүтә башладылар: шул бинаны гимназиягә бирмәсләрме дим. Инде җитәкчеләр белән сөйләшә дә башладым. Ниятләгән эш кайчан да бер килеп чыга ул… Гимназия укучылары белән араны өзмим. Без гел элемтәдә. Менә инде ничәнче ел рәттән гимназиядә, бөек шагыйребез Габдулла Тукайның туган көненә багышлап, Бишбалта бистәсе тарихын өйрәнү максатында укучылар арасында бәйгеләр уздырабыз. Җиңүчеләрне акчалата бүләклим. Яшәгән җиреңне яхшырак белү өчен анысы да үзенә күрә бер шәп кызыксындыру чарасы бит. 1993 елда Рафаэль Мөхәммәтдинов белән бергә балалар өчен дүрт мең данә рус-татар-төрек сүзлеген бастырып чыгардык. Спонсоры үзем булдым.



**АКЧА** 2013 елда Адмиралтейство бистәсенең 300 еллыгын билгеләп үтү турында карар чыкты. Шунда уйлана калдым. Бу вакыйганы мин, шәхсән үзем, нинди эшләрем белән истә калдырырлык итә алам? Шулай итеп, Бишбалта осталарына һәйкәл куюь, аларның исемен мәңгеләштерү уе белән яши башладым. Барысы да шул алтын куллы балта осталарыннан киткән бит инде: алар йортлар салган, агач суднолар, йөзү җайланмалары эшләгән, Кремль эчендә агач корылмалар салуда катнашкан…. Бу якларның тарихы алар исеме белән бәйле.

Шуннан китте инде эзләнүләр... Бу җитди эшкә теләсә кем алына да алмый бит әле. Кемнәргә генә мөрәҗәгать итмәдем сын ясаучылар эзләп. Эзли торгач, таптым. Сынчы Зөлфия Мөхәмммәтҗанова ризалык бирде. Бронзадан коелган, асты граниттан эшләнгән һәйкәл шактый бәягә төште. Бу – Казан халкына бүләк, ә бүләкнең бәясен сорамыйлар. Яхшылык эшләп калырга кирәк... «Бишбалта осталары»на һәйкәл тиздән ике мәртәбә Советлар Союзы Герое Николай Столяров скверында куелачак. Әзер һәйкәлне куяр урын даулап та аз йөрмәдем. Бу көн райондашларым өчен дә, туристлар өчен дә истә калырлык зур вакыйга булыр дип уйлыйм.



**МӘХӘББӘТ** Без Зәйтүнә белән бик бәхетле. Менә инде 45 ел бергә без аның белән. Өч бала тәрбияләп үстердек. Хәзер инде биш оныгыбыз бар. Тормышта төрлесен күрдек. Әмма беркайчан да, бернигә дә үкенмәдек. Бу – безнең язмыш. Без үтәсе сукмак… Хатыным да Кукмараныкы бит. Бәлкем, шуңа без аның белән бик якыннардыр. Поездда кайтканда очрашып танышкан идек. Ресторанга барып, әнигә дүрт лимон алып килдем дә, урыныма килеп утырдым. Каршымда – чибәр генә бер кыз. Минем кулдагы лимонны күрде дә: «Бар әле, миңа да алып кил», – дип, күршедәге юлдашын ресторанга җибәрде. Тегесе, бик тиз генә «беткән», дип, кире әйләнеп тә керде. Мин шунда аңа ике лимон чыгарып бирдем. Танышып киттек… Аның – Казан дәүләт университетында, минем авиация институтында укыган чак. Мин аны үзем белән җәйләрен төзелеш отрядларына алып йөри башладым. Отряд командиры идем. Өч елдан соң өйләнештек. Без аның белән дөньяның кайсы гына илләрендә булмадык. Сәяхәт итәргә яратабыз. Минем өчен гаилә һәрвакыт беренче урында булды. Туган ягыма райкомның икенче секретаре итеп тә, Президент ярдәмчесе вазыйфасына да чакырып карадылар. «Юк, минем өч балам бар, аларга әтинең иң кирәк чагы… Юк, миңа заводтан фатир бирәләр…» – дип баш тартым. Чөнки миңа хатыным, балаларым янында булу мөһимрәк иде.



**БАЛАЛАР** Бүгенге көндә балаларымның икесе – Ренат белән Чулпан – фән кандидатлары. Ренатның хәзер үз бизнесы. Төпчек улыбыз Руфат та югары белемле. Абыйсының ярдәмчесе ул. Ә Чулпан исә еракта – океаннар артында. Гаиләсе белән Төньяк Каролинада яши, университетта инглиз телен укыта, бүлек мөдире. Бүгенге көндә Чулпанның университетта укучы кызы – оныгым Иделия үземә охшаган: минем кебек хәйрия эшләре белән шөгыльләнә. Туган көненә җыелган акчасыннан минем туган ягымда яшәүче шикәр авырулы әбигә кәҗә сатып алып бүләк итте. Гаҗәпләнүемнең, соклануымның чиге булмады шул чагында.



**ҮЗЕМ ТУРЫНДА** Лаеклы ялда булсам да, бер генә минут та эшсез утырганым юк. Бүген мин төбәкнең мәдәни мирасын торгызу юнәлешендә, бер дә арттырмыйча әйтәм, зур эш алып барам. Бишбалта турында китап яза башладым. Эшләгән проектларымның алыштыргысыз, зур кыйммәткә ия булуын исбатларга тиешмен. Бервакыт Татарстан Мәдәният министрлыгына мөрәҗәгать юллаган идем. Министрлыктан: «Сезнең проект, һичшиксез, татар халкы белән бәйле Бишбалтаны Казан шәһәренең тарихи өлеше буларак саклап калуга һәм яңартуга юнәлдерелгән уңышлы иҗади инициатива үрнәге ул, уңай бәягә лаек», дигән хат килеп төште. Димәк, дөрес юлдамын! Бүген мин «Шәрык» халыкара университетын салу, анда татар, рус, инглиз телләре укыту; канат юлы салу (ул Казанны Зөя утравы һәм Иннополис белән тоташтырган булырга тиеш); әйткәнемчә, музей өчен аерым бина булдыру; Сара Садыйкованың бабасы – Бишбалтаның күренекле сәүдәгәре Әхмәдишаһ бай йортына истәлек тактасы куйдыру; Клара Цеткин урамына «Бишбалта» исемен кире кайтару; 1552 елда Казанны саклаучыларга багышланган Тарихи панорама булдыру; төбәктәге мөселман зиратын тәртипкә китерү һәм, ниһаять, биредә туристлык маршрутлары ачу турында хыялланам. Һәркайсының проекты эшләнгән инде, аны гамәлгә ашыру буенча эшкә дә керештек. Бүген Казанны үзгәртү буенча берсеннән-берсе кызыклырак проектлар кабул ителә. Иң зур теләгем – тәкъдим иткән эшләрем шул проектларда чагылыш тапсын, урын алсын иде.

# ИКЕ УТ АРАСЫНДА

Без яшь гаилә. Үзебезнекен булдырганчы дип, әти-әнием янында яшибез. Үз акчабызны исә фатир сатып алырга дип җыеп барабыз. Ирем белән мөнәсәбәтләребез начар түгел, ләкин арага гел әти-әнием керә. Алар безне (күбрәк иремне) яшәргә өйрәтә. Иремнең эше физик көч сорый торган, кичкә арып кайта. Ләкин әни тарафыннан бу ялкаулык дип бәяләнә. «Яшь кеше арыймыни? Кич белән дә каядыр барып эшләргә була бит, болай булса, сез ул фатирны гомерегездә дә ала алмаячаксыз», – дип битәрли. Безне яшәргә өйрәтүдән әнине ничек туктатырга икән? Әлегә без аларның фатирында яшәгәч, барысына да түзәргә туры килә, ләкин иремнең сабырлыгы төкәнер дип куркам.

Нажия Сабирова.
Чаллы шәһәре.

**Ландыш ӘБҮДӘРОВА,**
**журналист:**

– Безнең җәмгыятьтә «әни һәрвакыт хаклы» стереотибы, калып яши. Бу хакта балалар гына түгел, әниләр дә белә. Күрәсең, бу гаиләдә иң соңгы сүзне әни кеше әйтә торган булгандыр. Ягъни әни ачуланмый – мөһим булган әйберләрне аерып күрсәтә, тәрбияли; әни бәхәсләшми – аңлатып бирә һәм башкалар. Һәм бу яшь ханым әнисе янына үзенең яраткан кешесен яшәргә алып килә. Билгеле, монда да чикләрне әни билгели, бу бит аның территориясе... Өстәвенә, кияү кызның әнисе өчен шушы ролен ныгытып куярга тагын бер форсат. Бу очракта киңәш итеп бер генә нәрсә әйтеп була: утырып, чикләрне билгеләргә кирәк. Ягъни әниегезнең ахыргы теләге нидән гыйбарәт: ул сезнең ара бозылуын телиме? Фатир алуыгызнымы? Үзенең сезнең өчен ничек борчылуын күрсәтәме? Яхшы әни булуын расларга телиме? Еш кына бер теләк яки максат икенчесе артына яшерелгән була. Ачыктан-ачык сөйләшкәндә менә шул асыл максатка төшенергә тырышыгыз. Әгәр сөйләшүдән куркасыз икән, түзәргә кала инде.

**Данир САБИРОВ,**
**Татарстанның атказанган артисты:**

– Тормыш коргач, гаиләле булгач, һәркемнең үзенчә яшисе килә. Ә моның өчен аерым торырга кирәк. Андый мөмкинлеген булмаса, әти-әни белән яшәсәң, бераз түзәсең инде. Әмма түземлекнең дә чиге була. Баласының гаиләсе бозылмасын, бергә тату яшәсеннәр дигән әти-әни аларның арасына, гомумән, керми. Акыл да өйрәтми. Кешегә акыл өйрәтү иң файдасыз эш дип саныйм, чөнки һәркем төрле, берәү дә берәүне кабатлый алмый. Киңәш бирергә була анысы, олы кешенең киңәше файдалы да була. Әмма акыл өйрәтергә ярамый. Без дә хатыным Миләүшәнең әнисе белән бергә яшибез, тик ул беркайчан да безнең арага кереп, кысылып йөрми. Ничек яшәргә икәнен дә өйрәтми. Хат авторының әти-әнисе кызы белән киявенең бәхетле булуын тели икән, араларын бозудан туктасыннар. Кияү яки киленнең гаебен табып, битәрләп тору – нәкъ менә араны бозу була да инде. Акыллы әти-әни бу адымга бармый.

## Белгеч фикере


Ләлә БӘҺРАМШИНА, психолог

– Гаиләгә яңа кеше керү – һәрвакыт кризис. Моңа кадәр бергә яшәүчеләргә дә, яңа килеп керүчегә дә кыен. Мөнәсәбәтләрдә мөмкин кадәр ачыграк булганда бер-береңә ияләшү җайлырак уза. Яңа килгән кешегә ихтыяҗларын, хисләрен «мин-хәбәр» рәвешендә белдерергә өйрәнергә кирәк. Башкаларны ишетә белү дә бик мөһим. Кеше үзен аңлаганнарын белгәндә генә кемнедер тыңларга әзер. Мин сөйләшүне рәхмәт әйтүдән башларга киңәш итәр идем. «Әти-әни, рәхмәт, безне үзегезгә сыендырдыгыз, безгә түзеп, хәлебезгә кереп яшисез...» Бу бит дөрестән дә шулай. Сөйләшүне мактаудан башлауны – «өч плюс» кагыйдәсен өлкәннәр дә куллана ала. Кияүләре тик ятмый, эшли бит. Шулай ук яшьләр дә үз ниятләрен ачыктан-ачык белдереп, хәбәрләшеп эшләсәләр, отышлырак. Өлкәннәр яшь гаиләнең хәленнән, ниятләреннән хәбәрдар булсалар, аларның гамәлләрен аңлавы җайлырак булачак. Әйтик, фатирны ничә сумга алырга җыеналар, ай саен ничә сумны җыеп баралар, кайсы срокларны күздә тоталар, моның өчен нишлиләр – бу мәгълүмат ачык булырга тиеш.

# КӨМЕШ ТӘЗГЕН, АЛТЫН ЙӨГӘННӘР...

**– Атны ничек җигәләрме? Әллә ни катлаулы эш түгел ул... Башта йөгәнен кидерәсең, аннары аркасына ыңгырчак салып, тәртә арасына кертәсең. Муенына камыт кидерәсең... Аңа өйрәнәсе юк, үзеннән-үзе өйрәнелә торган һөнәр...**
**Каршымдагы агай, көлемсерәп, бермәл тын кала. Мөгаен, яшьлеген, тройка атлар җигеп йөргән гаярь чакларын уйлыйдыр.**
**Ул җиңел генә санап чыкты да бит, ләкин ыңгырчак ни дә, бөят ни, авызлык, аел, тезген ни – бүген аларын кемнәр генә белә икән?! Хәер, белүчеләр бар әле анысы, ләкин атны күз йомып та җигә алганнары, ай-һай, сирәк. Атлары да санаулы лабаса.**
**Ә менә шул атларны җигәр өчен дирбия ясаучылар аннан да азрак.**



Лилия
ГӘРӘЕВА



Фото: Анна Арахамия

# Ир-егетнең йөрәгендә иярләнгән ат ята (мәкаль).

Зәй районы Әхмәт авылында хәзерге заманның үтә дә сирәк һөнәр иясе – хәтта республикабызда бердәнбер оста дип әйтерлек Фаит абый Сәитов яши. Җиләкле тау итәгенә аны эзләп барышыбыз. Бу үрләрне Уралның үзенә барып тоташа, диләр. Матур яклар!

Кызы Алсу ханым Әюпова, әткәй олыгайды инде, күзләре начарланды дисә дә, җиңел гәүдәле җитез агай каршы ала безне. Килешебезгә атны да җигеп куйганнар. Шлеяларның көмеш тәңкәсендә – кояш нуры. Аелы, йөгәне, тезгене – бар да көмеш тәңкәле! Аты күршеләре Шамил абыйныкы булса да, бизәкле дирбияләр Фаит аганыкы. Моннан берничә еллар элек Зәйдә аның тәңкәле ат дирбияләрен күреп, без бу якларга тагын бер киләчәкбез әле, дип, күңелгә салган идек. Хәзер бизәкле ат дирбияләре ясаучыларны тагын кайларда гына очратып була икән?!

– Без атны җигә белеп туган буын булдык. Атның муенына камыт кидерергә буй җитмәс иде, анысын картлар кидереп бирә дә, таң белән тырмага чыгып китәбез. Бүгенге тормышны машиналарсыз күз алдына китереп булмаган кебек, элек атсыз яшәп булмады. Әле колхозлашу чорына кадәр авылның иң ярлы кешесе дә ат алырга тырышкан. Безнең әти дә колхозга үзенең биясен биреп кергән. Фазыл биясе дип йөрттеләр аны. Ул чакта колхозның һәр атын хуҗасының исеме белән атадылар. Гыйльметдин биясе, Сәүбән алашасы... Безнең биянең колынынннан үскән атны сугышка озаттык...

Фаит абый – сугыш чоры баласы. Әлеге өч сүзгә бар да сыйган. Ачлык та, ялангачлык та, ятимлек тә, балачактан башкарган авыр хезмәт – барысы да шушы өч сүздә. 11 яшеннән колхозда эшли ул. Бары дүрт кенә ел укырга туры килсә дә, тормыш аңа бернинди дә институт, университетлар бирә алмый торган гыйлем бирә. Шул гыйлеме аңа ферма мөдире дә, клуб мөдире дә булып эшләргә мөмкинлек ача.

– Сугыш башлангач, сигез чиләк бәрәңгегә алыштырып, әнкәй бер иске гармун алды, – дип искә ала героем. – Шатлыгымны әткәйгә бик язасым килгән иде дә, «Бигрәк иркен яшисез икән», – дип әйтер», дип, әнкәй яздырмады. Безнең әткәй сугышның беренче елыннан ук фронтка алынып, Берлиннарны урап кайткан кеше. Кайткан көне әле дә күз алдымда – ишектән килеп керде дә: «Улым, бар әле, ат тап. Анда юл буенда минем әйберләрем калды, шуларны алып кайтырга кирәк», – ди. Ул кайткан сөенечтән кунаклар җыйдык. Берзаман авыл советы председателе Сабир абый: «Кая, теге «кыйкыең»да уйна әле!» – димәсенме?! «Анысы ни тагын?» – ди әткәй. «Бәй, белмисеңмени? Улың гармунда уйный бит синең!» – диләр. Шунда әткәй: «Эһ, язган булсагыз, гармун алып кайта идем бит. Казан базарында бер кулымда – акча, икенче кулымда – гармун. Нәселебездә гармунчыларның булганы юк, дип, гармунны кире куйдым», – диде.

Үзе дә 90 яшен тутырып дөнья куйган Фазыл абзый, нәселебездә юк, дисә дә, бүген өйдәге алты гармунның икесе – хуҗаның улы Ринат белән килене Әлфия апаныкы. Фаит абыйның бертуган энесе Халит абый да оста гармунчы булган.

Күренеп тора, бу йортта гармуннарга һәм атларга хөрмәт зур.

– Әткәй үзе дә атлар асрады, бетергәненә кайчан гына, – дип сүзгә кушыла Ринат абый. – Әткәй, хәтерлисеңме ул атларыңны?

– Хәтерләмичә! Тройка атлар җигеп, дугаларга җиз кыңгыраулар тагып, гармуннар белән Сабантуйларга йөрер идек. Кышны озату бәйрәмнәре тагын! Тройка җигүне колхоз председателе булып килгән Комаров дигән кеше керткән иде бездә. Үзе дә кошёвка, тарантас җигеп йөрде. Матурлыкны ярата, шуңа омтыла иде.

Без бая телгә алган сирәк һөнәренә узган гасырның 60 нчы елларында керешә Фаит ага – колхоз атларын бәйрәмгә җигү өчен дирбияләр җитештерә башлый.

– Аларны күп ясадым инде, – дип сөйли ул. – Элек дирбия җитештерүче заводлар була иде. Безнең Ширәмәттә дә ясадылар аны. Колхозлар заманында ат дирбияләренә кытлык булмады. Ләкин алар атны эшкә җигә торган гына, матур түгел. Ә бәйрәмнәргә матур итеп бизисе килә. Менә шул председателебез колхозга ике пар тройка әзерләтте. Миңа – аксыл атлардан, авылыбызда бүген дә ат тотучы Валерийның әтисе Виталий Васильевка – каралардан. Шуларны җигәр өчен үзебез тиешле сбруйларын тегеп, аларны бизәдек. Болар фәкать бәйрәмнәрдә тотар өчен генә иде, бер ясап куйсаң, гомерлек була, тузмый алар.

Бүген дә матурлыгын югалтмаган ул бизәкләрнең берсе дә кибетләрдән сатып алган түгел, һәрберсен оста үзе ясаган.

– Кайчан вакыты була, шунда бүкәненә иелеп, тең-тең тәңкә чүкер иде әткәй, – дип искә ала балалары.

Хәзер бу эш белән инде шөгыльләнмәсә дә, останың кораллары тутырылган чемоданы ерак куелмаган әле. Тәңкәләрне формага кертә торган бүкәне дә якында гына. Чормасында – ясалып бетмәгән кошёвка чаналары.

Теләсә кайсы эшкә керешкәнче, иң элек материалы кирәк. Күгәрми торган мондый ялтыравык калайларны кайдан табып бетерде икән, дип гаҗәпләнәбез.

– Нәрсә ялтырый, шуннан ясап булмый аларны, – ди оста үзе дә. – Төсле металл гына ярый. Башкалары тора-бара күгәрә. Металлның да бик калын да, бик юка да бул-

# Атларга мәхәббәт татарның геннында. Ә геннарны үзгәртеп булмый.

маганы кирәк. Сез сорагач, уйга калдым әле: кайлардан табып бетердем икән шуның кадәр җизне, алюминны? Бер атның дирбиясен бизәр өчен генә дә йөзләгән тәңкә кирәк бит.

Фаит абый утырган урыныннан җитез генә күтәрелеп, безне үзе белән ияртә. «Әйдәгез әле, мең кат сөйләгәнче, бер кат эшләп күрсәтим!» Оста кулындагы кечкенә генә калай кисәге ул арада ике колаклы тәңкәгә әверелә. «Колаклары ник кирәк?» – дип аптырашканыбызны ишетеп, кеткелдәп көлеп куя үзе.

– Ник кирәкме? Колаклар тәңкәне каеш дирбиягә беркетү өчен кирәк. Баштарак мин аларны колаксыз гына, уртасы тишекле итеп ясый идем дә, каеш дирбияләргә тимерчыбык белән беркетә идем. Ләкин бу рәвешле эшләүне ошатмадым, якынрак килеп карасаң, ничек беркетелгәне барыбер күренә. Аннары әлеге ысулны уйлап таптым.

Моның белән генә эше бетми әле останың. Һәрбер тәңкәсен махсус бүкәнгә куеп, формага кертәсе бар аның, аннары киез белән ышкып, барысын да ялтыратасы...

– Яссы гына булса, матур түгел бит. Кабарыбрак торсалар, бөтенләй башка төрле, затлырак булып күренә.

Атка тага торган чукларны ул иске күн дирбияләрдән, камыт покрышкаларыннан ясый. Йөгәннәрне, шлеяларны күннән үзе тегә.

Аларны тегәргә беркемнән өйрәнмәгән, тормыш үзе өйрәткән аны.

– Иң яхшы дирбияләрне фронтка җибәрделәр. Без исә калганын тәртипләп, өзелсә, үзебез тегеп, ялгап, иң авыр елларны атлар һәм үгезләр белән уздык, – дип, еракгагы хатирәләрен барлый әңгәмәдәшем. – Ат – юлдашым булды. Сиксәнне узганчы атлар асрадым. Бик акыллы җан иясе бит ул. Бер дә онытмыйм: берсендә ат җигеп урманга зелпегә бардым. Озаграк йөрдем, ахрысы, адаштым. Эзлим-эзлим, атны таба алмыйм. Бер аралыктан узганда үзе кешнәп тавыш бирде.

Тәүге тапкыр чабышка чыкканын да көлеп кенә искә ала ул:


– Үзем колхозда эшкә җигеп йөргән атны иярләдем. Ярты юлга кадәр баш бирмәде. Ярты юлдан соң сынатты – тыны кыска булган. Иң ахырдан килдем. Атымның ияренә тәмәке янчыгы элгәннәр иде. Шуннан соң ат чабышында башкача катнашканым булмады.

Яшьлекләрен искә төшерү Фаит абыйның күңелен җилкетеп җибәрде булса кирәк, ул кулына кыңгыраулы Саратов гармунын ала. Гармуннарның төрлесендә уйный Фаит абый, әмма иң катлаулысы дип шушы гармунны атый. Яшь вакытта сәхнәләр тоткан кеше утыра каршымда. Коеп куйган Хәлил ул («Галиябану»ны куйганда, Хәлил ролен гел аңа тапшыра торган булганнар). Үзе уйнап, үзе җырлап җибәрсәме!!! «Чың-чың итә, җил тузгыта / Җиз кыңгырау моңнарын...» Вәсил Хәбисламовның Әнгам Атнабай сүзләренә язган бу җырын яшьлегендә бик яратып җырлаган ул. Күз алдына аның ак тройка атларда, гармуннар уйнатып, ямь-яшел басу юлыннан Сабантуй мәйданына юырткан мәле килә. Дугаларда исә җиз кыңгыраулар чыңлый – чыңчың, чың-чың... Юксындыра бу чың, сагындыра...









# КҮРШЕ ХАКЫ – АЛЛА ХАКЫ



Илнар хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИН, «Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы

**? Күрше хакы – Аллаһ хакы дип әйтү бар. Бу хак, чынлап та, шулай зурмы?**

– Күршеләргә яхшы мөнәсәбәттә булырга кирәклеген Аллаһы Тәгалә безгә Коръәни-Кәримдә әйтә. Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылыгыз, аңа тиңне күрмәгез, әти-әниләрегезгә, туганнарыгызга, ятимнәргә, фәкыйрьләргә, шулай ук якын яки ерак булган күршеләрегезгә, мосафирларга, әсирләргә яхшы мөнәсәбәттә булыгыз ди ул. Алар арасында, күргәнегезчә, якын һәм ерак күршеләребез дә бар. Пәйгамбәребез дә: «Әгәр дә күршеләрегез акча сорап керсә, бурычка акча бирегез. Әгәр дә тормышларында авырлыклар килеп чыкса, аларны кичерергә ярдәм итегез», – ди. Башка хәдисләрдә дә күршеләр белән куаныч-шатлыкны уртаклашырга кушыла. «Өйдә ризык пешерелсә, аны күршеләргә дә кертергә кирәк», – диелә. Пәйгамбәребез дә: «Ашарга пешерсәгез, ризыгыгызны күбрәк салыгыз, чөнки кунак алдына куярга яки күршеләргә дә кертергә туры килүе бар», – ди. «Балаларыгызга берәр нәрсә сатып алсагыз һәм күрше балаларында ул әйбер булмаганын белсәгез, аларга да алыгыз», дигән хәдис бар: бу үз чиратында, күршеләр арасында булган көнчелекне бетерергә ярдәм итә. Күрше риза булмаса, ике арага нидер төзү, гомумән, аңа комачау итә торган әйберләрне эшләү катгый рәвештә тыела. Кое казыган вакытта, күршеңнең коесының суы сиңа күчә торган була икән, шулай ук бу эштән тыелырга кирәк – аңа зыян салырга ярамый. Әгәр күршең авырып китсә, хәлен белергә керергә кирәк. Әгәр мәрхүм булса, синең бурычың – аны зиратка озату, җирләргә булышу. «Аллаһы Тәгалә янында яхшы күрше булам дисәң, үзеңнең күршеңә яхшы мөнәсәбәттә бул», – ди Пәйгамбәребез. Икенче бер хәдисендә: «Күршеңне ихтирам итү – әниеңне ихтирам итү белән бер», – ди. Димәк, аларга да әти-әнигә караган кебек карарга тиешбез. Болар барысы да күрше хакын хаклауга керә торган әйберләр. Күршебезнең нинди диндә булуы мөһим түгел: күрше хакы барысына да тарала – мөселманга да, христианга да, башкаларга да. Әлбәттә, ул христиан булса, син аның диненә катнашмыйсың, ләкин, күрше буларак, хакын хакларга тиешсең.

**? Ничә өйгә кадәр күрше дип санала?**

– Гадәттә, динебездә һәм халкыбызда: «Кырык йортка кадәр – күрше», – дип әйтелә. Уң һәм сул яктан, арттан һәм алдан. Әйтик, шәһәр җирендә күп катлы йортта торасың икән, анда яшәүчеләр бөтенесе дә күрше булып санала. Хәтта күрше йорттагылар да. Авыл җирендә исә бер урамда гомер итүчеләргә күршеләр, диләр. Әлбәттә, кырык йорт, бер караганда, бик күп булып тоела. Әмма, икенче яктан, синең тормышың барыбер шушы кешеләр белән бәйле: алар белән бик еш күрешәсең, бер урамнан йөрисең, бер ишектән чыгып китәсең, кайтып керәсең. Шуңа күрә кырык йорт дигән сүздә гаделлек һәм логика бар.

**? Аңа карата син рәхим-шәфкатьле булып та, күршең яхшылыгыңны аңламаса?**

– Күршегә яхшы мөнәсәбәттә булырга кирәк дип әйттек инде. Әмма ул сиңа яхшы мөнәсәбәттә булса, яхшылык кылса гына син дә аңа яхшылык кыл дигән сүз түгел бу. Күршең сиңа бер яхшылык эшләмәсә дә, син аңа эшләргә тиешсең. Ул сиңа гомердә сәлам бирмәсә дә, син аңа бирергә тиеш. Ул сиңа ярдәм белән кермәсә дә, син аңа ярдәмеңне тәкъдим итеп керергә тиешсең... Күршеңнең беренче адым ясавы шарт түгел. Башлап яхшылыкны син кылырга тиеш, чөнки син Аллаһы Тәгаләнең әмерен-сүзен үтисең. Шуның өчен динебездә хәтта начарлык кылган күршеләргә дә яхшылык кылу дигән нәрсә бар. Пәйгамбәребезнең бер яһүд күршесе аның ишек төбенә гел чүп ташлый торган була: аның һәр иртәсе шул чүпне җыештырудан башлана. Бер көнне чүпне күрмәгәч, пәйгамбәребез күршесенә керә: «Ни булды, әллә авырып киттеңме?» – ди. Күршесе, чыннан да, урын өстендә авырып ята икән. Үзенең чүп ташлаганын, зыян китергәнен яһүд кешесе, әлбәттә, белә – Пәйгамбәрнең тавыш куптарганын көтә. Ә ул аның хәлен белергә кергәнен аңлагач, күзенә яшьләр тула. Хәтта улына да ислам дине кабул итәргә әйтеп калдыра... Яхшылык бары тик яхшылыкны гына тудыра. Әгәр син битараф булсаң яки начарлык эшләсәң, ул начарлыкка гына китерәчәк. Мәсәлән, бер кеше Пәйгамбәребез янына килеп: «Күршем бик начар, мин дә, җавап итеп, аңа начарлык эшләсәм ярыймы?» – дип сорый. Пәйгамбәребез: «Юк, ярамый, түз, – ди. – Икегезнең берегез үлгәнче сабыр ит: ул алданрак үлсә, башка начарлык эшләмәячәк, син бакыйлыкка күчсәң, аның начарлыгы инде зыян китермәячәк». Әгәр җавап итеп начарлык кылсаң, син дә начарга әйләнәсең. Бу исә гомерлек дошманлыкка китерергә мөмкин. Ахырда ул күршенең: «Мин бит аңа гел начарлык кына эшләдем, ә аның беркайчан бу адымга барганы булмады», – дип акылга килүе ихтимал. Һичьюгы – аның балаларының. Шуңа күрә күршегә начарлык кылу рөхсәт ителми. Хәтта алар тавышлы кешеләр булсалар, эчеп йөрсәләр дә, сабыр итү хәерлерәк. Әлбәттә, җинаятькә кучмәгән очракта.



Рәкит Әбделмәнов (Рәкит Аллабирде) – Башкортстанның Күмертау районы Яңа Аллабирде авылында туа, атаклы Мораптал мәктәбен тәмамлый. Хәрби диңгез флотында хезмәт итеп кайткач, Татарстанга эшкә килә. КАМАЗның Тәгәрмәчләр заводы, «Камгэсэнергострой» төзелеш берләшмәсе, Чаллы... Биографиясендә дә, иҗатында да зур урын алып тора алар. Күпләр өчен ул «Идел–Урал» хәйрия фондын оештыручы һәм аның җитәкчесе. «Алтын йөрәкле кеше», «Ел хәйриячесе», «Зур йөрәкле кеше»... Бу исемнәре үзләре генә дә аның кем булуын сөйлидер. Хәйриячелек һәм халыклар дуслыгы өлкәсендәге эшчәнлеге Россия һәм Татарстан хөкүмәтенең, «Возрождение–Яңарыш» фондының рәхмәт хатлары белән бәяләнә. Рәкит – үзенчәлекле шагыйрь дә! Шигырьләрендә – туган як табигате, мәхәббәт лирикасы, милләт, халык язмышы.

# ТОРНА ЭЗЕ БУЙЛАП...

### *Гаярьләр*

Язгы кич. Торналар чылбыры
Талпына шәфәкъка үрелеп.
Әйтерсең биләүдә һәрбер кош
Тибрәнә, бер моңга төренеп.

Бер урын буш калган төркемдә –
Шуңамы җырлары аяныч?..
Кайдадыр баш салган гаярь кош,
Табалмый чит җирдә таяныч...

Күңелем күзендә бу урын
Буш түгел – ап-ак эз күренә.
Нәселнең буынын тотышып,
Кош җаны кайтамы иленә?!

Ишетәм мин аваз: «Кавемем
Үз эзен сакласа һавада,
Җанымны һәркемгә бүлгәләп
Яшәрмен гел сезнең арада».

### *Җаным тама...*

Каләм тибрәтергә өйрәнмәдем
Толстойлар, Байрон үрнәгендә.
Мәртәбәле уку йортларының
Колонналы даһи түрләрендә.

Уй-хисләрем тыеп зиһенемдә
Күпме генә йөрәк чыдагандыр...
Сыешалмый җырлар җисемемә –
Сахраларга ташып чыгалардыр.

Тәүге тойгыларны күңел күзе
Яза манып рәшә чыкларына.
Рульгә түгел, әти йөрәгенә
Чат ябышып барган чакларыма.

Шәфәкъ утларына манып яза,
Хисләр тама ялан-кырларыма.
Сагыш түккән торна эзе буйлап
Агып киткән яшьлек юлларыма.

Хәтер булып тама, яланаяк
Тилгән куып чабып үткәнемә.
Бакча почмагында кунак кызын
Хыялымда гына үпкәнемә.

Җаным тама үткән елларыма...

### *Катлам...*

Шагыйрьләрнең бер катламы китте...
Китте алар белән сүзгә кадер.
Ятимлеген тойган шигырь юлы
Авырсулап кына туа хәзер.

Хәтер ача күңел дәфтәремне,–
Хисләремне кемдер көтә кебек.
Күк йөзендә якты, таныш йөзләр
Офыкларга агып үтә кебек...

Җисемнәрен барлый алмам бугай
Барысында бер үк – шигырь төсе.
Җиһаннарда җуелмастай булып
Ап-ак эзләр кала – шагыйрь хисе.

Кемнәргәдер тарих булу язган,
Күпләр офыкларга китеп эрер...
Бу катламда сугарылган аһәң
Шигъриятькә әле кайтып керер.

### *Байлык җитә...*

Рәхәтләнеп, көлеп туса шигырь –
Шагыйрь җаны иркен дала кебек!
Сүздән таҗлар тезгән, и сөенә
Күлне күккә аскан Балда кебек...

Теләмичә, елап туса шигырь,
Җәмгыятьтән тәмам бизгән кебек –
...Шагыйрь җаны –
кешелектә хаклык
Үлчәп торган рухи бизмән кебек...

Көлеп тусын шигырь, елап тусын –
Яңа җырлар белән дөнья тулсын.
Иң биектә рухи байлык торсын,
Шул шагыйрьгә җитә – разый булсын.

### *Янә гашыйк булам...*

Һәр яз саен янә гашыйк булам –
Апрель ае таңга гөл чигә.
Һәр ел саен, нәкъ яз уртасында
Чәчкә булып туа Гөлчирә.

Бик сөенеп балкый шунда таңым,
Елмаялар гөлләр бакчада.
«Дөньяда бер чәчкә шулай туа –
Туа алмый сөю башкача.

Син туганны көтеп алдым бит мин –
Март аенда тудым, иртәрәк.
Шушы таңда, миндә моңнар туды...
Шуңа күңел нечкә, иркәрәк.

Чәчәк ата гөлләр, тойса гына
Мәхәббәттә яну хисләрен.
Күбәләге таҗларына кунып,
Назлаганда иртә-кичләрен.

Күңел таша, ургып чыга хисләр –
Җан төренә рәхәт назыңа.
...Гөлбакчада бары бер чәчкәдән
Илһам ала шагыйрь сазына...



Әнгам Атнабаев исемендәге әдәби премия лауреаты Галия ГАЙНЕТДИНОВА шигырьләре ихласлыгы, яктылыгы, җылылыгы белән күңелләрне яулый. Балачактан ук туган як табигатен күзәтергә, ул матурлыкны рәсемгә төшерергә, шигырьләр язарга яраткан Галия (ә ул Башкортстанның Тәтешле районы Сараштыбаш авылыннан) иҗади гаиләдә үсә: әтисе шигырьләр яза, гармунда уйный, әнисе бик матур җырлый. Кыз мәктәп елларында ук Казан, Уфа язучылары белән хатлар алыша. Хыялны, шигъриятне канат итеп, мәктәптән соң Казанга ашкына. Бүген ул биш китап авторы, дистәләгән җырлары бар. Казандагы 5 нче гимназиядә укучылар әдәбиятка, иҗатка, журналистикага тартылып үсә икән, димәк, анда да татар теле һәм әдәбияты укытучысы Галия апаларының роле зур.

# ИСТӘЛЕКЛӘР ЭЗЛИМ

### *Үтеп бара җәем*

Әй авылым, синдә бар да матур:
Алсу таңың, зәңгәр кичләрең.
Ирексездән җырга әверелә
Синдә туган күңел хисләрем.

Тау ягыннан килә җиләк исе,
Болынында печән исләре.
Кыр гөлләрен күр син, ниндие юк,
Анда җәйнең бөтен төсләре.

Җәй бизәге – сары көнбагышлар,
Рәт-рәт тора тезгән кибәннәр.
Тау итәге тулы мәтрүшкәләр,
Урманында шаулый имәннәр.

Бер төш сыман үтеп бара җәем.
Бүген август ача ишеген.
Китәр вакыт җиткән.
Тагын кайт, дип
Озата төсле яшел бишегем.

Август ае җәйгә нокта куя:
Июнь, июль түгел – ул бүтән.
Шуны шәйләп алдым яңа гына:
Мин бит гомер җебенең дә инде
Августында яшимен икән.

### *Өч пәрдәлек тамаша*

Өч пәрдәлек бер тамаша белән
Чагыштырам гомер агышын.
Һәрбер күренештә, һич ялгансыз,
Мин үзем һәм минем язмышым.

Чиратлаша анда өч матур чор,
Һәрберсенең әнә үз төсе.
Көлә-көлә шаян балачагым
Очып йөри күбәләк төсле.

Чая яшьлегем дә яулык болгап
Кереп бара томан артына.
Кире кайту мөмкин булмаса да,
Күңел шул яшьлеккә тартыла.

Тик нишләмәк, гомер арбасыннан
Һич ярамый төшеп калырга.
Теләмәсәң дә син, картлык чорын
Туры килә каршы алырга.

Өч пәрдәгә сыйган хатирәләр
Хәтер сандыгында калалар.
Пәрдәсез һәм антрактсыз гына
Агалар да еллар агалар.

### *Югалмаган ул һич тә*

Бөрчек-бөрчек бизәк төшкән
Яулыгымны югалттым.
Табылыр әле диеп гел
Күңелемне юаттым.

Яулыгым бик тә килешеп
Тора иде йөземә.
Таба алмадым, кем генә
Алды икән үзенә?

Шул яулыкны бүген кичтә
Бирде күрше егете.
Нигә алган? Уйларында
Ни икән ул егетнең?

Яулыкка төреп бирергә
Уйлаганмы сүзләрен?
Бер чара кирәк булганмы
Чишәр өчен серләрен?

Белдертте егет үземә
Күптән гашыйк икәнен.
Очрашып бер сөйләшүне
Күптән инде көткәнен.

«Яратам сине», – диде ул,
Сөю, наз сүзләрендә.
Кулларында – ак сиреньнәр,
Мәхәббәт – күзләрендә.

Югалткан яулыгым шулай
Табылды айлы кичтә.
Ялкынлы учларда йөргән,
Югалмаган ул һич тә.

### *Кайтчы, иркәм*

Болыннарга килеп, сагышымны,
Бөтен уйларымны таратам.
Бакча гөлләре дә матур, никтер,
Болын чәчәкләрен яратам.

Зәңгәр таҗлы чәчәкләрне җыйсам,
Искә төшә синең күзләрең.
Алсуларын җыйсам кулларыма,
Алсуланып китә йөзләрем.

Яшьлегемнең матур хатирәсе —
Сине сөеп йөргән юләр чак.
Бүләк иткән идең миңа ул чак
Болын чәчәкләрен бер кочак.

Син киткәннән башлап бу болынның
Гүзәл чәчәкләрен өзмәдем.
Гөлдән гөлгә очкан күбәләк күк,
Җаным һаман сине эзләде.

Бергә чаклар искә төшкән саен,
Болын сукмагыннан мин үтәм.
Гөлләр гөрләп чәчәк аткан чакта,
Кайтчы, иркәм, тизрәк, мин көтәм.





Язучы һәм журналист Ләлә Сабирова (Гыймадиева) хикәяләреннән җылы яктылык бөркелә. Укытучылар гаиләсендә үсү, университетта уку еллары, мәктәптә балалар укыту, балалар газетасы «Сабантуй»ның редакторы булып эшләү аның иҗатында да чагыла. Яшьлек, хыяллар, дөньяны матур итеп күрәсе килү – менә шулар аның геройларын да матур итә, аларны укучыга якынайта.



Ләлә САБИРОВА

# КОЛ

(Хикәя)

***Мәхәббәт сагыштан тора ул...***

– Нурания апа, почта килдеме әле?

– Күрәсең ич, аралап утырам. Көт бераз.

Әлфинур ишектән башын тыгып кына дәшкән иде, эчкә узды.

– Кая, үзебезнең урамныкыларны миңа гына бир. Үзем өләшәм.

– Ай, кызый! Бушка эшләргә дә риза! Каян таптың соң син ул егетне?

– Ник, бер мин генәме? Безнең класс кызлары бөтенесе язышa ич!

– Беләм инде, аптырап әйтәм. Ни кызыгы бардыр күрмәгән-белмәгән кеше белән мәхәббәт хатлары алышуның. Армия срогы беткәнчегә хәтле генә бит инде алар.

Нәрсә аңлыйсың соң син, Нурания апа-а! Асланның фотосурәтен күңгә әллә ничә тапкыр алып карый Әлфинур. Хатларын хасиятләп җыеп бара, өйдә ялгызы гына калганда кабат-кабат укый. Классларындагы бер генә малай да андый матур сүзләр әйтә белми. Күп калмады инде. Хезмәте бетүгә, туры монда кайтырга ышандырды. Аңарчы алар мәктәпне бетергән була инде.

– Мә, кызый, бие!

Әлфинур урыныннан сикереп үк торды. Битләре кызышып яна башлады.

– Син ул хатлар турында әнигә әйтеп торма инде, җәме, Нурания апа!

– Ярар ла! Кеше серен кешегә чәчеп йөргәнем юк әле.

Ул көнне хатлар классларындагы башка кызларга да килгән булып чыкты. Иртән күрешүгә, китте чыштыр-чыштыр конверт актару, бер-берсенә күрсәтеп мактанышу. Әллә аңлап, әллә болай гына, малайлар аларны кызлар кулыннан йолкып ала, тегеләре чырыйлап кычкыра.

Бөтенесе Хәлимәнең абыйсы Салих армиягә киткәч башланды. Кызларның адресларын хезмәттәш дусларына ул тараткан. Юри генә язышa башлаганнар иде, тора-бара кызып киттеләр. Әлфинурга Аслан атлы абхаз егете туры килде. Икенче хатында ук ул фотосурәтен салды. Шуны күргәч, тынычлыгы качты кызның. Әттәгенәм, булса да булыр икән шундый чибәр кеше! Кап-кара кашлар, кап-кара күзләр... Бөтен йөрәкне өтеп ала инде. Әлфинурның үзен дә ошаткандыр, фотолар алышкач, хаты тагын да «тәмлерәк» килеп чыга башлады Асланның. Русча язса да, соңыннан: «Сау бул, матурым, очрашырбыз!» – дип, саф татарча сүзләр «төртеп» куярга да онытмый иде.

Нурания апа «чәчмим» дисә дә, авыл кешеләренең теленә керү озакмы? «Солдат хатлары» турындагы хәбәр Шәмсенур апага да килеп ирешә.

– И-и, болай гына бит инде ул, әни! – дип акланды Әлфинур, әнисе сораштыра башлагач, үзенең йөзе кызарып китте. – Кызлар белән хат алышканда солдат хезмәте тизрәк уза, дип әйтә ди Салих абый...

– Тапканнар кызык... – дип, яратып кына сукранды әнисе.

Нурания апа хатларны төгәл бер ел – кызлар тугызынчыны бетергәнче ташыды. Аннары аңа эш җиңеләйде – әллә егетләр уйнап туйды, әллә болары кызык тапмый башлады – хатлар йөрү сирәгәйде. Торабара бөтенләй туктады. Әлфинур белән Аслан гына элемтәне өзмәде. Озаграк хәбәрсез торгандай тоелса, ашы – аш, йокысы йокы булмады инде кызның.

Чыгарылыш кичәсендә бигрәк ямансу булды. Егетләрнең биергә чакыруына да теләр-теләмәс кенә чыга Әлфинур. Күзләрен йома да, Асланны алар урынында итеп күрә. Менә шулай вальс әйләнсәң иде аның белән!

Ул җәйне классташларының күбесе кайсы кая таралышып бетте. Авылда берничәсе генә калды. Мәктәптә хәйран яхшы укыгач, укытучылары Әлфинурны институтка кыстаганнар иде, кызый аяк терәп каршы килде. «Әнине ялгызын гына калдырмыйм!» – диде. Моны ишеткәч, Шәмсенур апа шаккатты. Кызын каршысына утыртып сөйләште.

– Син нәрсә! Әни үзе генә кала дип әйтәсең диме?! Урын өстендәге карчык түгел лә мин, синнән башка да тормышымны бик әйбәт алып барам. Укып, кеше булганыңны күрәсем килмимени минем дә!

Әлфинурның хәлен аңлыймыни ул? Чын дөресен әйтсә, буран очырачак шул. Дөрес, кызның башында – томан, алда ни булачагын тәгаен генә үзе дә күз алдына китерми. Шуны гына белә: Аслан көзгә кайтачак. Монда калырмы, Әлфинурны үзе белән алып китәрме, анысын менә күз күрер.

– Әни, бер генә ел ял итеп торыйм инде, ә! Аннары кая кушсаң, шунда барырмын! – диде әнисенә. Күзен дә йоммый ялганлый алуына үзе дә аптырады. Мәхәббәт дигән шайтан шулай иләсләндерде инде аны.

Классташларын шаккатырып, тотты да колхоз фермасына сыер саварга керде Әлфинур. Әнисе башта киреләнеп маташкан иде, кызы «бер генә ел» дип тәкрарлагач, күнде тагын.

Җәйләрне көчкә уздырып җибәрде кызый. Һәр иртәне Асланның кайту көнен исәпләп чыгарудан башлый. Октябрьдә, дип язган иде бер хатында, инде анысы да узып бара. Алай гынамы, соңгы арада никтер хаты да тукталды әле. Хәлимәнең абыйсы кайтып утырганын ишеткәч, күңеленә шом керде. Юк йомышын бар итеп, Салихларга китте. Эчкә узып торасы булмады, егет ишек алдында йөри иде.

– О-о, солдат кайткан икән! – дигән булды Әлфинур, гаҗәпләнгән кыяфәт чыгарып. Үзе Салих белән ике куллап күреште. – Хәлимәнең күренгәне юк микән дип килүем иде.

– Сеңелнең укуы каты, ди. Киләсе атнада гына күрешербез инде, Алла теләсә.

– Бөтенләйгә кайткансыңдыр, иеме, Салих абый?

– Бөтенләйгә инде! Күпме йөрергә була тагын.

– Һәммә кеше кайтып беттеме?

Егет Әлфинурга шактый гына текәлеп карап торды.

– Ә син... ник алай дип сорыйсың? – Ул нидер исенә төшерергә азаплана иде бугай. – Туктале, кызый... Синең теге абхаз егете турында сорашуың мәллә?

Әлфинур кызарынды, ык-мык килеп, күзләре белән җирне бораулады.

– Соң, монда кайтырга тиеш түгел бит ул, аны үз әнисе көтә торгандыр. Син инде бигрәк, бала-чага шикелле... Алай бөтен нәрсәне серьезныйга алырга димәгән.

Әлфинур капканы бәреп диярлек чыгып китте. Асланның монда туры кайтмавында Салихның гаебе бар диярсең. Аның үз артыннан:

– Төкер син аңа, башында җил уйный торган егет, кирәк түгел ул сиңа! – дип кычкырып калуы бер колагыннан керде, икенчесеннән чыкты.

Менә ышан син егетләргә! Әнисе барлыгы яңа исенә төшмәгәндер бит инде Асланның... Йә, ярар, дип юатты кызый соңыннан үз-үзен, туры кайтмаган икән, димәк, сәбәбе булган. Әнисе белән күрешергә-киңәшергә теләгәндер, озак йөрмәс, шап итеп килеп төшәр әле... Шулаен шулай да, озаккарак китте шул. Инде кыш та ишекне шакый. Асланны уйлый-уйлый йоклап китә Әлфинур, күзен ачуга, тагын Аслан дип саташа башлый. Ашаудан калды, шуңадыр, ябыгып та китте. Шәмсенур апа үзенчә борчыла.

– Без аңламаган чирең бар мәллә, Ходаем?! Күзләреңнән нур качты, өшкертеп карыйсымы соң?.. Ял итә дә белмисең бит. Кеше шикелле клубка чыгар идең, күңелең ачылып китәр иде.

Мондыйларына бөтенләй җавап биреп тормый Әлфинур. Аслан тегендә, ә ул монда бүтән егетләр белән биеп йөрсенме? Булмаганны..

### *«Урының монда түгел синең...»*

Сабыр канатлары сынды кызның, өмете тәмам киселде – Асланның соңгы хаты килүгә дә төгәл ярты ел узды. Нишләп туган җиренең адресын сорый белмәде икән ул аннан теге вакытта?.. Шулайдыр, Салихның «серьезныйга алма» диюендә хаклык бардыр. Аслан өчен уен гына булган инде бу хат алышу. Ә ул, юләр кызый, читтән торып баш-аягы белән шуңа гашыйк булып йөри...

Бүген дә эшкә авыр уйлар белән килде. Савымчы кызларның гадәттәгечә чырык-чырык килеп көлешүе, мәгънәсез сөйләшүләре ачуын китерде. Ферма мөдире күренүгә, кызлар төртмәле сүзләр белән аңа ташланды. Ул тозсыз шаяртулардан ничек туймыйлардыр! Тегесе дә түзә тагын, артыгын дәшми.

– Фазылҗан абый, комың коелып бара бит инде, ник өйләнмисең син, ә?

– Менә мине ал, үкенмәссең! Колхоз эшенә йөртмәсәң, мин сиңа барырга риза!

Фазылҗан, аларны узып, Әлфинур янына килде.

– Нихәл, сеңел! Кәефсез күренәсең, бер-бер хәл булмагандыр бит?





– Юк ла... Боларның кыланмышларыннан күңел болгана. Тыя да белмисең үзләрен, Фазылҗан абый.

– Сөйләнсеннәр, тел сөяксез бит ул. Миңа димәгәе...

Соңгы арада ул гел аның янында кайнаша. Әллә аңлый, әллә җәлли...

Кышын Әлфинур уйларын тәртипкә китерә башлады. Дәреслекләрен барлады, кайсы институтка барырга икән дип план корды. Әнисе белән дә киңәште. Анысы моңа кызыннан артыграк сөенде.

– Кая барсаң да бар, гомереңне фермада үткәрмә берүк! – диде.

Тик... Бер булмаса, булмый икән. Әллә булган белеме бер ел эчендә шул сыерлар янында коелып беттеме? Ничек күтәренеп чыгып киткән булса, ике атна дигәндә шулай күтәренеп кайтып төште Әлфинур авылга. Авызборыны болай да салынган иде – әнисе, сорашып, җанын талкымады.

– Ярар, быел булмаса, киләсе елда булыр, – диде. Тик ул моны болай гына, кызын юатыр өчен генә әйтте.

Үзенә үзе урын таба алмыйча шактый йөрде әле Әлфинур. Күңелендә бушлык иде. Әнисе кыстагач, клубка да чыккалап карады. Сагыз шикелле сыланырга маташкан авыл егетләреннән гайрәте чикте. Алар урынында Аслан булсамы?!

Ниһаять, җыенып, ферма мөдире янына китте.

– Менә, кайттым, – диде. – Мине эшкә аласыңмы, Фазылҗан абый?

Фазылҗан озак кына дәшми торды. Күрәген бер куйды, бер алды.

– Аласыңмы дип... Монда түгел бит синең урының, сеңел...

Әлфинур аңа аптырап карады. Ник монда түгел? Нәрсә, начар эшләдеме әллә ул? Берәүнең дә аннан артык җире юк.

Соңгы җөмләсен кычкырып ук әйтте бугай. Фазылҗан көлеп куйды.

– Юк, сеңел, киресенчә... Мондагыларның берсенә дә охшамагансың. Былтырдан бирле күзәтәм инде мин сине.

Шуннан? Әлфинурның аптыравы йөзенә чыккан иде.

– Менә нәрсә, Әлфинур. – Фазылҗан аңа беренче тапкыр исеме белән дәште. – Чык миңа кияүгә. Үзең беләсең, мин алай төчеләнә белмим, ну син минем начар кеше түгел икәнемне беләсең.

Ул күрәген шап итеп җиргә кадады.

– Ашыктырмыйм. Уйла. Иртәгә өегезгә керәм, җавабыңны шунда әйтерсең, – диде дә кызу-кызу атлап китеп барды.

Әлфинур телсез калды. Менә сиңа Фазылҗан абый! Уйла, ди. Уйларга иртәрәк бит әле аңа... Иртәрәк дип... Ә Аслан кайткан булса? Ул чакта иртәсен-соңын карап тормаган булыр идең бит, кызый!

Ә бер карасаң... Укырга керә алмады, тагын шул сыерлар янына кайтып утырды. Киләсе елга, дигән була әнисе. Әлфинур үзе ул «киләсе елга» тамчы да ышанмый. Асланны уйлап яшәү дә көлке. Ә болай... юньле кеше чакырып торганда, аны онытырга да ярап куймасмы әле.

Иртән аның Фазылҗанга әйтәсе җавабы әзер иде. Егет капкадан күренүгә, каршы чыкты. Йөзе белән генә әнисе ягына ымлап күрсәтте. Мин риза, әни белән үзең сөйләш, янәсе...

### *Карлыгандай кара күзләрең...*

– Әбием, мә! Сиңа иң зурысы! Әнием, монысы сиңа карап тора, кап!

– Һай, бәбекәчем! Бигрәк юмарт инде үзең! – Сәбиха апа ике арада чабып йөргән оныгын алдына алып, шапы-шопы сөйде дә, карлыган куаклары арасына кереп чумган Әлфинурга эндәште:

– Бүгенгә җитәрдер, килен? Без, кереп, чәй куя торыйк, озаклама, яме!

– Ярар, ярар! Җитешмәсәм, эчә торыгыз, бу куагымны бетерим инде!

Быел карлыган бигрәк эре. Үзләре ишле, җыеп бетерешле түгел. Мине ал да мине ал, дип, күзгә үк кереп торалар.

Абау! Бусы ни тагын?!

Әлфинур тураеп басты. Карлыгандай кап-кара күзләрен аңа төбәп, куаклар артында ят бер ир басып тора иде. Хатын, шикләнеп, артка чигенде.

– Кем кирәк сезгә?

– Не бойся, красавица! – Татарчасы юк, димәк. Урысчасы да төзек түгел. – Это я, Аслан. Ты помнишь меня?

Әлфинур егылып китә язды. Ничек танымый торды соң ул аны? Төн йокыларын калдырган шул Аслан бит инде! Нәкъ фотодагы кебек – бераз олыгайган гына. Их, егет, ничек шулай бик соң эзләп таптың соң син мине?!

Әлфинур сыгылып төште. Карлыган төбенә чүгәләде, ул арада Аслан да аның каршына килеп утырды:

– Не ждала меня, красавица?

Көтмәгән кая! Хәзер күрешерлек булгач, ник алданрак хәбәр бирмәдең соң син? Хатынның күз яшьләре гөрләвектәй акты. Соң инде хәзер, җаным, соң!..

Аслан көрәктәй зур учы белән аның күз яшьләрен сөртә, җилкәсеннән сөеп ала, башыннан сыйпый. Егетнең өзек-төтек җөмләләреннән шуны гына аңлады Әлфинур: теге вакытта ул әнисенең авыруы хакында телеграмма алган, ашыгыч төстә өенә кайтып китәргә мәҗбүр булган. Аннары аны тәрбияләп яткан. Бик теләсә дә, Әлфинурны оныта алмаган.

– Не могу без тебя, моя хорошая! – дип, Аслан үзе дә хатынның күкрәгенә башын төртеп үкседе.

Карлыган төбендә күпме шулай акылларын җуеп утырганнардыр, Әлфинур кайнанасы тавышыннан айнып киткәндәй булды.

– Җитәрсәнә, килен, кер инде! Рәмис тә юксына! Иртәгә дә көн бетмәгән!

Сискәнеп торып басты Әлфинур. Көн бетмәгән дип... Кемгә беткән, кемгә юк...

– Хәзер, хәзер... Ике минут...

Аслан яфрак кебек калтырап торган Әлфинурны кочагына алды. Тегесе шунда сенде, ереде...


Рәсем: Наталья Васильева

– Анда сезнең посадка... Иртән мин сине шунда көтәм. Сәгать ничәгә хәтле булса да көтәм. Син килмичә китмим. Җыенып кил. Мин сине монда калдырмыйм... Үзем Салихларда кунам. Аңа синең өчен кайтканны әйтмим...

Төсе качкан киленен күреп Сәбиха апа куркып калды.

– Абау, ни булды? Күбрәккә китте, ахры?

Бигрәк артыгын кайгырта инде! Әлфинурның кайчак ачуы да килә.

Яратып чыкмады бит ул Фазылҗанга, «чыгам да керәм» дип кенә уйлады бугай. Инде ияләшә төшкән иде. Рәмис тугач, Фазылҗан үзе дә һавада очып йөри башлаган иде... Хәер, ияләшү ярату дигән сүз түгел бит әле ул... Мәхәббәтсез яшәү үзе гөнаһ дигәнне дә ишеткәне бар Әлфинурның... Их, ичмасам, каксыннар, суксыннар иде аны, түзә алмыйча качып киткән дип уйларлар иде хет...

Уйларының берсеннән керде Әлфинур, икенчесеннән чыкты. Башы буталып бетте. Шаулап кайтып кергән Фазылҗанга күтәрелеп тә карыйсы килмәде. Кичке аш вакытында күбрәк Сәбиха апа белән Рәмис сөйләде, Фазылҗан каш астыннан гына хатынын күзәтте. Рәмискә иптәш алып кайтам, дип сөйләнә иде, шуңа кәефсездер, дип юрады.

– Алай карама миңа, көне буе карлыган җыйдык, башыма капты, – дип акланды Әлфинур. Үзенең зиһене чуалды, әйберен кая куярга белми аптырады.

Күзгә йокы кермәгәндә, ай-һай, төн бигрәкләр дә озын икән! Хатын боргаланып ятып карады да, мендәрен кочаклап, зал ягына чыгып китте. Фазылҗанның иртән эшкә барасы бар, аңа да йокларга бирми бит.

Таң атып килгәндә икеләнүдән туктаган иде Әлфинур. Үзем белән ниләр алырга, уңай вакытны ничегрәк туры китерергә дип кенә уйлана иде. Ә Рәмис... Үзе барып урнашсын әле башта, аннары кайтып алачак ул аны. Ташлап китми ич, ышанычлы кулларда калдыра.

Иртә гадәттәгечә башланды: Фазылҗан ашык-пошык чәйләп, эшенә чапты, Сәбиха апа оныгын бакчага илтергә кузгалды, Әлфинур өйдәге вак-төякне карарга калды. Кайнанасы артыннан капка ябылуга, хатын юл сумкасын тартып чыгарды да тиз-тиз генә кирәк тапкан нәрсәләрен тутырырга тотынды. Кайсын алды, кайсын салды да, арт бакча аша җилфер-җилфер атлап, авыл башындагы посадкага таба юл алды...

Төш авышканда Әлфинурның югалуы турында олысы-кечесе хәбәрдар иде инде. Бөтен авыл «ду» килде. Ни уйларга белмәделәр. Фазылҗан, аптыраганнан, урман юлларын, елга буйларын уратып кайтып килә иде, машинасы каршына Салих атылып килеп чыкты.

– Хет ас, хет кис, бөтенесенә мин гаепле, – диде. Өзек-төтек җөмләләре белән Асланның бу якларга эш белән килүен, үзләрендә кунып чыгуын әйтте. – Шулай ук булыр дип башыма да килеп карамады. Бер җилкуар ул, хатыныңны харап итеп ташламагае. Әйдә, ерак китә алмаганнардыр әле, очтык станциягә!





Фазылҗан «Аслан кем ул?» дип сорамады. Машина рулен чытырдатып кысты. Күкрәгеннән ахылдаган тавыш иңрәп чыкты. Салих ачкан ишекне аның борын төбендә кире шапылдатып япты да ыжгыртып китеп барды.

### *Саумы, диңгез! Саумы, яңа тормыш!*

Әлфинурның поездга гомерендә беренче утыруы. Нинди поезд, калага да йомыш белән әллә нигә бер барып кайталар иде. Тормышның менә мондые да була икән! Ул Асланнан күпме барабыз дип тә, кая барабыз дип тә сорамады. Яраткан кешең белән дөнья читенә китәргә дә әзер буласың икән аны. Мәхәббәткә тел кирәкми диюләре хак – икесенең дә русчасы такы-токы, шулай да рәхәтләнеп серләштеләр. Вагонның өске шүрлегенә менеп кунакладылар да, табигатькә хозурланып карап барып, поездның рәхәт теркелдәвенә оеп-оеп та киткәләделәр. Алдагысы хакында Әлфинур уйламаска тырышты. Янәшәсендә – еллар буе зарыгып көткән Асланы, калганы – вакыт эше. Җайланыр, боерган булса.

Шәһәрне чыгып киткәннең өченче көнендә хатынның бөтенләй йокысы качты. «Озакламый килеп җитәбез», – диде Аслан. Әлфинур тәрәзәгә баккан иде, хәйран калды. Бер якта – башлары болытлардан да ашып киткән биек таулар, икенче якта – Әлфинурның төшенә дә кермәгән очсыз-кырыйсыз диңгез. Әкияти җирләр бит бу! Сулышы кысылды, сөенечтән башы әйләнде.

Рәхәт булса да, ардырды. Адлер шәһәрендә поездан автобуска күчтеләр, аннары Абхазия чигенә кадәр ни өчендер җәяү тәпиләделәр. Менә алда бер-бер артлы тезелешеп баскан яшел фургоннар күренде. Бөтен халык шунда ябырылды. Әлфинур белән Аслан да, тыгылышып, фургоннарның берсе эченә кереп басты.

Юлның иң авыры шушы булган икән. Тирләп-пешеп, ниһаять, фургон ишегеннән сикереп төшкәндә, Әлфинурның җеп өзәрлек тә хәле калмаган иде.

– Поездда чакта ук диңгезне күреп һушсыз калдың, әйдә, башта шунда алып төшәм, – диде Аслан. – Юл тузаннарын кагуыбыз да булыр.

Әлфинур аңа аптырап карады. Нинди диңгез, өйгә дә кермәгән килешме? Өлгерерләр иде әле. Тик нихәл итәсең, кунак – хуҗаның ишәге, ди, Аслан әйткәч, көйсезләнеп торып булмый инде.

Кайчан килеп күрер иде әле ул Кара диңгезне! Каралҗымланып торган су өстендә, күзләрне чагылдырып, кояш нурлары җемелди, чуерташлы ярга бер-бер артлы күбекләнеп күтәрелгән дулкыннар килеп бәрелә. Әлфинур суга куркыбрак кына кереп киткән иде, соңыннан аның рәхәтлегеннән тәмам изрәде. Җитәкләшеп тә йөзделәр, су эчендә куышлы да уйнадылар. Хатынның күңеле бәхетле мизгелләрдән шартлар хәлгә җиткәндәй булды. Ул мизгелләрнең башы да, ахыры да шул икәнен белгән булсамы!..

...Биек тау итәгендә утырган авыл бөтенләй Әлфинурларныкына охшамаган. Акшарга буялган тәбәнәк таш йортларны, чуерташ түшәлгән тар урамнарны күргәч, хатынга ямансу булып китте. Кисәктән генә еракта калган якыннары исенә төште, өзелеп-өзелеп Рәмисен сагына башлады.

– Не кисни, моя хорошая! – дип, иңнәреннән кочып алды аны Аслан. – Ну-ка, улыбайся! Пусть все думают, что мы прекрасная пара!

Хатын көчәнеп кенә елмайды. Ул арада әле бер, әле икенче капкадан егетләр, кызлар чыгып, Аслан белән исәнләшеп үтә башлады. Үзләре Әлфинурга сынаптекәләп карый сыман тоелды. Кыз оялуыннан гел җиргә карап атлады.

Монысы Асланнар йорты икән. Хатын капка төбендә үсеп утыручы таныш булмаган җимеш агачларына сәерсенеп карады. Ул да булмады, Асланның көр тавышы аны сискәндереп җибәрде:

– Мы пришли, Замира, выходи! Сдержал я свое слово!

Ишектән, атылып, Асланның үзе кебек үк кап-кара чәчле, кап-кара күзле чибәр генә хатын килеп чыкты. Боларны күрүгә, «исәнме» юк, «саумы» юк, кулларын болгый-болгый үз телләрендә нидер кычкырынырга тотынды. Хатын артыннан берсе мүкәләп, икенчесе тәпиләп, ике яшь бала да өстерәлеп килә иде. Аслан Замираның кыланмышларына игътибар итмичә, балаларның икесен ике беләгенә алып утыртты да алар белән гөлдергөлдер үзенчә сөйләшергә тотынды.

Әлфинурны баскан урынына кадаклап куйдылармыни! Ни алга, ни артка китә алмады. Нәрсә дә булса аңларга тырышып карады, булмады. Матур күзләрендә ут уйнатып, кара хатынның аның өстенә килгәнен хәтерләргә өлгерде әле. Үз телендә ниләрдер кычкырганын да ишеткәндәй булды. Аннары – тоташ бушлык. Әлфинур өчен бөтен дөнья тирбәлә башлады, аны талгын гына каядыр караңгылыкка очырып алып китте...

### *«Үз теләгең белән килдең...»*

Ул бер караңгы сарай эчендә уянып китте. Яткан урынын капшап карады – агач карават, өстенә иске кием-салым түшәлгән. Бераздан күзләре ияләште, сарай стенасына көрәктер, сәнәктер ише нәрсәләр сөяп куелганын күрде. Торак йорт түгел бу, димәк. Кая килеп эләкте соң ул? Ә Аслан кайда? Аслан... Әлфинур соңгы тапкыр аның ике бала күтәреп торганын исенә төшерде. Нинди балалар икән ул? Ә кара хатын? Исемен Замира диде бугай... Ә үзен нишләп бирегә кертеп салганнар соң?

Әлфинур сак кына торып утырды. Аның башы әйләнә, күңеле болгана иде. Юл өстендә ни бар, шуларга тотынатотына, ишеккә таба юнәлде. Үз аякларына урала-урала барды. Барып җитә алмады, ишек үзе ачылып китте. Әлфинурның кисәк яктылыктан күзләре чагылды. Башын күтәреп караганда, бер кулы белән ишек баганасына, икенчесе белән бөеренә таянып, Замира басып тора иде.

– Ну что, красавица, поговорим?

Әлфинур чайкалып куйды. Куллары белән тотыныр урын эзләде. Моны күреп, Замира аңа таба үзе кузгалды. Култыклап алды да, кире караватына илтә китте.

– Ты беременная, да? – Әлфинурның ияк какканын абайлап, үзләренчә нидер кычкырып куйды. – От Аслана? Мужа моего?

– Нет, нет, что вы! Моңа кадәр күргәнем дә булмады минем аны. Өч айлык авырым белән чыгып киттем. Исә-әр!..

Әлфинур сыгылып төште. Аңына әле генә килә башлады бугай ул.

Замира киң итәкләрен җилфердәтеп чыгып китте дә, озакламый кабат әйләнеп керде. Кулында зур подноска салынган ашамлык иде.

– Перекуси. Хәл җый. Аннары берәр нәрсә уйларбыз.

Ул ахылдап куйды, йодрыклары белән тезләренә суккалап алды.

– Акыл керәсе юк икән. Син ничек килеп каптың соң аңа?

Әлфинурның сөйләп бирми чарасы юк иде. Алар кулында бит хәзер, туган җире кайда да, ул кайда? Гаебе юклыгын аңлатырга кирәк бит инде, юкса, Замира бик гайрәтле күренә, бәргәләп ташламагае... Болай икәнен белгән булсамы?!. Бөтен нәсел-нәсәбен калдырып чыгып китәр идемени ул!

Яшенә тыгыла-тыгыла сөйләде хатын. Үзе туктаусыз:

– Ник алай эшләде соң ул, ник алай, ә? – дип кабатлады.

– Күңел ачар өчен тапкан инде бер юләрне! – диде Замира, Асланны тиргиме ул, әллә Әлфинурнымы, аңлашылмады. – Әнә эшенә чыкты да китте, әллә кайчан онытты инде ул сине.

Аның яртылаш урысча, яртылаш үзләренчә сөйләгәненнән шул кадәресе барып җитте Әлфинурга: иптәшләренә карта уенында оттырган Аслан. Откан очракта нишләргә тиеш булгандыр, отылсам, тагын бер кәләш алып кайтам, дип мактанган. «Татарстанда йөргән кызым елап калды», – дигән.

– Алдашмыйча яши белми ул, ну бу кадәресенә үк ышанмаган идем, – дип, үзләренчә сүгенеп куйды Замира, тешләрен шыгырдатып.

– Нишләргә, нишләргә...

– Нишләргә, имеш... Тик елап утыр инде хәзер. Шулкадәр дә беркатлы булырга кирәк бит, ә?!

Замира, чәчрәп, урыныннан сикереп торды, йодрыкларын йомарлап, арлы-бирле йөренде. Әлфинурның коты очты: артына тибеп, капкадан очырып чыгарса, нихәл итәрсең?! Кайту юлын да белми, кесәсендә бер тиен акчасы да юк... Кабат күз аллары караңгылана башлады, ишелеп төшмәс өчен, карават тимеренә ябышты.

– Ну, ну, ну... Син нәрсә?!

Кызулап килеп, Замира аның башын тотып карады.

– Абау! Ут та ут, син дә ут... Йә, чәбәләнмә, ятып тор әле, уйларбыз...

Замира йә дулап китә, йә йомшарып төшә. Әлфинур үзен аның янында ничек тотарга белми аптырый. Ят дигәч, ятаргадыр дип, караватына менеп капланды да күзләрен йомды. Башы ни дә булса уйларлык түгел иде.

Уяулы-саташулы көннәр бер-бер артлы уза торды. Әлфинур озак рәтләнмәде. Төннәр буе кызышып, бәргәләнеп чыкты. Көндезләрен өстерәлеп кенә ишек алдына чыга да, һава сулап, тагын ятагына кереп ава. Замира аңа үлән сулары кайнатып эчерде, җылы шулпадан да өзмәде. Аслан ник бер тапкыр янына кереп карасын! Еш кына хатыны белән ут чәчеп кычкырышкан тавышы ишетелә, урысча яман итеп сүгенә, ярый әле, аларчаны аңлап җиткерми Әлфинур.

Ник табиб-фәлән чакыртмыйлар икән соң аңа? Ярамыймы? Үлеме шулай чит-ят җирләрдә булыр микәнни?

Әлфинурның күңеле тулды, Рәмисе, Фазылҗаны күз алдына килеп басты. Мендәренә капланды да, үксепүксеп елап җибәрде.

– Ну, что, красавица, весело тебе у нас?

Хатын сискәнеп китте, үзе дә сизмәстән, карават читенә торып утырды. Нәкъ әүвәлгечә матур елмаеп, каршында Аслан басып тора иде. Әлфинур ачудан шартлар хәлгә җитте. Аһ, шушы җирәнгеч бәндәне ничекләр генә «яратам» дип йөри алды икән ул? Булдыра алса, үз куллары белән ботарлап атар иде аны хәзер!

– Ни вини меня, дорогая! Полюбил тебя, я, что, виноват за это?!

Аслан, көрәк кулларын сузып, аны кочагына алырга теләгән хәрәкәт ясады.

Әлфинур ыңгырашып куйды, йөрәге тагын да ешрак тибә башлады. Бар көченә талпынып торып басты да, бармакларын җәеп, Аслан өстенә ташланды:

– Кол итәргә уйладыңмы мине, кабахәт!..

– Кол?.. – Аслан аңа селтәнергә ирек бирмәде, кулларыннан кысып тотып алды да шаркылдап көлеп җибәрде. – Нинди кол? Колның аяк-кулларын богаулап, ач килеш көне-төне эшләтәләр аны, җанкисәгем. Ә синең урының рәхәттә, тамагың тук. Мин сине сатып та, урлап та алып китмәдем. Үзең килдең бит. Үзеңме? Йә, шулай түгел диген? Теләсәң, бүгеннән чыгып китә аласың – беркем мәҗбүриләп тотмый...

Шулай ул, шулай... Әлфинур Асланнан ычкынды да аңа нәфрәт тулы күзләрен текәде. Кол ул, кол... Үз теләге белән сайлап алган язмыш колы...

### *«Юллык акча табып бирсәң...»*

*...Аһ, дип әйтүләре кыен,*
*Исемә төшәсең дә...*

Әлфинур җырлый-җырлый, елый-елый, учак тирәсендә кайнаша. Соңгы вакытларда Замира аңа әбәт әзерләүне ышанып тапшыра башлады. Плитә ишегалдында, карт инҗир куагы төбендә.

Боларның бөтен ризыгы яшелчәдән, ахры. Токмач турап аш пешерсәң иде аны... Пәрәмәч пешереп күрсәтсәң иде... Шуларны уйлый да, тагын күңеле тула Әлфинурның, еламый калган көне бар микән?

Теге хәлдән соң Аслан аңа якын килми. Иренең сарай тирәсендә кайнашканын күрсә, Замира да карчыга шикелле аның өстенә ташланырга гына тора.

Тора-торса, ул Әлфинурны әрләп ташлый, бераздан, йомшарып, «нишләргә икән соң синең белән», диебрәк сөйләнергә тотына.

Әлфинурның хәле элекке кебек түгел инде, уңайлана бара. Аллага тапшырып, юл хәстәрен күрә башласа да ярый үзе. Баласын монда табып ятарга язмасын...





Бер көнне Замираның кәефе күтәренке чагын туры китереп, үзе сүз башлады.

– Юллык акча табып бирсәң, Аллам белән ант итәм, кайтып җитүгә әзерләп җибәрер идем, – диде.

– Табып бирсәң дип... Табучысы Аслан инде аның. Сорадым инде бер тапкыр, ничек килгән, шулай китсен, өстерәп алып кайтмадым мин аны, ди.

– Ай, Замира!.. Ничекләр итеп яшәмәк кирәк шундый кеше белән!.. – Әлфинурның тавышы иңрәп чыкты.

Замираның күзләрендә яшен уйнаклап алды.

– Менә шулай яшисең инде, кая бармак кирәк! Аздыручы хатыннар булганда, ирләрнең бөтенесе бер аның!

Юк, юк! Фазылҗан андый түгел – хәзер генә аңлады моны Әлфинур. Ул Асланга тагын бер кат нәфрәтләнде, гаҗизлектән беркавым аңгыраеп утырды. Ул арада Замира җәлт кенә кереп, өйдән кәгазь белән карандаш алып чыкты.

– Язып җибәр туганнарыңа сәлам хаты. Адресны әйбәтләп күрсәт. Килеп алсыннар...

Әйтте бер сүз! Кем килеп алсын аны? Әнисеме? Фазылҗанмы? Күптән тормышларыннан сызып атканнардыр инде, бу кадәр хурлыкны ничек күтәрә алсын алар?!

Шулай да кәгазьне Замира кулыннан алып, сараена кереп бикләнде. Тагын авылы күз алдына килеп басты. Сагынудан йөрәге кысылды. Ах, шушы хәлләрне күрәсен алдан белгән булсамы?!

Туктале... Ахирәт дусты Хәлимә калды бит әле анда. Теге вакытта әйткән иде ул аңа, чистый мәхәббәт колы булгансың син, дигән иде. Булды шул. Тик мәхәббәтнеке түгел. Аслан колы...

Ярдәм итә алмас алуын Хәлимә, шулай да бер рәхәтләнеп эчен бушатсын әле аңа...

Тезде дә тезде хәсрәт тулы ачынулы сүзләрен Әлфинур, кәгазь битендә урын калмады. Ул сүзләр күз яшьләренә чыланып бетте, кайсылары танылмаслык хәлгә килде. Соңыннан иң кирәклесен төртеп куйды: «Фәлән хәтле акча табып җибәрә алсаң, бу афәттән котылыр идем», – диде.

Китте хаты очып туган ягына. Әлфинурга караганда бәхетлерәк ул! Иң әүвәл Нурания апа кулына килеп керәчәк, кире адресны күргәч, шаккатып калыр инде. Тәки үзенекен иткән бу җүләр кызый, дияр...

## «Саклый алмадым сине...»

Озакламый Әлфинурның хәле тагын кирегә китте. Туктаусыз башы әйләнә, йөрәге уйнаклый. Хәйран түгәрәкләнеп килгән «көндәш»ен күреп, Замира аһ-уһ итә, ире белән талашып килә, шуннан арыдан уза алмый. «Акча табып бирсәм дә, ничек чыгып китәсең инде бу хәлеңдә!» – дип аптырый.

Бер иртәне Әлфинур бөтенләй урыныннан тормас булды. Башыннан: «Раббым, үзең кичер, үлемем шушы икән», – дигән уй сызылып узды. Күпме яткандыр, ишек алдындагы шау-шуга сискәнеп уянып китте. Кемдер нидер әйтеп кычкыра, нәрсәдер дөберди, аңа балалар елашкан тавыш килеп кушыла. Әлфинур коты очып тыңлап ятты. Ул арада шау-шу сарайга якынлашты, хатын, куркып, урыныннан кубарга азапланды. Менә кисәк кенә килеп, сарай ишеген каерып ачып җибәрделәр. Яктылыктан чагылган күзләрен Әлфинур учлары белән каплады. Дөп-дөп басып, янына кем килеп басуын күрми калды. Ул «кемдер» бер кулы белән аның аркасыннан, икенче кулы белән беләгеннән тотып, урыныннан торгызды. Чү, акылдан язуы түгелдер бит... Әллә саташамы?

Бу куллар аңа шулкадәр якын, шулкадәр үз иде. Күптән онытылган мондый җылылыктан Әлфинур изрәде, гәүдәсенең мамыкка әйләнә баруын тойды. Күзләре кабат йомылды, һәм ул, һушсыз калып, Фазылҗанның (әйе, әйе, аның Фазылҗаны иде бу!) кочагына авып төште...

...Ике көнлек юлда Фазылҗан хатынына ике сүз әйттеме икән? Поездга килеп керү белән, иң әүвәл ятып бару өчен аңа урын көйләде, кайнар чәй ташып торды, җылы ризыктан өзмәде. Тик ялгышып та: «Хәлең ничек?» – дип сорамады. Машинасын вокзал тирәсендә генә калдырган булган, кайтып җиткәч, анда да Әлфинурны күтәреп диярлек алып барды, арткы утыргычны ятып кайту өчен көйләде.

– Фазылҗан...

Гафу сорамакчы булдымы хатын, рәхмәт әйтергә теләдеме – сүзе тел очында эленеп калды. Аның ялварулы хәлсез тавышын ишеткәч тә борылып карамады ире, киресенчә, радиосын катырак кычкыртып куйды. Хәер, авызын ни әйтергә теләп ачканын Әлфинур үзе дә белмәде. Аның тәне дә, җаны да сыкрый иде.

Авылга кайтып төшкәч тә Әлфинур яткан урыныннан кузгалмады – олысы-кечесенең Фазылҗан машинасы артыннан ашардай булып карап калуларын күрмәде. Фазылҗан үзләренең капка турысыннан выжылдап узып китте дә, чаттан борылып, Шәмсенур апаларга турылап китте. Әлфинурны машинадан чыгарганчы башта капка келәсенә берничә тапкыр шакылдатып бәреп алды: кайтып җиттек, каршы ал, янәсе. Аннары гына машина ишеген ачты:

– Чык!

Капка шыгырдап ачылды, әкрен генә атлап килүче Шәмсенур апа күренде. Әлфинур аһ итте: әнисе тәмам бетәрешкән, тәнендә карга чукырлык та ите калмаган иде. Чыгу белән койма каршындагы эскәмиягә лапылдап килеп утырды, учлары белән йөзен каплады.

– Йа, Аллам...

– Менә, энкәй... э-э... Шәмсенур апа. Миннән калмады. Баласын тапсын, минеке ул – анысын ташларга җыенмыйм. Рәсимне сорамагыз – барыбер бирмим. Аның өчен анасы юк, үлде...

...Әлфинурның җитлекмәгән баласы үле туды. Хатынның еларлык та чамасы юк иде. Шәмсенур апаны хәсрәткә салып, бер ноктага карап тик ятты.

Халык зираттан чыгып, таралышып беткәч тә, яңа кабер янында Фазылҗан озак утырды. Иреннәре туктаусыз: «Кичер, балам, саклый алмадым мин сине, саклый алмадым», – дип пышылдый, күзләреннән тыелгысыз яшь ага иде...

75 ҖИҢҮ! 1945–2020

**Илгә ябырылган олы кайгы – миллионнарча корбаннар биргән сугыш афәте без – балалар өчен дә зур сынау, балачагыбызны урлаган, бик күпләребезне ятим иткән кара көннәр булып йөрәккә уелып калган. Безнең чор баласы авыр физик хезмәт белән иза чигүләрдән тыш, сәяси яктан кыерсытылу газапларын да башыннан уздырды шул. Искә төшереп, күз алдына китерсәң, җаннар телгәләнә. Ләкин без барысына түздек...**

# ӘЛЕ ДӘ КӨТӘМ...


Фото: Анна Арахамия

– Бибифатыйма, балаларны тәрбиялә. Мин кайтырмын! – дип киткән иде әти, шул сүзе әле дә хәтердә...

Асия апа Мөхәммәтдинова Актаныш районы Иске Байсар авылыннан. Әтиләре Сәлах абыйны 48 яшендә – 1942 елның 14 апрелендә фронтка алалар. Дүрт бала кала алар. Иң олы абыйларына 14 тулмаган, Асия апага әле ул чакта 9 яшь тә юк, энеләренең берсенә – 5, икенчесенә 3 яшь.

Әнисе белән абзыкае эштә, хуҗалык, ике кечкенә бала Асия өстендә.

– Нәрсәләр ашатып бетердем икән, дип уйлап утырам әле, – дип, бермәл тынып тора ул. – Сыерыбыз бар иде. Шул сыер сөте, бакчадагы бәрәңге, табигатьтәге үләннәр хисабына исән калдык та инде. Әле ел саен 350 литр сөтне налогка тапшырабыз. Аның өстенә 40 кило ит салымы. Арбага җигеп симәнә орлыгы ташыган сыер кайдан аның кадәр сөт бирсен дә, ит бирә алсын соң?! Заем тагын... Әнкәйләрне эштән кайткач чакыртып, төне буе утырталар. Районнан килгән вәкил өстәл төеп заемга язылырга куша. Шуны түләр өчен хәтта сыерыбызны саттык.

Ә 1944 елны... – Асия апаның тавышы тетрәп китә. Ничә еллар узса да, җан әрнүләре әле дә үтмәгән. – Кырда кышлаган башак ашап, әнидә кан чире башланды, үз авылыбыздагы больницага салдылар аны. Балтырган көпшәләнгән вакыт. Әнигә бик ашатып карыйсыбыз килә дә бит, янына кертмиләр. Ә беркөнне, әниегез үлгән, диделәр. Дүртәүләп больницага йөгердек. Күңел бер дә ышанмый. Әнисез ничек яшәрбез? Мәетләрне җыя торган палатага чыгарып куйганнар... үлгән... Өйгә кайтмыйча, больница ишегалдында дүртебез дә елап басып торабыз. Ә ике сәгатьтән үз гомеремдәге иң олы шатлыкны кичердем – ышанасызмы, әнкәй күзләрен ачты! И безнең сөенүләр! Шул көннән соң тагын 36 ел яшәп, 1976 елның җәендә җан бирде ул. Тормыш әниләрне дә, безне дә нык камчылады.

Берсендә Әҗәкүл пристанена баржада тоз кайткан. Сугыш елларында тоз әҗәл даруына тиң булды. Авылдан берничә хатын-кызга ияреп, мин дә тозга киттем. Капчыкларга тутырып, Агыйдел ярына чыгарып бушатабыз. Эшли-эшли, күлмәкнең аркасы умырылып чыкты. Ачык арка белән кайтып булмый бит, аркага капчык ябып кайттык.

Ул урман кисүләр җелекләргә үтте. Үзебезнең урманнарны да, Чаллы, Бондюг, Куйбышев (хәзер Спас районы) урманнарын да әллә ничә тапкыр барып кисәргә туры килде. Анда кичергән авырлыклар... Куйбышев урманын кисәргә без алты кызны авылыбызның ике егетенә ияртеп җибәрделәр. Урман кисәргә план бар. Шуны тутырмыйча кайтырга ярамый. Эшли торгач, бер кызыбыз теге егетләрнең берсенә кияүгә чыгып, каядыр эшкә китеп бардылар. Икенче егет тә аларга ияргән. Без биш кыз ялгыз торып калдык. Беравыз сүз русча белмибез, бер тиен акчабыз юк. 18 яшегез тулмаган дип, кисә торган делянкага да кертмиләр. Ике метрлы пычкы белән, ике ягыннан икешәр кеше тартып кисәсе иде ул агачларны. Җитмәсә, бер кызыбыз, өстенә агач авып, бик нык имгәнде. Бәйләргә ни чүпрәк юк, ни дару юк... Бичаракаем, имгәнсә дә, ул да бездән калмый. Күрше Яңа Байсардан урман кисүчеләрне алырга машина килгән. Куанышып, кузовына менеп баскан идек, планыгыз тулмаган, урманны тапшырмагансыз дип, безне алып кына ыргыттылар. Нишләргә дә белми торганда үз авылыбыздан Миркасыйм абый килеп чыгып, урманны аның белән кисеп тапшырдык. Үзебезнең авылга җәяүләп алты көн кайттык... Аягына агач төшкән кыз да безнең белән. Ул мескенемнең аягы гөбе кебек шеште, бөтенләй баса алмас булды. Өйдә дүрт кенә көн тордык та, тагын урман кисәргә җибәрделәр...

– Кайтырмын, дип киткән иде әти... Кайта алмады. 1943 елның 23 февралендә үк һәлак булган. Исеме – Хәтер китабында, мәңгелеккә язылган. Әмма ул миңа әле дә исәндер кебек. Кайтыр кебек...

Лилия ГӘРӘЕВА



# БЕРЕНЧЕЛӘР

Әхтәм ЗАРИПОВ

**Иҗатлары белән замандашларын беренчеләрдән булып куандырган шәхесләр республикабызда байтак. Мәсәлән, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Шәриф Хөсәенов беренчеләрдән булып Республиканың атказанган табибы дәрәҗәсенә ирешә, икенче бер Хөсәенов республикада беренчеләрдән булып күп серияле телевизион спектакльләр иҗат итте, тагын бер Хөсәенов, академия театры директоры вазыйфасын үтәгәндә, татар театрын беренчеләрдән булып БАМга, ерак Себер шәһәрләренә гастрольгә алып барды... Бүгенге язмам да әнә шундый беренчелеккә ирешкән иҗади шәхесләр турында.**

Театр институтының татар студиясендә укып югары белем алган 25 яшь артистның Камал театры труппасына кабул ителүенә инде 70 ел булды. Кызганыч, бүген алар барысы да мәрхүм... Бу студияне тәмамлаучыларның сәхнә язмышлары төрлечә язылды. Язмамда мин аларның икесенә генә тукталырмын: Асия Хәйруллина һәм Халит Кумысниковка. Мин аларны Асия апа, Халит абый дип атыйм: бер театрда эшләп, якыннан аралашу мине коры рәсмилектән коткара. Алар – Мәскәүдә югары белем алып, академия театры коллективына кушылган беренче студия әгъзалары. Асия Хәйруллина – хатын-кызлардан беренче Тукай премиясе лауреаты да әле.

Халит абый Кумысников Татарстан телевидениесенең беренче режиссеры һәм артистлар арасында үсеп җитлеккән беренче фән кандидаты, күп шәкертләрне режиссерлыкка укытып чыгарган остаз, мәдәният институтының беренче профессоры. Өстәвенә, спектакльләргә иң үтемле телдә үз карашын белдергән беренче объектив тәнкыйтьче дә ул. Татар театры тарихының Халит абый язган өлеше – ышандырырлык дәлилле, объектив телдә, җиңел укылышлы. Театр тарихын өйрәнүчеләр өчен иң ышанычлы чыганак. СССРның халык артисты Хәлил Әбҗәлилов һәм Тукай премиясенә лаек булган башка артистлар хакындагы мәкаләләре бүген дә кызыксынып укырлык.

Тукай премиясенә беренчеләрдән лаек булган артистлар төркеменә алардан соң бүләкләнүчеләрнең саны елдан-ел өстәлә барып, хәзер инде бүләкләнмәүчеләре бетеп бара. Анысы ярый инде, кирәкле һәм бик куанычлы күренеш булсын, ди. Тик менә ул премияләрнең ни өчен бирелүен аңлаткан һәм аклаган мәкаләләр генә язылмый – шунысы үкенечле. (Хәтта шундый бер парадоксаль хәл булды. Дәрәҗәләре катлы-катлы булган бер артисттан «Тукай премиясен ни өчен алдың?» дип сорагач, ул, әллә уйнап, әллә уйлап: «Чиратым җиткәнгә», – диде.) Кызганыч, сәнгать әсәрләре сыйфат буенча түгел, чират буенча бәяләнә башлады.

«Чират» дигәннән, Асия апаның да, Халит абыйның да кыскача тәрҗемәи хәлләре белән таныштыру чираты җиткәндер.

...Асия апаның тәрҗемәи хәле һәм иҗаты турында үзе язган китабы бар. Ә инде аның сәхнә телен өйрәнү буенча язылган дәреслек китабы – татар театрында иҗат итүче күп артистларның өстәл китабы. Шуны укып яисә Асия апаның үзеннән дәресләр алып, кайбер артистлар бүген үзләре шәкертләренә дәресләр бирә. Бу юнәлештә дә Асия апа – беренче. Театрдан, сәхнәдән үзе теләп киткән артист юк. Ә менә Асия апа үзен сәхнәдә күрми башлауга, үзе теләп укыту эшенә күчә. Укытучылык – аның беренче һөнәре. Спас педагогика техникумын тәмамлап, күпмедер вакыт авыл мәктәбендә укыта. Театр училищесында ул инде гомеренең ахырына кадәр сәхнә теле буенча дәресләр бирә. Бүгенге артистларның күбесе аны, әйткәнемчә, остазым дип искә ала икән.

Кумысников Халит Лотфулла улы... Түбән Новгород губернасындагы Медяна авылында 1926 елның 27 февралендә дөньяга килгән. Колхозлашу чоры башлангач, гаиләләре белән Мәскәүгә күченгәннәр. Балет театрында эшләүче абыйсы йогынтысында 1944 елда татар студиясенә укырга керә. Халит абыйның ул еллар турында кыскылы истәлекләре бар.

«1944 елда А. В. Луначарский исемендәге Мәскәү дәүләт театр сәнгате институтына – ГИТИСка керү өчен конкурс игълан ителде. Кабул итү имтиханнарында яттан берәр әсәрдән өзек, шигырь һәм мәсәл укырга кирәк иде. Әзерләнә башладым. Мишәрчә сөйлим, телдә чатаклыклар бар. Дусларым – сәнгать училищесы студентлары Әмир Вәлиәхмәтов һәм Празат Исәнбәт миңа булыштылар: ике турны уңышлы гына үттек. Өченче турдан бик курыккан идек. Празат Мольерның «Тартюф» комедиясеннән өзек уйнарга тәкъдим итте. Әтисе Нәкый Исәнбәт аны татарчага тәрҗемә иткән булган. Безне кабул иттеләр... ГИТИС безгә, татар студиясе студентларына, Мәскәү театр дөньясының әкияти патшалыгы тоела иде. Кемнәр генә укытмады безне!.. Бөек Станиславский шәкерте Ольга Ивановна Пыжова үзе генә дә ни тора! Руфина Нифонтова, Нонна Мордюкова, Надежда Румянцева, Вячеслав Тихонов, Леонид Куравлев кебек талантлы кино артистларын да ул укыткан... Ул һәрберебез

белән аерым шөгыльләнә, талантыбызны, мөмкинлекләребезне ачарга тырыша иде...»

«Сиңа, Халит, үзеңне комик рольләрдә сынап карарга кирәк, – диде Глеб Успенскийның Толоконниковы минем уйнауда уңышсыз килеп чыккач. – Телгә, сөйләмгә игътибарлы булу да кирәк. Асия Хәйруллина әнә татарча матур сөйли, ул өйрәтер. Ә син аңа русчаң белән булыш».

Чыгарылыш имтиханнарын тапшырганда безнең татар студиясе дүрт спектакль күрсәтте. К. Гоццының «Король болан», М. Горькийның «Васса Железнова», Д. Аппакованың «Бишек җыры», Г. Мусреповның «Козы-Көрпеш һәм Баян-Сылу» әсәрләре. Барысы да уңыш белән барды. Без бердәм театр булып Казанга кайтып киттек».

Институтны 1949 елда тәмамлап, рус театрында эшләп ала, берничә роль уйнарга да өлгерә. Бер елдан аларны академия театры составына кушалар. Бирелә Халит Кумысников театрның әдәби бүлек мөдире – баш режиссерның репертуар сайлау буенча киңәшчесе булып эшли. Ә 1959 елдан, ягъни Татарстанда телевидение «күрсәтә» башлауга – Халит Лотфулла улы телевидениенең беренче татар режиссеры. Режиссерлык тәҗрибәсе туплагач, мәдәният институтына күчеп, режиссура буенча укыта башлый. Профессор дәрәҗәсенә күтәрелә. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр шушы институтта эшли. «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемгә лаек була.

ГИТИСның Татар студиясендә биш ел дәверендә уку актерларның иҗат осталыгын да арттыра, республиканың милли театр сәнгате үсешенә дә йогынты ясый. Мәскәүдә укып кайтканнан соң, күпләр Камал театры труппасында эшли башлый, искиткеч матур образлар тудыралар. Кайберләре, мәсәлән, Празат Исәнбәт, Гали Хөсәенов, укуларын дәвам итеп, соңрак театр, телевидение режиссерлары булып кайталар. Әмир Вәлиәхмәтов Мәскәүнең атаклы рәссамы булып китә.

Халит Кумысников ГИТИСта укып, театровед, ягъни театр белгече һөнәренә ия була. Шушы профессиясе аның төп эшенә әверелә, ул күп татар артистларының иҗаты турында монографияләр яза, театрларның юбилейларына багышлап альбомнар чыгара. Аның иң күләмле эше – татар театры тарихын язуда катнашуыдыр. Бу китапта ул театрның Бөек Ватан сугышы чорындагы эшләренә анализ ясый, үз бәһасен бирә.

Студент Халит Кумысников һәм студентка Асия Хәйруллина 1949 елның 30 апрелендә туй ясап өйләнешәләр, ике кыз тәрбияләп үстерәләр. Кызларының олысы Җәмилә (инде мәрхүмә) әтисе һөнәрен сайлый, кечесе Наилә бүген республикабызның танылган рәссамы, мөгаллимә. Наилә ханым әти-әнисе турындагы истәлекләрне кадерләп саклый.

Сәнгать халыкка хезмәт итәргә тиеш дип лаф орган заманда, «сәнгать – хезмәт күрсәтү бюросы түгел» дип, үзләре аңа ихлас күңелдән хезмәт иткән сәнгатькәрләрнең якты исемнәре һәм иҗатлары онытылмый. Алар «без булдырабыз» дип түгел, «без тиешбез» дип яшәде һәм иҗат итте. Беренчеләр булды!

## Аларның исемнәре театр тарихында алтын хәрефләр белән язылырга лаек.



Фото: Халит Кумысников һәм Асия Хәйруллина.





Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

*Минем әтием ягыннан дәү әтием сугыштан кайтмаган, кайда күмелгәне дә билгесез. Эзләтеп карасак та, «хәбәрсез югалган» дигән җавап ала килдек. Җиңү бәйрәме җитәрәк телевизордан күп кенә архивларның ачылуын ишеткәч, яңадан өмет уянды.*

Мин һәрвакыт сугышта хәбәрсез югалган бабамны әтием хакына табарга тиешмен дип яшәдем. Аның каберенә барып, әтисенең табылуы турында пышылдыйсым килде.

Дәү әтием Тимергалиев Җиһангәрәй 1942 елда Кукмара военкоматыннан сугышка җибәрелә. Фронтка барып җиткәнче күпне кичерергә туры килә аңа. Башта Казанда солдатларны сугышка әзерләү пунктында була, аннан Суслонгерга озаталар. Аны икенче ГУЛАГ дип әйтергә дә буладыр. Бик күп ир-атлар Суслонгерда ачлык, авыр эштә интеккән, күбесе вафат булган. Аннан исән котылып, фронтка китүчеләр үзләрен бик бәхетле санаган. Дәү әтинең яше кырыктан узган булса да, ул да яшьләр белән беррәттән үзен сугышка җибәрүләрен сораган.

Эзләнү эшләрен оныкларыбыз белән бергә интернет аша дәвам иттек. Эзләнә торгач, бер архив исемлегендә дәү әтинең исем-фамилиясенә, аның турындагы кыска гына мәгълүматка юлыктык. Анда полк, дивизия номерлары күрсәтелгән иде. Канатланып, эзләнүне дәвам иттек. Шунысын да әйтеп узыйм, сугыш кырларында ятып калган солдатларны ачыклаучы кешеләр, оешмалар безгә зур ярдәм күрсәтте, эзләнү эшебездә соңгы ноктаны куярга ярдәм итте. Бергәләп дәү әтиебезнең вафат булган урынын ачыклый алдык. 1943 елның 20 августында Калуга өлкәсе Спаск-Деменск районы Снопот авылында һәлак булган. Ул көннәрдә монда бик каты сугышлар барган. Архив документларында шул көннең оператив сводкасы да бар. Ватылган техника, үлгән һәм яраланган солдатлар саны язылган анда. Дәү әтиебез күмелгән хәрбиләр каберлегендә ике мең кеше ята. Шуларның мең ярымы ачыкланган, ә биш йөзенең исемнәре билгесез...

Фото: Анна Арахамия

Барысын да ачыклагач, әтиебез кабере янына барып, изге бурычыбызны үтәдек, дәү әтинең кайда күмелүе турында сөйләдек.

Журнал укучыларына шуны әйтәсем килә: беркайчан да өметегезне өзмәгез. Эзләнегез, бүгенге заманда бик зур мөмкинлекләр бар!

*Ихтирам белән,*
*Гүзәл ЖИҺАНГИРОВА.*
*Казан.*

Әнием – урманчы кызы. Алар бик яшьли ятим калганнар. Әбием иң кечкенә сабыена яшь ярым булганда җир куенына кергән. Әтиләренең әнисе – Фатыйма әбиләре биш балага әни урынына калган, ана назын биргән.

Фатыйма әбием 1903 елда Мамадыш районы Югары Яке авылында дөньяга килә. Хәлле гаиләдән булган ул, әтисе һәм абыйсы урман тоткан. 17 яшендә кызны, күрше авылның атаклы Кәрим бай улы Фазлыәхмәткә кияүгә биргәннәр, ә бертуган абыйсы исә Фазлыәхмәтнең сеңлесенә өйләнгән. Шулай итеп, Фатыйма белән Фазлыәхмәт Түбән Яке авылында тормыш корып җибәрәләр. Бер-бер артлы ике кызлары дөньяга аваз сала. Беренче кызларына Зәйнәп исеме кушалар, ләкин ул бик иртә вафат була, аннан соң туган кызчыкка да шул исемне бирәләр, аның да гомере озын булмый. Шуннан соң бер-бер артлы дүрт малай алып кайта Фатыйма әби.

Совет чорында, репрессия вакытларында халык күргән михнәтләрне аларга да кичерергә туры килә. Бай, хәлле гаиләне Владивосток өлкәсенең Артем шәһәренә сөрәләр. Фатыйма әбинең бертуганнары төрлесе-төрле якка тарала. Бертуган сеңлесен дә ул Магнитогорскига озата.

Авылыбызның акъәбисе – Масфура әби сөйләгәнчә, китәр алдыннан Кәримовлар бөтен мал-мөлкәтләрен кар базында калдырганнар. Тик бер әйберне кулыннан ычкындырмый Фатыйма әби, ул да булса – Коръән китабын. Владивосток җирләреннән исән-сау туган якка әйләнеп кайтырга да шушы изге китапның ярдәме тигәндер.



Алар юлга кузгалуга, авыл халкы Кәримовларның бар байлыгын үзенә ташый башлый. Өч көн узганнан соң, Масфура әби дә барган анда, тик ул килгәндә инде базда әллә ни калмаган була. Шулай да лампа куыклары алып чыга ул.

Кәримовлар Артем шәһәрендә тернәкләнеп, яңа тормыш башлап җибәрә. Фатыйма әби хәрбиләр туклана торган ашханәгә пешекче булып урнаша. Биредә ул үзенең тырышлыгын, хезмәт сөючәнлеген күрсәтә. Аны хәтта Мәскәүдә үткән съездга делегат итеп сайларга телиләр. Әмма Фазлыәхмәт бабай каршы төшә: фанер самолетларга утыртырга куркып, хатынын җибәрми.

Намуслы хезмәте өчен Фатыйма әбине тормышта зур бүләк көтә: алар Түбән Якегә – туган нигезләренә кайтып, яңа йорт тергезәләр.

1941 елда Фазлыәхмәт бабай Бөек Ватан сугышына китә. 1942 елда контузия алып әйләнеп кайта. Әмма язмышына сугыш кырларында ятып калу язылган булгандыр, аны кире фронтка җибәрәләр. Авыл советы рәисе Мотахара апа, абыйсын сугышка җибәрәсе килмичә, аның урынына колагы ишетмәгән Фазлыәхмәтне озата. Фазлыәхмәт бабай башка исем астында янә сугышка китә. «1945 елның 3 маенда вафат булды» дигән хәбәре генә килә аннан. Аңлавыбызча, Фатыйма әби Фазлыәхмәт бабайның нинди «тәхәллүс» астында киткәнен шунда гына белгән.

Авыл халкының Фатыйма әбигә хөрмәте зур булган. Ул оста итеп иген урган, көлтә куйган, палас суккан. Сугу станогы, суккан паласлары бүген дә авыл музеенда һәм төп йортта саклана. Тырыш булганга аларның сөргеннән кире әйләнеп кайтуларына да кырын карамаганнардыр, бәлки. Укымышлы һәм диндар булуы белән дә аерылып торган. Биш вакыт намазны калдырмаган, мөнәҗәтләр укыган. «Коръәнне су урынына эчте, яттан сөйли иде», – дип искә ала әни. Гарәп телендә, кириллицада укый, яза белгән.

Йортыбызда Фатыйма әбидән калган Коръән китабы һәм тәңкәләр белән бизәлгән калфак саклана. Аның туку җайланмасы, күпләгән келәмнәре авыл музеен бизи.

*Алинә ЮНЫСОВА.*
*Казан.*

***Туган авылым – Апасымны бик яратам.*** *Мин яшәгән нигездә газиз әнием Сәхипҗамал туып-үскән. Заманына күрә бик гыйлемле, гади һәм гадел, искиткеч моңлы матур тавышка ия иде ул.*

Әти сугышка киткәндә абыем Илгизгә 1 яшь була. Яраланып, 1943 елда кире әйләнеп кайта ул. Әни минем соңарып, 44 яшендә тудырган. Гомеремнең иң матур чаклары бала чагымда булды. Әтинең җигүле атына утырып, арбадагы яңа чабылган печәннең хуш исләрен иснәп – Сабантуйларына, мәктәп формасы киеп, әтием кулына тотынып беренче класска укырга барулар... Кызганыч, 50 яшендә әтием, авырып, безнең арабыздан китеп барды. Миңа 16 яшь чагында шулай итеп әнием белән икәүдән-икәү калдык... Кышка – утын, терлекләргә азык әзерләү, бакча казу, бәрәңге утыртуалу безнең өстә иде. Җае чыкканда Казанда укып йөргән абыем да булышты, билгеле. Ә мин олыгаеп килүче әниемне ташлап китә алмадым, Пионерлар һәм укучылар йортында эшли-эшли Казан педагогика институтында белем алдым.

1969 еллар... Легендар «КамАЗ» төзелешенә ирем белән без дә кушылдык. Әмма Чаллы каласы нинди генә матур булмасын, ияләшә алмадым. Мине туган нигезем гел үзенә тартты. Әниемне сагынып яшәвемне күреп-тоеп торган ирем мине яңадан Апасыма алып кайтты. Ходайның рәхмәте белән эш урыным да сакланган иде, без яңадан әнием белән бергә яши башладык. Иремә эш урыныннан ике бүлмәле фатир бирделәр, шунда күчендек. Берничә елдан төп нигез урынына яңа йорт җиткереп кердек. Улыбыз Артурга 8 яшь иде ул вакытта. Яңа өйдә дөньябыз түгәрәкләнде: әнием оныгын бик яратты, бөтен тәрбияне үз өстенә алды. 1981 елда көттереп кенә кызыбыз Ландыш туды. Яңа нигезебезгә күпме кайгы-хәсрәт киләсе уебызга да килмәде ул чакларда...

1983 елның 8 мартында, 80 яше тулырга ике ай кала, әнием үлеп китте. Аннан абыемны соңгы юлга озаттык... Кара кайгы безнең нигезне үз итте. Матур гына яшәп ятканда, 2001 елның көзендә кабат ишегебезне какты ул. 2 яше дә тулмаган улы Айдарны ятим итеп, кызыбыз Ландышның гомере юл һәлакәтендә өзелде. Бу хәсрәт безне бөтенләй өнсез калдырды, бигрәк тә ирем биреште. Сабыр итик дип, бер-беребездән көч алып яшәгәндә, тагын кайгы килде: 2006 елның 13 июлендә (бу көнне безнең өйләнешкәнгә 37 ел тулган иде) эшкә киткән улыбыз Артур 36 яшендә «КамАЗ»дан егылып билен сындырды – коляскага калды. Ике операция кичергән идем, бу хәсрәттән тагын берне кичерергә мәҗбүр булдым. Хастаханәләрдә ятулар, операция өчен кешедән акча эзләүләр үзәкләрне өзде. Ике ел түшәмгә карап яткач, улыбыз да матур июль аенда арабыздан китеп барды...

2016 елның октябрендә болай да яралы күңелем кыллары тагын шартлап өзелде: иң якын кешем, арка терәгем, газиз ирем Касыйм, озак авырудан соң, Айдар оныгым белән икебезне генә калдырып, якты дөньядан китеп барды.

Бүгенге көндә Айдарның уңышларына сөенеп, Ходайга шөкрана кылып: «Безнең нигезне ятим оныгым хакына кайгы-хәсрәттән сакласаң иде!» – дип яшим. Бик авыр, ләкин сабырлык белән яшәүне дәвам итәргә кирәк...

*Миләүшә ВӘЛИУЛЛИНА.*
*Апас.*

***Хөрмәтле укучыларыбыз!***
***Сездән хатлар көтеп калабыз.***
***Безнең адрес: Казан,***
***Декабристлар урамы, 2.***
***e-mail: ssuum@yandex.ru***

# АЛСУНЫҢ ЧИШМӘ БАШЫ – УЯНДЫКТА!



Танылган җырчы Алсуның әнисе Разия Исхак кызы САФИНА белән аларның Уяндыктагы бик күркәм йортында очраштык. Разия ханым беренче минутлардан ук үзенең ачыклыгы, ихласлыгы, гадилеге белән сокландырды, аш-суга осталыгы белән шаккаттырды. Ә иң мөһиме – бик шәп әңгәмәдәш булып чыкты. Без дүрт сәгать сөйләштек!

### *Балачак һәм яшьлек еллары*

Мин 1954 елның 4 августында Саратов шәһәрендә хәрби офицер Исхак Сәлах улы белән Тәзкирә Миргалим кызы гаиләсендә икенче бала булып дөньяга килгәнмен. Әтиемә Татарстанның Бөгелмә шәһәреннән фатир бирелгәч, гаиләбез белән шунда күчендек. Биредә урта мәктәпне тәмамладым. 1973 елда исә Уфа дәүләт нефть-техник университетына укырга кердем һәм шунда үземнең гомерлек мәхәббәтемне – Рәлифемне очраттым.

### *Рәлиф*

Рәлиф белән танышканда мин – икенче, ул өченче курста белем ала иде. Озын буйлы, спортчыларныкы кебек тыгыз гәүдәле бу егеткә беренче күрүдә үк гашыйк булдым. Рәлифнең дә күңелендә шундый ук хисләр уянгандыр, күрәсең, очрашып йөрүебезгә берничә ай үтүгә: «Чык миңа кияүгә!» – дип тәкъдим ясады. «Без бит әле яшь, миңа – 18, сиңа 19 яңа тулып китте», – дим. «Булса соң, без бит бер-беребезне яратабыз!» – дип каршы төште Рәлиф. Һәм мин, «ярар», дип әйтмичә булдыра алмадым. Икенче көнне ЗАГСка гариза илтеп бирдек тә, Рәлиф мине туган ягына – Уяндыкка, әти-әниләренә күрсәтергә алып кайтып китте.

### *Уяндык килене*

Текә яр башында, куе урман ышыгында утырган бу кечкенә авыл мине иң беренче чиратта саф һавасы, күркәм табигате белән әсир итте. Автобустан төшеп, кар салган юлдан туган йортына таба атлаганда Рәлиф тә: «Дөньядагы иң матур авыл безнең Уяндык инде ул!» – дип, туып-үскән авылы белән горурланып әйтеп куйды.

Сөйгәнемнең туган йортына якынлашкан саен йөрәкне: «Әти-әниләре мине ошатыр микән?» –

дигән дулкынлану хисе биләп алды. Рәлифнең әнкәсе мине иң беренче чиратта тыныч кына итеп сөйләшүе, сорауларны җайлап, әдәпле генә итеп бирүе белән әсир итте. Әтисе Рәфил күрер күзгә кырысрак һәм кыркурак холыклы кешегә охшап торса да, аның белән дә уртак телне тиз таптык.

Кулымнан килгәнчә әнкәйгә (беренче көннән үк бианамны «әнкәй» дип йөртә башладым) ярдәм итәргә тырыштым: чишмәдән көянтә белән су ташыдым, аш-су әзерләдем. Кыскасы, беренче имтиханны уңышлы тапшырдым. Берничә көннән сөйгәнем белән кире Уфага китеп бардык.

1974 елның 16 мартында Рәлиф белән законлы язылышып, матур гына яши башладык. Кызганыч, Рәлифнең әткәсе белән әнкәсе авылның бетмәс-төкәнмәс эшләрен калдырып туйга килә алмады. Аның каравы, әнисенең бертуган апасы Глүсә килеп, нефть институты янындагы бер кечкенә кафеда узган комсомол туебызны күреп, безне котлап китте.

### *Исә Себер җилләре...*

Укуны тәмамлагач, юллама буенча Башкортстанның Октябрьский шәһәренә эшкә киттек. Рәлиф – «Туймазынефть» идарәсендә эшли башлады, мин исә «Октябрьскмежрайгаз» оешмасына эшкә кердем.

Рәлиф беренче көннәрдән үк үзен инициативалы һәм энергияле белгеч, производство рационализаторы итеп танытты. Моннан тыш, үзешчән сәнгать түгәрәгендә дә актив катнашты. Иң мөһиме – ул тиз арада хезмәттәшләренең ихтирамын яулый алды.

Ул арада безнең тәүге сабыебыз – Маратыбыз дөньяга килде. Авыр вакытлар иде ул. Кибет киштәләре буп-буш, акчага кытлык... Шуларны уйлап, Себер якларына чыгып китәргә булдык. Андагы яшәү шартларына өйрәнү бер дә җиңел булмады. Әле дә хәтеремдә, 1980 елда Себердә салкынлык минус 57 градуска кадәр җитте. Үзәк котельный бу коточкыч салкынга түзә алмады: сафтан чыкты. Хатын-кызларның барысы да диярлек яшь балалары белән өйдә утыра, ирләре исә 70–100 чакрым ераклыкта эштә... Бер сүз белән әйткәндә, Себер безне чыныктырды, кеше итте! Шуның өчен язмышыма чиксез рәхмәтлемен. Аңа гына да түгел...

### *Алсу*

1983 елда икенче сабыебыз – Алсуыбыз дөньяга килде. Дөрес, мин аны үзебездә – Бөгелмәдә, әтиәнием янында таптым. Шулай булса да, Алсу ул – Себер кызы! Биредә беренче адымнарын ясады, «әттә», «әннә» дигән беренче сүзләрен әйтте, балалар бакчасына йөрде.

Алсуның музыкаль сәләтен дә беренче тапкыр Себердә яшәгәндә күреп алдым. Рәлифкә дә бу хакта әйттем. «Таланты булгач, үстерергә кирәк», – диде ирем һәм икенче көнне үк пианино сатып

## Рәлифкә бер күрүдә гашыйк булган кебек, Уяндыкны да беренче күрүдән үк яраттым.

алды. Шулай итеп, Алсу музыка дөньясына тәүге адымнарын ясый башлады. Күз алдына китерәсезме, ул чакта балалар бакчасына йөрүче кызыбыз шәһәрнең бер башыннан икенчесенә музыка мәктәбенә бара иде! Берүзе, бездән башка... Ул вакытларда дөньялар тыныч, балаларны бүгенгедәй төрле яктан хәвеф-хәтәр сагалап тормый иде шул. Соңрак дөньялар үзгәрә башлады. Аның үзгәрүе безне дә яшәү урыныбызны алыштырырга мәҗбүр итте. Туксанынчы еллар башында «Лукойл» оешмасы барлыкка килгәч, Рәлифне Мәскәүгә эшкә алдылар. Ә безгә исә чит илдә яшәү мөмкинлеге туды.

Рәлиф яшь чактан ук балаларга төпле белем бирү турында хыялланды. Шуңа да туксанынчы еллар башында ул мине балалар белән Лондонга җибәрде. Өлкән улыбыз Марат иң абруйлы колледжда укыды. Алсу исә музыка колледжында белем алды. Беренче көннәрдән үк инглизләрне үзенең музыкаль сәләте белән шаккаттырды ул. Алты еллык колледжны өч елда гел «бишле»гә генә тәмамлады һәм... җырлый башлады.

Марат абыйсының туенда «Телохранитель» фильмыннан «I will always love you» җырын башкарып, барыбызны да таң калдырды ул безнең. Туй барганда ук бер якын танышыбыз: «Алсуны танылган продюсер Валерий Белоцерковскийга күрсәтеп карарга кирәк», – дигән тәкъдим ясады. Һәм без шулай иттек тә. Алсу продюсер янында да алда телгә алынган җырны башкарды. «Бу – гади генә тавыш түгел, бу – алтын тавыш!» – дип, Валерий аны ярты куплеттан ук бүлдерде һәм кызыбызның музыкаль карьерасы белән җитди рәвештә шөгыльләнә башлады.

Нәтиҗә озак көттермәде. 1999 ел башында телевизордан Алсуның режиссер Юрий Крымов төшергән «Зимний сон» җырына клип күрсәттеләр. Икенче көнне иртәнгә инде Алсуыбыз танылган кеше булып уянды... Шуннан китте... Шул ел ахырында аның Минск, Днепропетровск, Киев, Одесса шәһәрләре буйлап гастрольләре узды. Алсу, Россиядән беренче җырчы буларак, бөтен дөньяга билгеле «Universal» тавыш яздыру компаниясе белән озак вакытлы контракт төзеде. 2000 елда исә Россия исеменнән «Евровидение»дә чыгыш ясап, икенче урынны яулады. Шул ук елның җәендә Идел буе шәһәрләре буйлап аның гастрольләре узды. Бөгелмә шәһәрендәгесе аеруча истәлекле булды. Бу шәһәрдә якынча 100 мең кеше яши. Ә Алсуның концертына 86 мең (!) тамашачы килгән иде. Концерт барышында аңа «Бөгелмәнең почетлы гражданины» дигән

# Менә шундый ул безнең Алсуыбыз: бик талантлы һәм шул ук вакытта үтә дә тыйнак.



■ Алсу әнисе Разия ханым белән.

мактаулы исем бирделәр, алсу төстәге «Ока» машинасы бүләк иттеләр. Аңа кадәр ул Казанда концерт куйды, «Татарстанның атказанган артисты» исеменә лаек булды. Шул ук елны 130 мең тамашачы каршында Уфада да чыгыш ясады. Гомумән, 2000 ел Алсу өчен истәлекле вакыйгаларга бай булды. Ул елны Алсу ЮНЕСКОның Париждагы штаб-квартирасының зур залында «Франциядә Татарстан Республикасы көннәре» кысаларында узган концертта да чыгыш ясады. 2003 елда исә Алла Пугачева, Валерияләрне узып, «Россия эстрадасының иң яхшы башкаручысы» исеменә лаек булды.

Алсу – күпкырлы шәхес. Төрле елларда ул үзен дизайнерлык өлкәсендә дә сынап карады, фильмнарда да төште, скрипкада да уйнарга өйрәнде. Кияүгә чыгарга, өч бала табарга да өлгерде. Җырлаудан да туктамады. 2010 елда ул, мәсәлән, Парижда «Дөнья артисты» исеменә лаек булды. Әлеге исем илләр арасында мәдәни багланышларны үстерүгә зур өлеш керткән мәртәбәле артистларга гына бирелә. Сүз уңаеннан, бу исем Алсудан алда безнең илдән Валерий Гергиев белән Владимир Спиваковка гына бирелгән булган. Аның бу югары исемгә лаек булуы белән бик горурланам.

Шунысына куанам, Алсуны өлкәннәр дә, балалар да бик ярата. Ул үзенең җанатарларыннан бик күп хатлар, рәсемнәр, бүләкләр ала. Берьюлы сигез (!) капчык хат алганы, аны бөтен гаиләбез белән утырып укыганыбыз, аннары һәркемгә җаваплар язганыбыз әле дә исемдә.

Татар телендә иркенләп сөйләшә алмаса да, Алсу туган телен бик ярата һәм хөрмәт итә. Балачагында күп кенә җәйләрне ул Марат абыйсы белән биредә – Уяндыкта, картәтисе белән картыйсы янында уздырды. Соңыннан, җырчы булып үсеп җиткәч, әтисенең туган җиренә, картәтисе белән картәнисенә, милләттәшләренә хөрмәт йөзеннән «Туган тел» исемле альбомын чыгарды. Моннан тыш, берничә ел рәттән рус, татар, башкорт эстрадасы йолдызлары катнашында Уяндыкта оештырылган концертларда да чыгыш ясады.

Алсу әле дә Уяндык юлына тузан төшерми. Мөмкинлегенә карап, һәр җәй саен бирегә кайтырга тырыша. Минем кебек үк Уяндыкның саф һавасын ярата, бирелдәге тынычлыктан җанына рәхәтлек ала. Татар халык ашларына да битараф түгел. Бик теләп кыстыбый, тәбикмәк, бәлеш кебек милли ашларны пешерә. Кыстыбые аеруча тәмле килеп чыга.

Миннән күпләр: «Алсу белән горурланасыңмы?» – дип сорыйлар. Горурланмаган кая инде?! Алсу – нәселебезнең йөзек кашы! «Музыкага сәләт кемнән бирелгән аңа?» – дигән сорауны да еш бирәләр. Сәләтне дә ул башлыча шушыннан – Уяндыктан, җырга-моңга гашыйк нәсел тамырларыннан алган. Аның картәтисе Рәфил дә, әтисе Рәлиф тә, әтисенең энесе Рәзиф тә өздереп гармунда уйныйлар, матур итеп җырлыйлар.

Без генә түгел, уяндыклылар да Алсу белән бик горурланалар һәм аның кайтуын һәрвакыт сагынып көтеп алалар. Алсу үзе дә якташларының йөзенә кызыллык китермәслек итеп эшләргә һәм иҗат итәргә тырыша. Үзенең нәсел тамырларының шушында – Уяндыкта икәнлеген дә һәрбер интервьюсында диярлек телгә ала.

## *Үзем турында*

2012 елдан бирле Уяндыкка бик еш кайтам, монда яшим дисәм дә була. Сафиннарның төп нигезләрен яңарту, үзебез төзегән кунакханә комплексына җитәкчелек итү, авылны төзекләндерү белән шөгыльләнәм. Буш вакытларымда Уяндыктагы ахирәтләрем белән очрашам, спорт белән шөгыльләнәм, бакчада казынам, кыскасы, бер генә минут та тик торганым юк.

Миннән еш кына: «Син үз яшеңә караганда яшьрәк күренәсең. Берәр диетада утырасыңмы, әллә махсус препаратлар кулланасыңмы?» – дип сорыйлар. Яшермим, нәкъ шулай – төрле диеталарда утырып, махус препаратлар кулланып ябыгырга тырышкан чаклар да булды. Күптән түгел исә үзенчәлекле диетага – чи азык кына ашап торуга күчтем. Ышанасызмы, ике ай дигәндә 7 килограммнан котылдым. Бәлки, кемнәргәдер кызык та булыр, әйдәгез, кыскача гына көндәлек рационым белән таныштырып китим әле.

Иртән торуга бер стакан җылымса суга бер бал кашыгы чәй содасы салып эчәм. Аның артыннан

ике әфлисун ашап куям. Иртәнге йөгерүдән соң бик күп яшел тәмләткечләр салынган, бүрттерелгән ясмык (чечевица), борчак, көнбагыш мае кушылган кыяр-помидор йә булмаса кәбестә-кишер салаты ашыйм. Шуңа аз гына зәйтүн мае да салам. Көн дәвамында виноград, киви, мандарин, алма, хөрмә кебек ризыклар белән тукланам. Суны җаным теләгәнчә эчәм. Төгәлрәк итеп әйткәндә, көненә ике литр су эчәргә тырышам. Беләсезме, шушылай туклана башлагач, үземдәге энергиянең тагын да артуын, тәнемдә ниндидер җиңеллек барлыкка килүен тоя башладым. Иттән, итле ризыклардан башка да яшәп булганлыгын аңладым. Үз яшәү рәвешемне беркемгә дә көчләп тагарга җыенмыйм. Ләкин шуны төгәл беләм, сәламәтлекнең нигезе иң беренче чиратта дөрес туклануга кайтып кала.

Яраткан шөгылем дә бар. Соңгы елларда газета кәгазеннән декоратив кәрзиннәр, читлекләр, вазалар үрергә өйрәндем. «Бу вак эшкә ничек түземлегең җитә?» – дип сорый танышларым. «Күңелеңә ошаган шөгыль табу – үзе зур бәхет бит!» – дим аларга. Газетадан ясалган «җеп»ләрдән үргән тәүге кәрзинемне Мәскәү мэры Юрий Лужковка бүләк иткән идем кайчандыр... Бүген инде балаларымның, туганнарымның, дусларым һәм танышларымның һәркайсында минем кул белән эшләнгән мондый бүләк-сувенирлар бар.

Ел саен 4 августта – туган көнемдә Уяндыктагы йортыбызда төрлесе төрле җирдә яшәүче балаларым һәм оныкларым җыела. Бу көнне авылда зур концерт оештырган вакытларыбыз да булды. Туган көнемне шулай зурлап үткәрүемнең үз сере бар. Оныклар (бүген мин 12 оныкның дәү әнисе!) буыннан-буынга күчеп килүче гаилә традицияләрен белеп үсәргә тиеш дигән фикердәмен. Рәлифнең уйлары да минекенә аваздаш. Чөнки ул да тормышның төп мәгънәсе гаиләдә – балалар һәм оныклар белән якыннан аралашуда икәнлеген яхшы аңлый. Шуңа да һәркайсыбызның туган көнен ел да зурлап үткәрергә тырыша. Ирем турында сүз чыккач, тагын бер нәрсә әйтеп узыйм әле. Рәлиф – искиткеч туган җанлы, юмарт һәм акыллы кеше. Минем уемча, аның кебек игелекле кешеләр бу дөньяда санаулы гынадыр!

## *Кунакханә*

Күпләр беләдер, соңгы ун ел эчендә Рәлифнең тырышлыгы белән Уяндык танымаслык булып үзгәрде. Башта ирем бирегә асфальт юл түшәттерде, су, табигый газ үткәртте, теплица, мәчет, күп кенә авылдашларына яңа йортлар салдырды. Шуның белән беррәттән, күршедәге Андреевка авылында да шундый ук күләмле эшләр алып барды: чиркәү, мәктәп төзетте, сырхауханәгә реконструкция үткәрде. Бу эшләрне тәмамлауга, Уяндык авылындагы биек тау башында кунакханә комплексы төзетә башлады.

Уяндыкта кунакханә төзү уен Рәлифкә мин әйттем. «Туган авылыңның табигате оҗмах почмагына тиң бит. Әйдә, шуны Европа тибындагы бер матур авылга әйләндерәбез», – дидем. Рәлиф бу тәкъдимне шундук күтәреп алды, һәм берничә ел элек Уяндыкта масштаблы төзелеш эшләре башланды.

Бүген бу кунакханә комплексы турында инде республикадан читтә дә яхшы беләләр. Бирегә Россиянең төрле төбәкләреннән ял итәргә киләләр. Кышын тау чаңгысында шуып рәхәтләнсәләр, җәен атта йөриләр, балык тоталар, су керәләр. Ә шулай да туристлар бирегә иң беренче чиратта саф һава суларга, урман шавын тыңларга, табигатьнең матурлыгына сокланырга килә.

Минем иң зур хыялым – кунакханәне «Матурлык, мәхәббәт, сәламәтлек үзәге»нә әйләндерү иде. Бу инде чынга ашып килә. Уяндыкта «Матурлык һәм сәламәтлек» мәктәбе эшли башлады. Гүзәл затларга матурлык, үз-үзеңне карау, дөрес туклану буенча лекцияләр укыйбыз, алар белән бергәләп Агыйдел буендагы әрәмәлектә дару үләннәре һәм җимешләр, кунакханә янындагы урманда гөмбә җыябыз, аннан кайткач, шуларның файдасы турында «түгәрәк өстәл»ләр үткәрәбез. Лекцияләр укырга Россия күләмендә танылган табибларны, диетологларны, дару үләннәре буенча белгечләрне чакырабыз.

Кунакханә каршында бию дәресләре оештыру, күпфункцияле кинотеатр ачу, шәхси ярдәмче хуҗалыкны киңәйтеп, анда экологик яктан чиста продукция җитештерүне арттыру, урман фонында кардай ак интерьерлы никах теркәү мәйданчыгы булдыру, яр итәгендәге күл буенда пляж зонасы ачу, балык тоту урыннары ясау... Билгеләнгән уй-максатлар исемлегем шундый озын әле! Беләм: боларның берсе дә тормышка ашмастай уй-хыяллар түгел!

Шушы комплекс ачылганнан соң, кырыкка якын кешегә яңа эш урыны булдырылды, авыл халкының тормыш-көнкүреш шартлары күзгә күренеп яхшырды. Кайчандыр «перспективасыз» мөһере сугылган Уяндык бүген Башкортстандагы татар районының – Илешнең генә түгел, илнең иң матур авылына әйләнде! Әнә шунысына иремнән дә ныграк сөенәм!

## *Йомгак*

Миңа еш кына: «Син бик бәхетледер инде», – диләр. Әйе, бәхетлемен. Гомер сукмагыннан атлаганда ныклы терәк булучы ирем – Рәлифем, гаилә традицияләрен уңышлы дәвам итүче акыллы-тәртипле балаларым, минем өчен өзелеп торучы оныкларым бар. Шулар бәхет түгелмени?! «Сөембикә»не укучы хатын-кызларга да иң беренче чиратта гаилә бәхете телләр идем. Гаилә бәхетен дөньядагы башка берни дә алыштырмый!

Венера МӘҖИТОВА язып алды.

Фотолар: Разия Сафинаның шәхси архивыннан.

# ИР БИРМӘК – ҖАН БИРМӘК


Фото: www.pixabay.com

**Алдыбызга китергән чәйләргә ул да, мин дә кагылмадык. Шул килеш суындылар… Алдан килешкәнчә, Гөлия белән шәһәр үзәгендәге кафеларның берсендә очраштык без. Исәнләшүгә, аның белән нидер булганын сизенгән идем анысы. Тик әңгәмәбез менә бу юнәлешкә кереп китәр дип башыма да китермәдем. Өстәл янына утыруга ул миңа сүзсез генә телефонын сузды. Фотосурәттә – кияү белән кәләш. Икесе дә бәхетле елмаялар.**

**– Туй? Ә кемнең туе бу? – дим.**

**– Иремнеке… Кичә аның туе булды. Булган…**

**– Ничек инде иремнеке? – бу сорауны бирүемне үзем дә сизми калдым.**

**– Әйе, аныкы… Дөнья булгач, шулай да була икән. Туйдагы кунакларның берсе җибәргән. Кем икәнен белмим… «Котлыйм», – дип яздым.**

**Мин тәмам сүзсез калдым.**

– Сезнең белән очрашудан баш тартасы булгандыр инде… Кичә бу фотоны алгач, бик авыр булды. Югалып та калдым. Шуңа телефоннан әйтәсем килмәде, күрешкәч, барысын да аңлатырмын дидем. Без бер ел элек аерылышкан идек инде. Сез бит әле анысын да белмисез… Әмма аның белән бергә тормасак та, сорауларыгызга барыбер җавап бирә алырмын дип уйладым, шуңа сезгә «юк» димәдем…

Чит ил кешесенә кияүгә чыгып, ире янына яшәргә китеп барган кызларыбыз байтак. Ә менә, киресенчә, кияү егетләренең безгә күченеп килгәннәре алай күп түгел. Әмма бар. Мондый адымны олы мәхәббәт хакына гына ясап буладыр… Гөлиянең ире – шундыйларның берсе. Әти-әнисен, туганнарын, дусларын калдырып, Татарстанга күчеп кайткан ул. Башка мохиттә, башка тирәлектә үскән кешегә бездә яшәп китү, урнашу, эш табу, карьера ясау җиңел генә була алмый. Мондый гаиләләрнең үз проблемалары, үз авырлыклары – без шушы хакта сөйләшергә җыенган идек. Тик мин ишетергә теләгән шәрык әкиятенең генә эчтәлеге үзгәргән булып чыкты менә.

Алар университетта танышалар. Гөлиянең кандидатлык диссертациясе яклап йөргән чагы була. Факультетларына магистратурага Төркиядән бер төркем студент килеп төшә. Арада ул да була… Юк, юк, Гөлия аңа бер күрүдән гашыйк булмый. Ул, гомумән, ирен өзелеп яратуы турында бер сүз дә әйтми… Бәлеш пешереп, бер көнне төрек егетләрен үзенә кунакка чакыра ул. Җиһан аны, бәлки, шул көннән соң якын итә башлагандыр да. Ярты елдан студентлар кире үз илләренә кайтып китә. «Мин сине яратам, барыбер сиңа өйләнәчәкмен», – ди Җиһан саубуллашканда. Сүзендә тора – нәкъ ярты елдан соң ул кире килә. Үзе генә түгел, әти-әнисе, апалары, туганнары белән. Колшәриф мәчетендә никах укыталар, ә туйлары Төркиядә уза. Бу юлы Гөлиянең әти-әнисе, туганнары барысы бергә җыелып кунакка бара.

Ун ел эчендә төрлесе булгандыр: бер гаиләдә дә савыт-саба шалтырамый гына тормый анысы. Шалтырый да тына. Тик Гөлия белән Җиһан арасында чыккан соңгы тавыш кына нигәдер тынарга ашыкмый.

– Безгә аның туганнары кунакка килгән иде. Әтисе һәм кияүгә чыкмаган ике апасы. Кайнанам исән түгел инде, яман шештән мәрхүм булды… «Нишләп Җиһан һаман Төркиягә кире кайтмый?» – дип, зур җәнҗал кузгаттылар. Син безне хөрмәт итмисең, диделәр… Аның кайтырга җыенмавын гаиләсе гел миннән күрде. Югыйсә иремнең бу хакта бөтенләй сүз кузгатканы

## Күңелеңдә һаман да ярату булса, аерылышуга салкын акыл белән әзерләнү кыенрактыр.

булмады. Башта укыды, аспирантура тәмамлады. Аннары эш табылды. Тел өйрәнде. Татарча сөйләшә, русча. «Монда укыганда русча да өйрәнергә кирәк», – дип, мин аны курсларга йөрттем. Кандидатлык диссертациясен дә якла, дип әйтсәм дә, анысын эшли алмады. Үҗәтлеге җитмәде. Зур тырышлык кирәк моның өчен, башлаган эшне ахыргача җиткерә белү, аны ярты юлда калдырмау. Хәер, бу гаиләдә дә шулай. Ниндидер проблема килеп туса, башны комга тыккандай, аңардан качу бар иде Җиһанда. Бар нәрсәне дә уртага салып сөйләшә белмәдек. Кызганыч... Тик мәхәббәт булса, гаилә барыбер сакланып кала бит ул – безгә, күрәсең, ул да җитмәде. «Синең өчен, сине ятратканга гына килдем. Бөтен тормышын ташлап яраткан кеше генә килә ала», – дия иде ул миңа. Димәк, мәхәббәте ул кадәр үк көчле булмаган дип уйлыйм хәзер.

Шул тавыш-гаугадан соң аларның арасы нигәдер яңадан көйләнеп китә алмый. Җиһан үзен бөтенләй башкача тота башлый. Бик соң кайта. Ап-ак күлмәгендә кершән эзләре дә күренгәли. Гөлия, мөгаен, хаклыдыр: читтә кешесе булмаса, ирләр өйдән болай гына чыгып китми инде... Юк, бөтен гаепне дә иренә генә аударып калдырмый ул. «Докторлык диссертациямне яклау алды иде. Гел шуның белән мәшгуль булдым. Иремә вакытым җитеп бетмәгәндер. Ә ирләр бала белән бер, аларга һәрвакыт игътибар кирәк», – ди. Якынаю юлларын эзләргә тырышып карый, әмма файдасыз...

Аерылышу турындагы гаризаны Гөлия үзе яза. Ире: «Мин мондагы законнарны белмим, син үзең барысын да рәсмиләштер инде», – ди. Моңарчы да гаиләдә шулай кабул ителгән була: документлар белән нинди генә эш чыкса да, аны Гөлия хәл иткән. Иренә мондый проблемалар калдырмаган.

– Язуын яздым гаризаны, әмма ул судка килер дип уйламадым. Башкаларның шулай булганын ишеткәнем бар иде. Юкка өметләнгәнмен – ул килде... Безне беренче утырышта ук аердылар. Гаилә институты юкка чыгып бара диләр, тик аны саклау өчен тиешле оешмаларның нидер эшләвен сизмәдем. Киләсең, талон алып, үз чиратыңны көтәсең һәм... аерылып кайтып китәсең. Үзебезне әйтмим әле, яшьләр бит кайчак бу адымны ачу белән дә ясый. Шундый чакта читтән бирәүнең – психологның яки дин әһеленең бер сүзе җитәр иде араларны көйләргә. Мин дә үзебезне үгетләүләрен көттем бугай... Ул адвокаты белән килгән иде, суд бинасыннан чыктык та икебез ике якка киттек.

Ә өмет... Ул Гөлиянең күңелендә әле кичәге көнгә кадәр барыбер яшәгән. «Бөтенләйгә аерылышуыбызны яңа аңладым. Кайтыр, кире кушылырбыз кебек иде, – ди. – Бала бар бит...»

Улы белән Җиһан хәзер атнага ике тапкыр күрешә: чәршәмбе һәм якшәмбе көннәрендә. Ул бу гадәтен хәтта кичә, үзенең туе көнне дә бозмаган. Улын алып, икәү бергә чәчтарашханәгә барганнар. Әтисенең үз туена матурлануын уллары да әнисе телефонына шушы фото килеп төшкәч кенә белгән. «Аңа бигрәк тә авыр булды», – ди Гөлия.

Язмышның байтак хатын-кызлар өлешенә тигән бу сынавын инде Гөлиягә дә күтәрәсе.

– Сезнең сорауга әйләнеп кайтыйк... Ире чит илдән күчеп килгән гаиләләрдәге проблемаларга. Әйе, алар бар һәм аз түгел. Иренең умыртка сөяге нык булса, андый хатын-кызга җиңелрәктер. Юк икән, тормышны алып бару аның үз өстендә кала. Мөмкин булган кадәр, мин дә уртак проблемаларны үзем чишәргә тырыштым. Төркия белән ике арада кризис килеп туу Җиһанның да эшләрен катлауландырды. Хәтта безнең мөнәсәбәтләргә дә тәэсир итте ул.

Мин аны кабат моннан өйләнер дип уйламаган идем. Туганнары ничек ризалык биргән, шаккатам. Ирем – гаиләдә бердәнбер ир бала, алардагы гореф-гадәтләр буенча, ул төп нигездә яшәргә тиеш. Җиһанга Россия гражданлыгы алу артыннан йөри башлагач та, бөтенләйгә калырга җыена бугай дип, бик борчылган иде алар. Ә ул менә тагын хаталанды. Дөрес адым түгел бу. Элеккеге ирем булганга гына әйтмим. Хәзер инде бу мәсьәләдә фикерем нык: гаиләне бары тик үз милләтең кешесе белән генә корырга кирәк. Бер генә катнаш гаиләнең дә чын мәгънәсендә бәхетле булуына ышанмыйм. Җиһан белән бергә яшәгән елларда андый гаиләләр белән байтак аралаштым: һәркайсының үз бәхетсезлеге.

Төрекләрдә гадәт шундый: балалары белән хатыннарын һәр җәйдә бер-ике айга әти-әниләре янына яшәргә җибәрәләр. Безнең әти белән әни беркайчан да аерыммаерым ял итмәде, шуңа күрә мин үзем моңа бик авыр ияләштем. Бармасам, туганнары үпкәли: «Сагынмыйсың, безне яратмыйсың... Оныкны сагынабыз, аны күрәсебез килә», – диләр. (Дөрес, әлеге баруларның уңай яклары да байтак булды: бу илнең тормыш-көнкүрешен эчтән күрдем.) «Оныкны бездә калдырмыйсың», – дип тавыш чыгардылар. Улымның үзенең дә анда озакка каласы килмәде: кечкенә иде бит әле. Туганнары юкка гаепләде, ирем: «Китәбез», – дисә, мин аның белән Төркиягә күченергә риза идем. Моңа үземчә әзерләндем дә. Улыма да, үземә дә Төркия гражданлыгы эшләттем. Дипломнарымны Төркия биргән югары белемгә эквивалент итүгә ирештем. (Эш турында алдан ничек кайгыртмыйсың инде?!) Хәер, андый мөмкинлек килеп чыкса, мин хәзер дә китеп барырга әзер. Телне беләм, документлар тәртиптә: төпле эш кенә кирәк...

## Ирегез белән аерылып йөргән көннәрдә яныгызда сер сыярлык, киңәш бирә алырлык берәр акыллы ахирәтегез булу кирәк.

Иремнең апалары: «Син гел үз эшләрең белән мәшгуль», – дип битәрләделәр. Анысы хак иде инде: фәнгә бер кереп киткәч, башкача булмый. Эшем белән, чынлап та, бик мавыктым: күбрәк үз дөньямда яшәдем. Җиһан да миңа еш кына: «Ә докторлык сиңа нәрсәгә, ул сиңа ни бирәчәк?» – дия иде. Ә мин хатын-кыз үсәргә тиеш дип санадым. Өстемә халат, аягыма башмак киеп өйдә генә утыра алмыйм. Үзгәрмәдем ләбаса, ул мине сайлаганда ук шундый идем. Шулай булгач, нигә мине моның белән битәрләргә? Тик медальнең икенче ягы да бар. Ир-аттан бер башка өстен икәнсең, ул үзендә комплекслар таба башлый һәм... үзеннән түбәнрәк хатын-кызны эзләргә керешә. Аннан, әлбәттә, таба...

Безнең сүз кабат аерылышуга, аның авырлыкларына кайтып төшә. (Авырткан җирдән кул китми!)

Ире белән аралар суынуын сизеп, эшләр аерылышуга баруын аңласа, теләсә кайсы хатын-кыз моңа алдан әзерләнергә тиеш дип саный Гөлия.

– Иң мөһиме: ялгыз калган очракта хатын-кызның эше һәм торыр урыны булырга тиеш дип саныйм. Фатирны ипотекага мин алган идем, бу яктан проблемам булмады. Мөнәсәбәтләр суына башлауга, машина йөртү курсларына язылдым. Бала тиздән мәктәпкә керә, аны озатырга, каршы алырга, түгәрәкләргә йөртергә машинасыз ничек өлгерәсең? Юк, машинасыз тормыш итү авыр булачак. Аннан, ире белән мөнәсәбәтләре берничек җайга салынып кебек тоелмаса, хатын-кыз әкрен генә акча җыя башларга тиеш дигән фикердә мин. Кара көнгә... Бу бик кирәк! Үзен бер ел тәэмин итәрлек акчасы булырга тиеш аның кулында. Мин үзем моны эшли алдым... Кемдер мине салкын канлылыкта гаепләргә мөмкин. Эшләрнең аерылышуга барганын чамалыйсың бит ул... Бик тырышып, ике араны көйләргә дә азапландым, шул ук вакытта начарына да әзерләндем. Матди яктан да да, психологик яктан да. Кырт кисеп аерылу яклы түгел мин.

Аерылышуны тагын ничек җиңелрәк кичерергә? Мөгаен, аны бөтен хатын-кыз булдыра да алмас. Ничегрәк итеп әйтим икән... Янында берәр кеше булырга тиеш. Ир кеше... Чынбарлыкта ул юк икән, аны бит уйлап чыгарырга да була. Һәм шуңа гашыйк булып йөрергә. Шулай итеп җандагы бушлыкны тутырырга. Шул моментта гына булса да бу бушлыкны тутырып торырга тиеш хатын-кыз. Гомумән, әлеге ситуациядә үзеңнең психологик халәтеңне бик нык кайгыртырга кирәк – сәламәтлегебез шуңа бәйләнгән. Аннан шунысы да бар: син бәхетле булсаң, балаң да бәхетле булачак. Иң беренче аның турында уйлыйсың, шуңа күрә үзеңне ясалма рәвештә булса да шушы халәттә тотасың. Моңа ничек ирешәсең – анысын үзең хәл итәсең.

Минем үземне ул чакта эш коткарды: елап утырырга вакытым юк – диссертация яза идем. Атнага ике тапкыр күрше шәһәргә – фәнни җитәкчем янына барып йөрим. Кеше беркайчан да берберсе белән болай гына очрашмый. Сез дә бит яныма очраклы гына килмәдегез, миңа бүген күңелемдә булганнарны бушатырга кирәк иде. Рәхмәт, тыңлыйсыз... Фәнни җитәкчем хатын-кыз иде, ул да беренче иреннән аерылган булып чыкты. Иң авыр көннәрдә ул миңа терәк, киңәшче, ярдәмче булды. Әмма аңа җиңелрәк: алар инде икесе дә үз тормышларын көйләгәннәр – бала хакына дусларча аралаша алалар. Ә күңелдәге үпкәләр... Алар, әлбәттә, бар. Тик фәнни җитәкчем: «Алар үтәчәк», – ди. Бу көнне миңа исә әле котәргә дә котәргә....

Аерылышкан хатын-кызларның күбесе иллюзияләр белән яши. Аралар өзелүгә үземне әзерләдем – холкымны нығыттым, миндә иллюзияләр юк дип саный идем. Кичә аңладым: миндә дә булган алар. Бу фото бөтен дөньямның астын өскә әйләндерде. Иреңнең башкага өйләнүен ишетү тагын да яманрак икән... Улым кичә бик каты елады. Без аерылышкач, ул болай да өлкәнәеп китте – сөйләшүләренә кадәр үзгәрде. Аның өчен чыннан да зур хәсрәт булды бу. Мин аңа булдыра алганча барысын да аңлатырга тырыштым. Әтисе турында бер начар сүз дә әйткәнем юк. Ул – мин сайлаган кеше, минем хата, монда баланың гаебе юк. Аннан ата кешене яманлау балада комплекслар гына тудырачак.

Аларның очрашуларына беркайчан да каршы булмадым. Алга таба нидер үзгәрерме, әлегә әйтә алмыйм. Өченче кеше – аның яңа хатыны да бар бит хәзер. Без аны бик теләсәк тә, инде читкә куя алмаячакбыз... Ул баланы ошатырмы, ата белән улның аралашуына киртә куймасмы – аңардан да бик күп торачак. Боларга тормыш тәҗрибәсе җитәрме – аңа бит әле 25 яшь кенә. Иремнән ун яшькә кече ул. Мине «сөендерергә» ашыккан туй кунаклары бу хакта да яздылар...

Минем яшьтә исә кем беләндер яңа мөнәсәбәтләр кору күпкә катлаулырак булачак. Ышанычлы ир-атлар аз хәзер... Гаиләле кешегә бөтенләй якын килергә ярамый – табу. Ә аерылышканнарның минуслары күп. Аның балалары белән уртак тел табарга кирәк булачак, аңа – минеке белән. Ә таба алмаса?! Әйе, хатын-кызга кабат гаилә кору һәрвакыт авыррак...

...Мондый язмышларны язганда, кемдер өчен йә гыйбрәт, йә сабак булыр дип уйлыйсың. Бу юлы да үзе өчен нәтиҗәләр ясаучылар табылмый калмас. Әкиятләрнең ахыры матур булганны барыбыз да ярата, шуны көтә дә бит, нишләтәсең, тормыш башкарак шул...

Гөлнур САФИУЛЛИНА

# ИР-АТ БЕЛӘН ХАТЫН-КЫЗ АРАСЫНДА ДУСЛЫК БУЛА АЛАМЫ?



Марат КӘБИРОВ

Хатын-кызлар арасында бик якын күрешеп йөргән кешеләрем күп. Ихластан аралашабыз, бер-беребезне якын күрәбез, ярдәм дә итешәбез. Күпләренең ирләре белән дә дустанә мөнәсәбәттә. Кайберләренеке – таныш түгел, ә кайсыларыныкы көнләшеп тә куя икән. Үземнең хатын да вакыт-вакыт шаярткан булып, шелтәләп ала:

– Дуслар гынамы соң сез, арагызда андый-мондый хәл юкмы? – ди.

– Юк! Һәрхәлдә, мин нәрсәгәдер өмет итеп йөрмим. Башыма да кереп чыкмый.

– Белмим, – дип, һаман үзенекен тукый теге, – хатын-кыз белән ир-ат арасында дуслык була аламы икән?

– Ир-егет бөтен кеше белән дә дус була ала, хәтта җәнлек-җанвар, тимер-томыр белән дә, – дип шаяртырга маташам.

Ә үзем уйлыйм. Туктале, дуслыкмы соң бу? Дуслык нәрсә соң әле ул?

Психологлар болай дип әйткән инде. Кешеләрнең төрле факторлар тәэсирендә барлыкка килгән күңел якынлыгы: психологик ярашу-омтылышлар уртаклыгы, үзара хөрмәт, ярдәмләшү, аралашуның бер дулкында булуы дуслык дип атала. Алар белән бәхәсләшеп булмый бугай. Гади генә әйткәндә, бер-береңне аңлый алу инде ул.

Әйтик, икегез ике өлкәдә эшлисез икән, хатыныңны ничек кенә яратсаң да, аның белән үз һөнәрең буенча фикер алыша алмыйсың. Ул нинди генә гыйлем иясе булса да, синең һөнәрнең нечкәлекләрен бөтен тулылыгында аңлап бетерми. Ә синең белән бергә эшләгән кеше аңлый. Фикерләр уртак, омтылышлар бер, үзара хөрмәт булганда дустанә мөнәсәбәт барлыкка килә. Ихластан аралашасың, серләр бүлешәсең…

Әгәр кемдер сине тыңлый һәм аңлый ала икән, кирәк вакытта терәк була ала икән, бу инде дуслык. Монда романтик хисләргә, җенси мөнәсәбәтләргә хәтта урын да калмый, алар артыкка әверелә. Һәрбер кеше үзен ишетүгә, аңлауга мохтаҗ. Мәхәббәттә бәхетлеләр дә шулай. Ә сине аңлый алган кешенең ир-атмы, хатын-кызмы икәне мөһим түгел.

Ләкин дуслык – үз урынында, мәхәббәт үз урынында кала. Гаилә – беренчел. Дуслар күп булырга мөмкин, ә гаилә берәү генә. Мәхәббәтсез гаилә – гаилә түгел.

Бу – ике як та саф күңелле булган очракта шулай. Идеалда дип әйтәсем килми, үземнең дә якты дусларым күп, танышларым арасында да ир-егет белән хатын-кыз дуслыгына үрнәк булучылар бар.

Ә тормышта төрле хәлләр була.

Дуслыкның бит аның мәхәббәткә әйләнеп китү мөмкинлеге дә бар. Әгәр кыз белән егет арасында шундый хәл туа икән, бу – бик яхшы. Димәк, гаилә ныклы булачак. Мәхәббәт үзе үк дуслыкны да эченә ала торган төшенчә бит ул: гаилә әгъзалары үзара дус булырга тиеш.

Әгәр инде гаиләле кешеләр арасындагы дуслык мәхәббәткә әйләнеп китсә… Монысы бераз хәтәррәк. Әлбәттә, ныклы гаиләләрдә андый хәл була алмыйдыр инде. Ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләр бозылып, мәхәббәтләре сүрелгәнгә шулай килеп чыгадыр… Монда хәтта сүз әйтү дә авыр. Тик барыбер… Гаиләне җимерә торган дуслык… Сәер яңгырый, шулай бит?

Гомумән, дуслык ул беркадәр куркыныч нәрсә. Ул төзи дә, җимерә дә ала. Кем нинди ният белән дуслаша бит. Берәүнең дә эчен ачып карап булмый. Үзара якын мөнәсәбәттәге кешеләрнең максатлары төрле булырга мөмкин. Икәүнең берсе мәхәббәтен аңлатырга кыймаган өчен генә дус булып кылана ала, мәсәлән, үз вакытын көтә. Яки икесе дә шулай. Яки кайсыныңдыр күңелендә мәхәббәт тә түгел, ә нindидер максатка ирешү өчен җай эзләү булырга мөмкин.

Файда, табыш теләге… Монысы инде ир-ат белән хатын-кыз арасындагы дуслыкка гына кагылмый. Дуслыкның төбендә нәрсә ятканын төгәл белеп булмый. Дуслык битлеге астында теләсә нәрсә булырга мөмкин. Тик без чын дуслык турында сөйлибез, шулай бит?

Шуңа күрә мин ир-ат белән хатын-кыз арасында дуслык була ала дип исәплим. Кем белән кем арасында туса да, ул – чын дуслык булсын. Якты дуслык.

**«Фираяның өстәл артында язып утырганын күргәнем булмады», – диде шагыйрәнең гомер юлдашы – ире, язучы, тележурналист, профессор, һәвәскәр бакчачы Фарсель Зыятдинов. Халык ничә еллар буе телдән төшерми торган популяр җырлар, дистәгә якын шигырь китаплары, тәрҗемә әсәрләре ничек туган соң алайса, дияр укучым? Хәер, аның үзенең дә: «Бүген шигырь язам, дип утырганым юк, үзеннән-үзе туа җыр, тик кәгазьгә төшерергә генә өлгер», – дигәне булды. Фираяның иҗат җимешләре – Күкләр бүләгедер дип фаразласак та... Олы хезмәтнең тырышлык, үҗәтлек нәтиҗәсе икәне сер түгел.**



# ҖЫР БУЛЫП КАЛДЫҢ

Бер җәйне Фирая белән икәү язучыларның Васильеводагы иҗат йортына путевка алдык. Рәхәтләнеп ял итик дисәм, дустымның хәтта дәвалану курсы узарга да вакыты юк. Фәнни-популяр әсәрме, брошюра диимме – тәрҗемә итәргә ниндидер эш алып килгән. Шундый буталчык, авыр текст өстендә Фирая баш күтәрми атналар буе утыра... Берсендә таң атар-атмас уянып киттем дә, балконга ут яктысы төшкәнгә аптырап, торып утырдым. Фирая тәрәзәсеннән бөркелә икән яктылык. Әллә авырып киттеме, ярдәм кирәкмиме, дип, сак кына ишегенә кагылдым. Төн буе тәрҗемә белән утырган: «Йөз бите калды, өлгерә алмыйм», – ди.

Чиста-саф күңелле, тормышка, яшәүгә, кешеләргә гашыйк, үзенә бертөрле – садә, гади дә, ихлас-эчкерсез дә иде ул. Аның шигърияте дә халыкчан, гади, үтемле булганга укучы яратып кабул итте. «Без бит җиргә якты, җылы ямь өстәргә яратылган! / Китмим әле яшьлегемнән – / Яз гөлләре арасыннан», дигән юлларны күпләрнең үзенеке итеп кабул итүе гаҗәп түгел. Хатын-кызга хас хиссият, табигыйлык тарта ич. «Син дә шулай сагына калсаң, / Карама җилләренә... / Җыр булып килеп керерсең / Наз тулы йөрәгемә!» Татарстан китап нәшриятында эшләгәндә Фираяның Луиза Батыр-Болгари белән серләре килеште. Композиторның Фирая Зыятдинова шигырьләренә язган көйләрен халык яратты. Бу – һәр иҗатчы өчен зур бәхет.

Фирая белән Казанга килгәч тә (ул чагында аның фамилиясе Шиһапова иде), университетның татар филологиясе бүлегенә керү имтиханнары биреп йөргәндә танышкан идек. 1963 елның августы иде бу. Ул тыйнак, сөйкемле, күп укыганы, күп белгәне сизелеп тора, әмма «мин беләмлек» чирен йоктырмаган. Холык-фигылебез дә бертөслерәк: икебез дә шигъриятькә гашыйк, балалыктан чыгып җитмәгән, самими. Беркатлылык, теләсә кемгә ышанучанлык та ят түгел. Казанда борын төртердәй дус-иш, туган-тумача юк. Холлда кулга төшкән «фатирга кертәм» дигән белдерүне тотып, Фирая, мин, Фәния исемле кыз – өчәүләп Федосеев урамын эзләп киттек. Таптык. Кайтып кунарлык бәләкәй бүлмә, хакы шалкан бәясе үк булмаса да, түзәрлек. Университетка якын. Шарты: фатир хакын шундук түләп куясы. Барлы-юклы акчаларны җыеп тоттырдык та әйберләребезне алып килергә вокзалга йөгердек.

Килсәк... Безне «фатирга керткән» хатын үзе дә юк, эзе дә. Казан кырыкалдарлары безне – авыл балаларын шулай акылга утыртты. Әмма дуслыкны сынау өчен ярады, өч тиенне икегә бүлеп яшәргә туры килде.

Бер урынга дүрт-биш абитуриент, татар филологиясе бүлегенә конкурс үтеп булмаслык зур иде. Рус теле белән дуслыгым чамалы: авылда рус әдәбиятын укытмадылар, рус теле укытучысы булмады, ә Иж-Бубый урта мәктәбендә «ташлама» ясаулары... юлыма киртә корды шикелле. Югыйсә төшеп калганнардан түгелмен: аттестатта билгеләр әйбәт. Яшь язучылар семинарында катнаштым, язам. Исемле, олы әдипләребез Мәскәүгә – Максим Горький исемендәге әдәбият институтына керергә үгетли. «Русча белмим!» дип тискәремә каттым. Рус теленнән язма эш монда да, куркыта! Фирая юата, «булдырасың!» ди. Лидерлыкка омтылмаса да, гел беренчеләр рәтендә булды Фирая, яхшы укыды. Әтнә районы бәләкәй Мәмәш авылында туып-үскән, урта мәктәпне колхозда эшләп, «экстерн» белән тәмамлаган кызның рус телен мөкәммәл белүе, эрудицияле, укымышлы булуы гаҗәп, бер караганда... Сүз дә юк, табигать сәләтле, булдыклы итеп яраткан аны. Мин калтырап-куркып торганда, ул имтиханга беренче булып керер иде дә «отлично» эләктереп чыгар иде.

Арабыздан беренче булып кияүгә киткән кыз да Фирая булды. Фарсель – радиожурналист, берьюлы университетта, авыл хуҗалыгы институтында укый. Акыллы, сылу-чибәр кызга ул бер күрүдә гашыйк иде.

Яшь пар фатирга чыкты. Кызлары Алсу туды. Уку, сабый багу җиңел булмагандыр Фираяга, зарланырга яратмый иде, сер бирмәде, сынатмады. Дустыбызның кызын без дә якын иттек. Әмма... сабый кыска гомерле булдымы, чир тидеме, күбәләк булып җаны мәңгелеккә очты. Әни булу тәмен тойган Фираябыз ике яше тулып килгән кызын югалтуны гаять авыр кичерде. Бер-бер артлы дөньяга килгән уллары Айдар, Айваз, Айнур да кыз баласын югалту сагышын баса алмады шикелле. Айдар, әтисе кебек эшчән, тырыш, булдыклы егет, үз юлын тиз тапты, өйләнде, бизнеска кереп китте. Ә менә уртанчы уллары Айвазга язмыш тәгаенләгән тәкъдир... сөенерлек түгел иде. Совет Армиясе сафларында хезмәт иткәндә аны адәм актыклары кыйнап, имгәтеп ташлады. Вәхшиләр гамәле ана йөрәген яралады, меңгә телгәләде. Ата-анасы сөеп үстергән камил акыллы газизеңне гомерлек гарип ясасыннар әле! Акылдан язарсың! Төпчеге – күз нуры Айнур да, аварияга эләгеп, айдан артык аңсыз – комада ятты. Шөкер, аякка басты. Көчле рухлы Фираябыз шулкадәр хәсрәт күреп тә авырлыкларга бирешмәде: эштән, иҗаттан туктамады, язды, күп укыды, юды-җыйды, пешерде... Талантлы дустыбыз Илсөярнең «Шагыйрә дип сокландылар миңа – мин хатын-кыз идем иң элек», дигән сүзләре Фираяга да туры килә. Эшкә комсыз иде ул, әйткәнемчә, тәрҗемә, машинкада басу (компьютерлар юк чак) кебек эшләргә дә берсүзсез алына. Ә күңеле... искиткеч юмарт. Мул куллы, саранланмый, шуңа күрә әзерләгән ризыгы телеңне йотарлык тәмле килеп чыга. Кунакчыл. Бәйләм – аның җан сөйгән шөгыле иде бугай. Шәлләр бәйләп үскән кыз ич! Башлык, бияләй, кофта дисеңме – коеп кына куя. Тик... Һай, матур, дип соклана күрмәгез! Күз нурын түгеп бәйләгән кул эшен сиңа бүләк итү хәстәренә керешәчәк ул. Фарсель – атаклы бакчачы. Күл буендагы бакчаларында ни генә үсми: утызлап төп карлыган, унлап алмагач, ул кура җиләге! «Карлыган пеште, коела, җыярга килегез!» Өч чиләк җыясыңмы, күбрәкме – җый гына! Мунча ягып, бәлешләр пешереп тагын кайда көтәләр сине! Карлыган, җиләк бетүгә алмагачлар сыгылып төшә. Тагын хәбәр: «Нишләп ятасыз алмага килмичә, коелып беткәнен көтәсезмени?!» Сыйланып, кунак булып, биштәрләреңне тутырып куюга, Айдар машинасы белән килеп җитә, өеңә кадәр илтеп тә куя. Нигә кирәк шулкадәр карлыган дигән сорауга да җавап әзер: «Сез дусларны бергә җыяр өчен!» Йорт-җирсез Мөдәррис Әгъләм дә айлар буе яшәп ята монда – урын да, сый да җитә.

## Авыр чакта юатырдай сүз тапкан Фираяга – кешелекле, ярдәмчел дуска гомер буе рәхмәтле булдым.


Яңа йортларын күрергә барып, Казан каласында адашып йөргәнем дә истә икән әле. Фираяларга фатир биргәннәр, кунакка чакырдылар. Серләшеп-сыйланып утыра торгач, соңга калынган. Кайтыр якка түгел, килгән якка утырып киткәнмен, гөнаһ шомлыгы. Өчдүрт тукталыш үтүгә кондуктор: «Соңгы тукталыш, эш көне тәмам, төшегез!» – ди. Төштем. Чү! Караңгы, алда бушлык. Күз ияләшкәч, күрәм: каршымда буйдан-буйга сузылган озын-тирән чокыр... Мең бәла белән Киров районындагы өемә кайтып җиттем. Азино бистәсе җир чите булып хәтеремә уелып калды. Ә дистә ел узгач теге чокыр аръягында төзелгән йорттан миңа да фатир бирделәр. Җир чите түгел икән! «Фираяга якын! Җәяүләп бер-беребезгә кунакка йөрешербез», – дип юрап та куйган идем! Насыйп булмады. Сагынам, бәгырем, өзелеп сагынам мин аны. Студент чакта якынаеп, еллар сынавы аша узган каләмдәшләр – Роза Зәйнуллина-Туфитуллова, Ләлә Сабирова-Гыймадиева белән дә Фираяны еш искә алабыз. Яратып, сагынып, җәлләп... Нечкә күңелле, олы җанлы Фираябыз тирән мәгънәле, моңлы-нурлы җырлар калдырып иртә, бик иртә китеп барды шул. Аңа быел 5 сентябрьдә 75 яшь тулган булыр иде. Дуслыгыбыз 2006 елның 22 апреленә кадәр – Фирая мәңгелеккә күчкәнче дәвам итте дә бит...

Кеше китә, җыры кала. Фираябыз талантлы, ихлас, саф-садә күңелле якты шәхес иде. «Иң зур бәхет», «Матур буласым килә», «Китмим әле яшьлегемнән», «Бәхет өчен күп кирәкми» кебек җырлар һәм якты нур калды аннан... Сүз белән әйтеп тә, аңлатып та булмый торган хәтер яктысы. Сагындыра торган! Хәер, әле бүген дә ул янәшәдә сыман!

Роза МУЛЛАНУРОВА

Фото: сулдан-уңга – Фирая Шиһапова, Фәния Әхмәтшина, Роза Мулланурова. 1963 ел.

# ХАТЫН-КЫЗ РОБОТ ТҮГЕЛ



Рамил ШӘРАПОВ, юморист, артист;
гаилә стажы – 7 ел;
балалары:
Раян – 6 яшь, Линара – 4 яшь.

**Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...**
**Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.**

**1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...**

– Яшьлекнең төрле чорлары бар бит. 16–22 яшь – җил куып йөри торган вакыт. Ул чакта чибәрләргә күз төшә. Кызлар белән күп йөргән кеше түгел мин. Алтынчы сыйныфта укыганда бер кызга гашыйк идем. Әле дә хәтерлим: әнинең мунчага дип алып куйган запас сабыннарын урлап бүләк иттем. Минем мәхәббәт җавапсыз калды. Ир-ат җавап хисләре тоймый икән, аның күңеле тиз сүрелә. Хатыным Земфира белән театрда таныштык. Ул костюмер иде. Кай ягына игътибар иттемме? (*Уйланып.*) Ул вакытта яшьлекнең башка этабында – эчке матурлыкны күрә торган чорда булганмындыр. Кешелеклелеге белән каратты. Үзен күрсәтеп, очынып йөри торган кыз түгел иде ул.

**2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?**

– Ә нигә гафу итәргә кирәк? Яратасың икән, ничек бар шулай кабул итәсең. Яши-яши зирәкләнәсең дә бит әле. Мин, мәсәлән, тузан сөртелмәгәнгә, ашарга пешерелмәгәнгә күз йома алам. Һәр вак нәрсәгә бәйләнәсең икән, димәк, син – бик бәйләнчек, вакчыл кеше. Ә ул хатын-кыз белән тандемда гармониягә комачаулаячак.

**3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?**

– Хыянәт! Анысын да еллар үткәч гафу итәрсең. Кәгазьне бер бөклисең икән, аны күпме турайтырга тырышма – эзе кала. Йөрәктә барыбер ярасы калачак. Тормышта хыянәт итүче ирләрне яклаучылар да бар: имеш, табигате шундый, аучы. Уйлап карасаң, хатын-кызда да шул ук табигатьтер инде. Бу адымга бару – ул гаиләңә дә, балаларга да хыянәт итү, аларны санламау.

**4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?**

– Миңа аның икесе дә якын. Ни өченме? Минем хатында ул ике сыйфат та бар. Өйдә комфорт та тудыра, шул ук вакытта миңа иҗатта этәргеч тә бирә. Артистларның тормышы күпләр уйлаганча уен-көлке белән генә бармый. Төшенкелеккә дә биреләсең. Төрле хәлләр булды. Земфира һәрвакыт мине үсендереп торды. Үземнекен булдыру теләге Буа дәүләт драма театрыннан Казанга алып килде. Күз тондырып зур шәһәргә килеп кердең, тик сине монда беркем көтми. Казанда җиде ел яшәп, без биш фатир алыштыргандыбыздыр. Ипи сатып алырга да акча җитмәгән чаклар булды. Кайбер хатын-кызлар авырлыклар килгәч: «Мужик башың белән шуны да булдыра алмыйсың», – дип, ирләрен игәүләргә тотына. Бу җәһәттән минем күңелем тыныч. Земфира һәрвакыт янәшәмдә. Бер-беребезгә терәк без. Әле дә кеше фатирында яшибез. Мин моны яшермим. Подумаешь, мин – артист. Һәрнәрсәнең үз вакыты бар.

**5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?**

– Дус кынамы соң, иң якын дус була ала! Минем якын дусларым юк. Бар ул коллегалар: «Сәлам, брат! Ничек хәлләр», – дип сөйләшә торган... Тик мин аны дуслык дип санамыйм. Заманасы шундый: икейөзле кешеләр күп. Бигрәк тә шоу-бизнеста. Әйе, хәзерге заманда хатыныңа да ышанырга ярамый, диләр. Без бер-беребезгә ышанабыз. Шуңа да гармониядә яшибез. Өйләнгәндә: «Аллаһы боерса, аерылып, балаларымны ятим итмәм», – дип үз-үземә сүз биргән идем. Популярлашкан саен, хатын-кызлар да, дуслар да арта. Әмма онытма: син кем белән күтәрелдең!

**6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме?**

– Мин хатынга тәкъдим ясамадым. Югыйсә үзем романтик кеше. Бик ыгы-зыгылы чор иде ул. Театрда эшләгән вакыт. Тугыз ай гына очрашсак та, бер-беребезне бик якын итә идек. «Үзебезне гаилә итеп күрәм, әйдә, язылышыйк», – дип, ЗАГСка киттек. Бер көн туры килми. Бары тик дүшәмбе генә буш. 12 апрельдә мин үз өемнән, ул үз өеннән ничек киенгән шулай ЗАГСка кердек тә язылыштык. Икәү генә. Аннан Казанда Мәрҗани мәчетендә никах укыттык. Кечкә туй ясадык. Гадәттә, икенче көнне шашлык ясыйлар, табигать кочагында ял итәләр. Мин Чаллыга чыгып киттем. Яңа тормыш шау-гөр килеп туй ясаудан башланырга тиеш дип уйламыйм. Бәхет анда түгел! Аллага шөкер, шушы көнгә кадәр бер-беребезне аңлап гомер итәбез.

Гел матур сүзләр генә әйтешеп яшибез дип әйтмим. Земфира «җимешем, матурым»ише төче сүзләрне, гомумән, яратмый. Без дә, гадәти гаиләләр кебек, әрләшеп-талашып та алабыз. Кызганычка, мин тугызынчы сыйныфта укыганда әти белән әни аерылышты. Бик авыр кичердем. Земфираның да әти-әнисе аерылышкан. Шуңа күрә тигез тормыш кадерен беләбез.

**7** Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Сайлыйдыр. Мин эзләмәдем. Әйе, Земфира да әни кебек тырыш, бик чиста, сабыр. Юк-барга көнләшми. Ул мине аңлый. Мин дә сәбәп бирмим. Эшемне яратам. Гаилә белән карьераны тигез алып барырга тырышам. Гаиләңдә проблема бар икән, нинди иҗат инде ул?!

**8** Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Әгәр хатын-кыз моннан канәгать икән, гармониядә яшәячәкләр. Тик мин алай яши алмыйм. Милләтем андый түгел. Татарга хас нәрсә түгел ул. Мужик – аучы, гаиләне саклаучы булырга тиеш. Гаиләм өчен җаваплылык минем өстә. Хатынымнан керем көтеп ятмыйм. Ул эшләми дә минем: балалар карый.

**9** Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Миңа аңлатканнары юк. Рус артистларына язалардыр. Безгә хас түгел ул. Ә тормышта андый хатын-кызлар да бар. Йә аңа кияүгә чыгарга кирәк, йә табигате сорый. Юк, хатын-кызларны гаепләмим. Бар бит шундый юаш егетләр: тотып селкисе килә. Аларга чаялар кирәк тә инде. Андый хатын-кыз белән югалып калмаячаклар. Хатыннары гомер буе артларыннан төртеп алып барачак. Беркемгә дә сер түгел: гаиләне, нигездә, хатын-кызлар тартып бара. Шундый ирләреннән начальник ясаучылары да бар. Мин ул яктан хатын-кызларны аңлыйм.

**10** Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Кемгә нәрсә кирәк инде. (*Көлә.*) Ир-атның игътибарлы булуыдыр, мөгаен. Хәзерге заманда күп хатын-кызны егетләргә караганда аның машинасы, кесәсе җәлеп итә. Кем нинди караш белән тормышка карый бит әле.

**11** Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу чынлап та шулаймы?

– Әлбәттә, бар лидер хатын-кызлар. Алар эштә дә, тормышта да беренче. Чибәр хатын-кызга өйләнәләр икән, көнләшәләр, китмәсен дип куркалар. Чөнки беләләр: өстенлеге бар – чибәр. Теләсә кемне каратачак ул. Элек хатын-кыз өчен аерылышу бик оят булган, хәзер башкачарак. Ул төшеп калмый: тормышын алып бара, мәш килеп бизнес ясарга мөмкин, стратегиясе бар. Нигә шулай? Тәрбия башка. Элек хатын-кыз сабыр итә белгән. Хәзер ул сыйфат юк. Хәер, ритм да башка. Чибәр хатын-кызлардан шәхсән үзем курыкмыйм: гашыйк була алам. Күңелдә күбәләкләр уйный башлый. Әмма ул энергиямне иҗатыма күчерәм. Дөрес калыпка салсаң, рухландыра ул.

**12** Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный. Мондый очракта нишлисез?

– Әгәр дә кечкенә әйбер икән, юл куясың, масштаблы булса, чынлап та дөрес икәнеңне расларга тырышасың. Алай да аңламый икән: «Ярар, алайса үзеңчә эшлә, авызыңны пешер», – дисең инде. (*Көлә.*) Бездә андый аңлашылмаучанлыклар юк. Без бик спонтан гаилә. Беркайчан да каядыр барырга алдан әзерләнмибез. «Әйдә, монда барабыз», – дип әйтәм икән, бер минутта җыенабыз да чыгып китәбез. Икебез дә бик җиңел ул яктан.

**13** Шундый очракны күзаллыйк әле: сез, ачыгып, арыпталып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, арыдым дип, диванда кырын ятып тора. Сез нишлисез инде? Кафега чыгып китәсез яки пиццага заказ бирәсез? Тиз генә үзегез берәр нәрсә пешерәсез?

– Хатын-кыз робот түгел. Авырган вакыты булырга мөмкин, хәле юктыр, башы авыртадыр. Бәлки, өлгермәгәндер. Өйдә ашарга булмаудан фаҗига күрмим. Кайбер чакта гастрольләрдән кайтып керәм, ашарга әзер түгел. Ул: «Ник алдан шалтыратмадың?» – ди. Үзем гаепле булып чыгам бит инде. Ашарга юк икән, кафега барып ашап кайтам. Ач булсам, нык усалмын. Миңа ашарга кирәк. (*Рәхәтләнеп көлә.*) Өйдә, билгеле, Земфира пешерә. (*Җитди итеп.*) Ләкин ул бит миңа кияүгә чыкканда көн саен ашарга пешерәм дип килешү төземәде. Үземнең пешергәнем бар, тик бик сирәк. Без, ир-атлар, пешерәбез икән, пешерәбез инде! Мин, мәсәлән, суганнарга, кишерләргә бар мәхәббәтемне биреп пешерәм инде. (*Көлә.*)

**14** Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан. Бу сезнең ачуны китерәме? Китерә икән, бу хәл белән ничек көрәшәсез?

Бездә бик сирәк була ул. Мин – кызу кеше. Кызып китәргә мөмкинмен. Әмма мин генә түгел бит әле. Аңа балаларны да җыярга кирәк! Чыгып машина караштыра торам. Бервакытта да зурга җибәргәнебез булмады. Хатын-кыз да кеше бит. Өйрәтергә цирктагы хайван да түгел.

**15** Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.

Земфира гел миңа кирәкле әйберләр генә бүләк итә. «Син үзең бүләк», – диям, шулай да бүләк биргәндә бик рәхәт инде. Үзем, бәйрәм булмаса да, бүләк бирергә яратам. Бервакыт бик озакка сузылган гастрольдән кайттым. Төнге икедә чәчәк кибетенә бардым да 101 роза алып кайттым. Шаккатып кабул итте ул чәчәкләрне, эмоцияләре дә озакка барды. Еракка гастрольләргә китсәм дә, өйгә чәчәкләр китерергә заказ бирәм. Хатын-кыз өчен бик мөһим бит ул. Әлбәттә, яшәеш акчага корылган. Шул кәгазьләр өчен тәгәрмәчтәге тиеннәр кебек чабабыз. Әмма бар нәрсәгә акча баш дип уйламыйм. Дөньяга бернәрсәсез килдек, бернәрсәсез китәбез. Тормышның ямен-тәмен белеп яшәргә яратам. Җәй үтеп китте, күрмәдек тә, диләр. Буага кайткач, Земфира белән 30 чакрым ераклыктагы Бәбки дигән авылга чыгып китәбез. Кечкенә авыл ул. 17 йорт кына калган. Андагы хозурлык! Кеше кулы тимәгән табигый матурлык! Берәү булса: «Бензин әрәм итеп йөримме соң?!» – дияр иде. Без Земфира белән җәй көне унар тапкыр барып кайтабыз шунда. Тау бар анда. Шунда менәбез. Хозурланабыз. Миңа андый йөрүләр, уйланулар, эмоцияләр акчага караганда да кыйммәтрәк.



**«Елата күрмә, бүсере чыкмасын!» Яшь баласы булган әниләр бик еш ишетә торган сүз бу. Нилектән килеп чыга бу чир һәм аның сәбәбе баланың елавында гынамы? Республика балалар клиник хастаханәсенең хирургия бүлеге мөдире, югары категорияле табиб, балалар хирургы Ренат ЯФЯСОВ белән сүзебез шул хакта.**

# БҮСЕР ЕЛАГАННАН ЧЫГАМЫ?

Касык бүсере җитлегеп туган балаларның 5 процентында, иртәрәк туучыларның 25 процентында күзәтелә. Малайларда 10 тапкырга ешрак очрый. Әлеге патология, нигездә, тумыштан ук була. Карында чакта ир балаларның күкәйләре махсус канал аша корсак куышлыгыннан йомырка капчыгына төшә. Үз вакытында ябылмаса, әлеге канал аша эчке органнар бүселеп чыга. Ул эчәклекнең берәр элмәге, кыз балаларда күкәйлекләр яки аналык торбалары булырга мөмкин. Кызлардагы бүсернең килеп чыгуы аналыкны тотып торучы сеңерле бәйләвеч формалашу белән бәйле. Әлеге патологиянең барлыкка килүенә нәселдәнлек тә йогынты ясый. 10–11 процент бәләкәй пациентларның әтисендә яки әнисендә кайчандыр касык бүсере күзәтелгән була. Зуррак балаларда касык бүсере барлыкка килгән очраклар исә бик сирәк.

Касык бүсерен бандаж кию ише консерватив чаралар белән бетерү мөмкин түгел. Ул еш кына катлауланулар белән уза. Иң куркынычы – бүсернең кысылуы. Ир балаларда аны кайчагында кул белән дөреслəп җибәреп булса да, кызларга кичекмәстән операция таләп ителергә мөмкин. Катлауланулар булмаганда, балага 6 ай тулганнан соң, планлы операция ясалып, бүсер капчыгы алына. Аннары бүсер авызы тегеп куела. Хәзер әлеге операция күп очракта лапароскопия юлы белән ясала.

**Билгеләре:**

- касыкта эластик шешенкелек (кызларда – тышкы җенес иреннәренә, ә малайларда күкәй капчыгына кадәр килеп җитәргә мөмкин);
- бу шешенкелек бармак белән баскалагач югала, әмма мускулларга көч килгәндә кабат чыга;
- сабый бала сәбәпсез елый;
- зуррак балалар эче авыртудан зарлана;
- баланың олы йомышын үтәүгә бәйле проблемалар барлыкка килә;
- эчәклектән газлар чыгу туктый, эч кабара;
- организмның гомуми хәлсезлеге күзәтелә.

БУ МӨҺИМ:

- **Бүсер капчыгындагы эчке органнар бүсер авызында кысылырга мөмкин. Бу – баланың гомеренә куркыныч тудыра торган халәт. Кичекмәстән ашыгыч ярдәм чакырып, баланы хастаханәгә алып барырга кирәк. Табиб килгәнче, сабыйның бүсеренә җылы грелка куеп, аякларын өскә таба күтәртеп яткыралар.**
- **Касык бүсерен башка катлаулы чирләр – эчке органнардагы төрле кисталар, лимфаденит белән бутамас өчен, баланың эчке органнарына җентекле УЗИ ясалырга тиеш.**

ДРКБның матбугат хезмәте җитәкчесе Зөһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.



**Куркыныч тудыручы факторлар:**

- нәселдәнлек;
- туган вакытка вагиналь үсентенең тулысынча ябылып бетмәве;
- баланың озак итеп бик каты елавы;
- дәвамлы эч кибү;
- үпкә ялкынсынуы белән узучы каты ютәл;
- зур физик нагрузка, авыр әйберләр күтәрү (зуррак балаларда);
- корсак стенасы мускуллары зәгыйфьлеге.

**Әти-әниләргә киңәш:**

- зуррак балаларда касык бүсерен кисәтү өчен, дөрес туклануга игътибар итәргә;
- эчәклектә булган авыруларны вакытында дәваларга;
- балада эч катуны булдырмаска;
- артык зур физик нагрузкадан сакларга;
- бала җитәрлек хәрәкәтләнсен;
- баланың гәүдә авырлыгын нормада тотарга.





**Җәй – яллар һәм сәяхәтләр ае. Ел дәвамына җитәрлек кичерешләр, уңай хисләр ала торган фасыл. Ләкин... кайчагында җәйге яллардан җанны иркәләгән хисләр генә түгел, аяк табанын һәм тырнакларны зарарлаучы гөмбәчек авыруы да ияреп кайтырга мөмкин. Тынычлыкны алучы һәм аяк киемен сайлаганда хатын-кызларны нык чикләүче бу чир белән ничек көрәшергә? Республика клиник хастаханәсенең дерматовенерологы Марианна БЫЧЕК белән сүзебез әнә шул хакта.**

# САК БУЛЫГЫЗ, МИКОЗ!

Гөмбәчек авыруы – микоз үтә дә йогышлы чирләрнең берсе. Аяк табанын, бармак араларын зарарлаучы бу чирне төрле төрдәге дерматофитлар барлыкка китерә. Еш кына табан астындагы тән тиресе белән бергә тырнаклар да зарарлана. Микоз белән кешелекнең 5–10 проценты чирли. Гөмбәчек тәндәге вак яралар, җәрәхәтләр аша иярә. Аякта сөялләр булу да аны йоктыру куркынычын арттыра. Шикәр диабеты, яссытабанлылык, аяктагы кан тамырлары варикозы, артык авырлыктан интегүчеләр микозны ешрак эләктерә. Бу иммунитетның какшавы белән дә аңлатыла.

Микозның беренче билгеләре күренү белән, озакка сузмастан табиб-дерматологка күренергә кирәк. Гөмбәчекләр бик күптөрле була. Организмны кайсысы зарарлавын ачыклау өчен тире кисәкчекләренә махсус анализ ясала. Дәвалау чаралары, пациентның сәламәтлегенә һәм тиренең никадәр зарарлануына карап, һәркемгә индивидуаль билгеләнә. Табиб тирегә сөртелүче мазьлар белән беррәттән, гөмбәчек авыруына каршы комплекслы чаралар да билгели. Үз белдегең белән дәвалану нәтиҗәсез генә түгел, хәтта куркыныч та булырга мөмкин. Кызганыч, микоз йоктырган һәркем табибка барырга ашыкмый. Комплекслы дәваламаганда, үзеннән-үзе генә бетә торган чир түгел ул. Аяк тиресенең кечкенә генә бер урынында башланып, тора-бара зуррак өлешләргә күчә, тырнакларны тулысынча зарарлый. Бик сирәк очракларда эчке органнарга да күчәргә мөмкин. Гөмбәчек – бик көчле аллерген да.

**Кайда иярә:**
- мунчада, саунада, бассейнда;
- спорт залларында;
- пляжда;
- инструментлар тиешенчә эшкәртелмәгән очракта – маникюр һәм педикюр салоннарында;
- гөмбәчек идәндә, паласта, keләмнәрдә дә яши.

**Микозның билгеләре:**
- табан астының тиресе кубалаклану;
- гиперкератоз – аяк табаннарында тиренең калынаюы;
- аяк тиресенең кызаруы;
- вак-вак юеш җәрәхәтләр барлыкка килү;
- бармак араларының ярылуы;
- тырнакларның калынаюы һәм төсен үзгәртүе;
- табан асты һәм бармак араларының бик нык кычытуы;
- тырнакларның калынаюы аркасында бармаклар да авыртырга мөмкин;
- аяктан һәм аяк киемнәреннән авыр ис килү.

**БУ МӨҺИМ:**
**аяктагы гөмбәчек авыруын төрле үлән төнәтмәләре белән дәвалау, аякны аш серкәсе, диңгез тозы, чәй содасы салынган суга тыгып торуның нәтиҗәсе юк. Болар фәкать профилактика чаралары гына була ала, берничек тә дәвалау чарасы сыйфатында кулланылмый.**



**Ничек булдырмый калырга:**
- гигиена таләпләрен катгый үтәргә;
- башкалар сөлгесен һәм урын-җирен кулланмаска;
- чит аяк киемен, хәтта үз гаиләңдәгеләрнекен дә кимәскә;
- кунакка баргач, кибетләрдә аяк кияме сайлаганда аякка оекбаш кияргә;
- җәмәгать мунчалары, сауна, бассейн, пляжда яланаяк йөрмәскә;
- гаиләдә кемдер авырса яки үзегез йоктырсагыз, гөмбәчек яшәргә мөмкин булган һәртөрле урынны – идәннәрне, ванна-душларны, паласларны яхшылап юарга;
- тырнак кисә торган кайчылар, маникюр җыелмаларын дезинфекцияләргә (авыручы кешенең үз җыелмасы булырга тиеш).



Республика клиник хастаханәсенең җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча әйдәп баручы белгече Валерия Белова ярдәмендә әзерләнде.

# Балыкчы шулпасы




**Балыкчы әзерләгән балык шулпасыннан да тәмлерәк аш бармы икән! Әле ул аш ямьле табигать кочагында, учакка казан асып пешерелгән дә булса! Бүген бездә кунакта – язучы,«Идел» журналының баш мөхәррире Гөлүсә ЗАКИРОВА. Кунагыбыз иҗат кешесе генә түгел, оста балыкчы да! Гөлүсә ханым әле этисе, әле ире белән җай чыккан саен балыкка йөрергә ярата. Балык тотуның җаен, барлык йолаларын белгән, ләззәтен татыган кеше ул! «Сөембикә» журналы укучылары өчен патшаларча әзерләнә торган балык шулпасын да үзе тоткан судактан пешереп күрсәтте. «Балык шулпасын табигатьтә нәрсә бар, шуның белән пешереп була, ул ничек тә тәмле килеп чыга. Өйдә сөмбаш белән әзерләгәндә шулпага йомырка да туглап сала кайберәүләр. Әмма елга балыгына йомырка килешми дип саныйм мин», – ди Гөлүсә ханым.**
**Әллә шулпабызның тәмле исе тәэсир итте, ашыбыз әзер булганда гына кунакка яңгыр болыты да килеп җитте. Әй иште дә соң! Яңгыр тамчылары төшкән уха иң тәмлесе, диләр! Кулчатыр астында төшерелгән тәмле фотоларны, үзенчәлекле балык шулпасын – ухaны сезгә дә тәкъдим итәбез.**

***Кирәк***

- 2 балык (без судак һәм махсус күлдә үрчетелгән чөгә балыгы (стерлядь) кулландык);
- 1 стакан тары;
- 2-3 бәрәңге;
- 2 помидор;
- 2 баш суган;
- бер кишер;
- дәфнә яфрагы, түгәрәк борыч, укроп, петрушка, тоз.





Фото: Анна Арахамия

## Әзерләү

■ Безнең балык шулпасы табигатьтә әзерләнә. Шуңа күрә эшебезне казан астында ут тергезүдән башлыйбыз.

■ Казандагы су (тозы алдан ук салына) кайнап чыккан арада, балыкларны юып, чистартып, телемләп турап куябыз.

■ Судакны казанга салып 5-7 минут пешерәбез. Аны шулпадан алып башка савытка күчерәбез. Чөгә балыгын да казанга салып 5-7 минут пешерәбез һәм шулпадан алабыз.

■ Балыклар пешкән шулпага алкалап туралган бәрәңге, кишер, помидор һәм тәмләткечләрне салабыз.

■ Яшелчәләр кайнап чыккач, тары ярмасы өстибез.

■ 10–15 минут кайнаганнан соң, балык шулпасын уттан алырга да була.

■ «Сөембикә» журналы тәкъдим итә торган ризык рецептлары гади генә була алмый! Бу юлы менә балык шулпасына аерым тәм кертер өчен, Гөлүсә ханымнан серле ысул: учактагы бер утлы чыраны алып, шуны шулпага чумдырып алабыз. М-м-м... Казан өстеннән күтәрелгән хуш исне белсәгез!!!

■ Балык шулпасын учактан алып, тәлинкәләргә бүләбез. Өстенә яшел тәмләткечләр сибәбез. Балыкны яшелчәләр белән аерым савытка куеп, өстәлгә чыгарабыз.
Тәмле булсын!



Дөрес туклану принцибы белән яшәүче кешенең дә кайчагында берәр баллы тәм-том, әйтик, кайнатма яки джем белән чәй эчәсе килеп куярга мөмкин. Әгәр дә ул джем дөрес ризыклар төренә керә икән, ник соң әле эчмәскә ди?! Дөрес туклану рубрикасының даими авторы Камилә **ДИМӨХӘММӘТОВА** тәкъдим иткән джемны әзерләр өчен күп вакыт та, әллә нинди ят ингредиентлар да кирәк түгел. Аны теләсә кайсы җиләк-җимештән әзерләргә мөмкин, без исә сентябрь нигъмәтләрен – алма белән кабакны кулланабыз.



# Дөрес джем

Әлеге рецептның сере – чиа орлыгында. Ул җиләк-җимешләрдән әзерләнгән бу джемны куе һәм туклыклы гына түгел, файдалырак та итә.

Гадәти джемнарның нигезендә шикәр һәм пектин була. Шикәрнең организмга зыяны турында аз сөйләмиләр, ә пектин?! Эшкәртелмәгән ризыклардан алынган пектин организм өчен файдалы, ә менә азык-төлек индустриясендә кулланылучы әллә ничә кат эшкәртелү аша узганы турында болай дип әйтеп булмый. Менә шуңа да без тотрыкландыргыч сыйфатында чиа орлыгын кулланачакбыз.

## АЛМАДАН

**Кирәк:**

- 2 стакан алма пюресы;
- 2 аш кашыгы бал яки 6-7 хөрмә җимеше (финик);
- 45 г чиа орлыгы;
- 0,5 чәй кашыгы ваниль экстракты (яки ванилин);
- 0,5 чәй кашыгы төелгән дарчин (корица);
- 4 аш кашыгы лимон суты;
- бер чеметем тоз.

**Эш барышы:**

1. Блендерда чиа орлыгын ваклыйбыз (нәкъ менә вакланган орлык кына безгә кирәк куелыкны бирә).

2. Алмаларны да блендердан үткәрәбез (аларны башта мичтә пешереп алырга була. Ул очракта бары тик бал гына кушасыз һәм өченче пунктны үтәмисез).

3. Блендердан үткәрелгән алма пюресын кәстрүлгә салып, бал кушабыз һәм кайнап чыкканын көтәбез.

4. Алманы уттан алабыз. Ваниль, чиа орлыгы, дарчин, лимон суты, тоз һәм хөрмәләрне кушып, кабат барысын да блендерда ваклыйбыз. Төерләр калмаска тиеш.

Джемны суыткычта саклыйбыз.

## КАБАКТАН

Джемны кабактан әзерләү рецепты да алманыкыннан әллә ни аерылмый. Фәкать кабакны башта мичтә пешереп, ваниль белән дарчин урынына башка төрле тәмләткеч кенә кулланырга кирәк. Аның өчен 2 чәй кашыгы дарчинны 1 чәй кашыгы имбир, 0,5 чәй кашыгы мөшкәт чикләвеген (мускатный орех), 0,5 чәй кашыгы төелгән канәферне (гвоздика) бергә кушабыз һәм джем әзерләгәндә 2 чәй кашыгы күләмендә алабыз.

Джем чәй белән эчәргә дә тәмле, аны чистартылмаган бөртектән пешерелгән икмәк өстенә ягарга, солы боткасына яки йогыртка кушарга да була.



Фото: www.pixabay.com

***Кучкар.*** Һөнәри яктан күтәрелешләр, якты киләчәк көтә. Акчаны саклап тотыгыз. Командировкаларга йөрү, килешүләр төзү өчен уңайлы вакыт. Һәр өлкәдә үзегезне уңай яктан күрсәтергә тырышыгыз.

***Үгезбозау.*** Төрле психологик кризислардан, күңелсез уйлардан арыныр өчен, беренче чиратта үзегезне ишетергә тырышыгыз. Китаплар укып, яңа кешеләр белән танышып, үзгә дөнья ачар вакыт җиткән.

***Игезәкләр.*** Октябрь сезгә сюрпризлар әзерли. Иммунитетыгызны ныгытыгыз, салкын тиюләрдән сакланыгыз. Кыйммәтле әйберләр сатып алудан тыелып торыгыз. Килешүләр төзегәндә игътибарлы булыгыз.

***Кысла.*** Мәшәкатьләргә бай ай булачак. Якыннарыгыз белән аралашканда эмоцияләргә бирелүдән, кызып китүләрдән сак булыгыз. Ял көннәрендә гаиләгез белән табигатькә чыгып көч тупларга тырышыгыз.

***Арыслан.*** Иҗади күтәренкелек вакыты. Интуициягезгә таянып эш йөртегез. Финанс мәсьәләләре дә уңышлы хәл ителер. Хоббига да вакыт калыр. Октябрь сезнең өчен бәхетле ай булырга охшап тора!

***Кыз.*** Һәртөрле конфликтлардан сакланыгыз. Ялгыз Кызларны романтик очрашулар көтә. Сәламәтлегегезгә игътибарлы булыгыз. Кичләрен үзегезгә ял оештырыгыз. Китаплар укыгыз.

***Үлчәү.*** Эш буенча күптән көтелгән тәкъдим яңгырар. Тормышыгызны үзгәртергә әзер булыгыз. Яңа сәләтләрегез ачылыр. Өстәмә табыш алырсыз. Үзегезне бик бәхетле хис итә торган чор бу.

***Чаян.*** Каршылыкларны, катлаулы сорауларны зирәк акылыгызга таянып хәл итегез. Эшегездә көтелмәгән уңышларны рәхмәт хисе белән кабул итегез. Холкыгыз катлаулы булса да, белеп торыгыз – сезне яраталар!

***Укчы.*** Бу айда сезне иң матур вакыйгалар көтә. Хыялларның чынга аша торган чоры дип тә әйтергә буладыр. Сәламәтлек турында онытмагыз, кирәк булса табибларга да мөрәҗәгать итегез. Эштә дәрәҗәгез үсәр.

***Кәҗәмөгез.*** Теләсә нинди проблемаларны хәл итәргә якын дусларыгыз булышыр. Күбрәк ял итәргә тырышыгыз. Гаиләдәгеләр белән мөнәсәбәтләрегезне ныгытыгыз, алар да сезнең игътибарны көтә.

***Сукояр.*** Кирәкмәгән элемтәләрне өзәр чак җитте. Уңайсыз хәлләрдә калмас өчен, кешеләргә артык ышанмагыз. Эшегездә мәшәкатьләр күп булыр. Гаилә кору өчен әйбәт вакыт.

***Балык.*** Күп көч һәм энергия сорый торган ай булса да, сез аны җиңеллек белән узып чыгарсыз. Яңа танышулар вакыты. Сәламәтлегегезгә игътибарлы булыгыз. Дуслар белән аралашырга вакыт табыгыз, алар сезгә бу чорда зур терәк булачак.

# ОЗАКЛАП УЙЛАНАСЫЗМЫ, ӘЛЛӘ...

Берәүләр тормышта «җиде кат үлчәп, бер кат кисеп» яшәр өчен яратылган. Ә кемнәрдер артыгын уйлап тормыйча, җил-җил атлап алга бара. Боларның кайсысы дөресрәк? Бу тестның гади генә сорауларына җавап биреп, үзегезнең кайсы төркемгә кергәнегезне ачыкларга мөмкин.

**1.** Юк кына сәбәп аркасында да кызып китәсезме?

**2.** Физик яктан үзегездән көчлерәк кешенең ачуын чыгарудан куркасызмы?

**3.** Үзегезгә игътибар җәлеп итү өчен махсус гауга оештырганыгыз бармы?

**4.** Тормышка куркыныч янаганын белсәгез дә, зур тизлектә машина йөртүне дөрес дип саныйсызмы?

**5.** Авырганда халык медицинасына мөрәҗәгать итмичә, дару эчү белән мавыгасызмы?

**6.** Максатка ирешү өчен чикләр юк дип саныйсызмы?

**7.** Зур этләр яратасызмы?

**8.** Сәгатьләр буе кояшта утыра аласызмы?

**9.** Үзегезнең кайчан да булса танылган кеше буласыгызга ышанасызмы?

**10.** Җиңелә башлаганыгызны аңлагач, бәхәсләшүдән туктый беләсезме?

**11.** Ашыйсы килмәгәндә дә күп итеп ашап кую гадәтегез бармы?

**12.** Сезгә нәрсә бүләк итәселәрен алдан белеп торырга яратасызмы?

**2 дән алып 10 га кадәр булган сорауларга һәр уңай җавап өчен – 1 балл куегыз.** 1, 3, 4, 5, 6, 8, 9, 11, 12 сорауларга һәр тискәре җавап өчен – 1 балл языгыз. Хәзер, әйдәгез, балларны санап, нәтиҗәләрне укып карыйк.

**8 баллдан күбрәк.** Сез – бик зирәк хатын-кыз. Акыл белән уйлап эш йөртәсез. Тынычлап кына яшәргә яратасыз. Күңел кайтулардан курыкмыйсыз, һәрнәрсәне ничек бар шулай кабул итәсез. Әмма башкалар белән җиңелрәк аралашу, көннәрегезне төрләндерү өчен хәрәкәтчәнрәк булсагыз да ярар иде.

**4–8 балл.** Алтын урталыкта яшисез. Үзегезнең мөмкинлекләрне әйбәт белгәнгә күрә, куктән торна тотарга тырышмыйсыз. Табигатьтән килгән наянлыгыгыз сезгә сөйкемлелек өсти!

**4 баллдан азрак.** Сезгә һаман нәрсәдер җитми. Менә шул «җитешмәгән» әйберләр аркасында үзегезне гел бәхетсез итеп тоеп йөрисез. Тормыштагы кечкенә генә шатлыкларны күрергә, тоярга өйрәнегез әле! Бу сезгә тынычрак булырга, фикерләрне уңай якка үзгәртергә ярдәм итәр.

тест

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен
Раилә ХӘЯЛИЕВА,
Лилия ГӘРӘЕВА
әзерләде.









# ЯКТЫЛЫК ЯСЫЙМ...

Роза Савинова – сәнгатьнең бик киң кулланышта булмаган юнәлешен үз иткән рәссам: ул күп кенә әсәрләрен монотипия ысулы белән иҗат итә. Талантлы рәссам Якутиядә, хәрбиләр гаиләсендә туган, балачагы, яшүсмер еллары Чиләбе өлкәсенең Троицки шәһәрендә узган. Башта Троицк сәнгать мәктәбенең сынлы сәнгать бүлегендә укыган, аннан 1994 елны Магнитогорск педагогика институтының сынлы сәнгать-графика факультетын тәмамлаган. Шуннан бирле ул Чиләбе өлкәсенең Кизильское авылында балалар сәнгать мәктәбендә укыта. 2010 елдан Россия рәссамнар берлеге әгъзасы булып тора. Аның иҗат эшләре инде нинди генә күргәзмәләрдә катнашмаган! Рәссам җиңүләр яулаган бәйгеләр дә бихисап. Узган ел почта маркасы, тәбрикнамәләр һәм махсус штемпельләр ясау максаты белән үткәрелгән «Мин Посткроссинг яратам» Бөтенроссия рәсем бәйгесендә җиңүе генә дә ни тора! Рәссамның «Россиядән –ярату хисе белән» дигән тәбрикнамәсе «Марка» акционерлык җәмгыяте тарафыннан нәшер дә ителде.

Үз исеме дә чәчәк белән бәйле булгангамы, рәссам ханымның иҗатында чәчәк сурәтләре дә җитәрлек. Аның яраткан темалары аз түгел – туган як табигате, ел фасыллары, портретлар... «Гадәттә, бер темага багышлап языла башлаган эшләрем тулы бер серияләргә барып тоташа: «Чәчәкләр феериясе», «Себер», «Гади кешеләр», «Язгы кыр ритмнары» шундыйлардан», – ди ул. Кошлар дөньясы да игътибардан читтә калмый: аның пейзажлары үзәгендә һәрчак диярлек чиста күк киңлекләрендәге иркәле кошлар сурәтен күрергә була. Рәссам күп очракта гади каләм, акварель буяулар белән яки монотипия нигезендә, катнаш техникада иҗат итә. Заманча сәнгатьтә акварельчеләр һәрчак тиз таныла. Роза Фәрит кызының да башка сәнгатькәрләр арасында исеме күптән билгеле. Ул акварельне техник яктан катлаулы булуы, төсләрнең бер-бер артлы салмак кына күчә барып, хисләр тантанасыннан торган сурәтләр хасил итәргә мөмкинлек бирүе өчен үз күрә. «Мин мөмкин булмаганны булдырырга – яктылыкның үзен ясарга омтылдым», – дигән француз рәссамы К. Моне кайчандыр. Акварельчеләрнең барысы да нәкъ шул максатка омтыла. Һәм күбесе моңа ирешә дә. «Акварельне яратмау мөмкин түгел! Акварель әсәрләр бик тиз кибә, аның сыйфатын да шунда ук күреп була», – ди рәссам.


Роза Савинованың шәхси күргәзмәләре һәрчак зур уңыш белән уза, аның эшләре Магнитогорск картиналар галереясында, Краснодар крае, Томск өлкәсе, Калининград өлкәсе сәнгать музейларында, Петрозаводск күргәзмә залында, Курган шәһәре сәнгать музеенда, Башкортстан дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Алабуга дәүләт музей-тыюлыгында һәм Россия, Украина, Казакъстан, Германия, АКШ, Кытай, Һиндстан кебек илләрдә шәхси тупланмаларда саклана.

Күп еллар укыту дәверендә ул дистәләрчә баланы олы сәнгать юлына чыгарган. Халыкара һәм Бөтенроссия күргәзмәләрендә җиңү яулаган сәләтле укучылары да бихисап. Алар остазларының уңай холык-сыйфатларын үзләре өчен өлге итеп ала. Ә аңа тынгысызлык хас, ул гел хәрәкәттә: быел язын да берничә онлайн-күргәзмәдә, флешмобта, иҗади марафоннарда катнашты, яз сулышы тулы табигать күренешләрен сурәтләргә өлгерде. Ә җәен яңа чәчәк бәйләмнәрен кәгазь битләренә төшерде (акварель кануннарында нәфислек өстенлек итә!). Аның әсәрләрендәге сюжетлар тамашачыларга күңел күтәренкелеге өсти. Моңа да аңлатма бар: Роза Фәрит кызы бу дөнья яктылыктан гына торырга тиеш дип саный. Ул безне дә табигать җанын ишетергә чакыра!

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА








РОЗА САВИНОВА



Люция ВАФИНА,
Башкортстан Республикасының «Ак калфак» татар хатын-кызлары берләшмәсе төбәк иҗтимагый оешмасы җитәкчесе

Хөрмәтле Рөстәм Нургали улы!
Кадерле милләттәшләр!
Башкортстан татарлары исеменнән ТАССРның 100 еллыгы белән ихлас күңелдән тәбрик итәм!

Икътисадтагы, социаль өлкәдәге казанышлар, гаять үзенчәлекле тарихи-мәдәни мирасыбыз, ватанпәрвәрлек, Россияне, туган Татарстаныбызны ихлас ярату хисләре яшен-картын, милләте, дине, һөнәре төрле булган, төрлечә уйлаучы һәм фикерләүче кешеләрне берләштерә, якынайта.

Әлеге истәлекле көн гади бәйрәм генә түгел, ул – миллионлаган татарны үз куенына сыйдырган, йөрәк җылысын бүләк итеп, безгә ныклы таяныч булган, бөек татар милләтенең, чал тарихыбызның үз казанышларын барлау, ризалык, бердәмлек көне.

Башкортстан татарлары язмышында кыйблабыз Казан һәрвакыт ныклы терәк булды, бар татар оешмаларының социаль-икътисадый үсешенә, аның рухи мәдәниятен баетуга ярдәмен тоеп яшибез.

Татарстанның алга таба да үсүен һәм чәчәк атуын телим. Ышанам, ике тугандаш республика арасында дуслык ныгый гына барачак. Сезгә, хөрмәтле татарстанлылар, ныклы сәламәтлек, рухи күтәренкелек, бәхет һәм иминлек юлдаш булсын! Бәйрәм күңелле үтсен!

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

